# Булат Хәмидуллин

## КАЗАН ХАНЛЫГЫ ХАЛЫКЛАРЫ

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2008

УДК 947.0
ББК 63.3
Х27

Фәнни мөхәррире
тарих фәннәре докторы *С.Х.Алишев*

Рецензентлары:
тарих фәннәре докторы *Д.М.Исхаков,*
тарих фәннәре докторы, профессор *А.Г.Бахтин*

**Хәмидуллин Б.Л.**

Казан ханлыгы халыклары / Булат Хәмидуллин. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. — 174 б. — 2000 д. — ISBN 978–5–298–01633–9

Тарих фәннәре кандидаты Булат Хәмидуллинның бу хезмәте Урта Идел буе халыклары тормышының аз өйрәнелгән дәверенә — Казан ханлыгы чоры тарихын барлауга багышлана (XIV гасырның икенче — XVI гасырның беренче яртысы). Шул дәвергә караган, элегрәк елларда басылып чыккан күпчелек тарихи хезмәтләр бүгенге заман таләбеннән чыгып анализлана. Китап борынгы бабаларыбыз тормышы һәм язмышы белән кызыксынучы һәркем өчен кызыклы булыр дип өметләнәбез.

ISBN 978–5–298–01633–9
© Татарстан китап нәшрияты, 2008
© ХӘМИДУЛЛИН Б.Л., 2008

# ЭЧТӘЛЕК

**Кереш**

**Казан ханлыгы тарихы буенча төп чыганаклар һәм әдәбият**

1. Төп чыганаклар
2. Төп әдәбият

**Казан феодаль дәүләтенең барлыкка килүе һәм үсеше**

1. Казан дәүләтенең барлыкка килүе
2. Казан дәүләтендә Урда династиясенең турыдан-туры хакимияте урнашуы

**Казан дәүләтенең периферияләге төрки халкы**

1. Дәүләттә чувашларның борынгы бабаларының этносоциаль үсеше
2. Дәүләтнең этносоциаль тормышында нугайлар
3. Ханлыкка керүче башкортларның этносоциаль үсеше

**Казан дәүләтенең угро-фин халкы**

1. Дәүләт карамагындагы мариларның борынгы бабаларының этносоциаль үсеше
2. Ханлык җирлегендә формалашучы удмурт этносы
3. Казан ханлыгына кергән мордва халкы

**Йомгак**

*Кушымталар*

*Искәрмәләр*

## КЕРЕШ

Хәзерге тарих фәне, төрле халыкларның үзләренә генә хас иҗтимагый-этник берлек буларак формалашуын тикшергәндә, чиктәш тармак фәннәреннән археология, антропология, этнография һәм борынгы тел белеме мәгълүматларына таянып эшли. Бер халыкның формалашу тарихындагы гомумилек һәм үзенчәлекне, закончалык һәм шушы милләткә генә хас булган үзгәлекне өйрәнүче аерым комплекслы этносоциаль тикшеренүләр юнәлеше бүген уңышлы дәвам иттерелә.

Һәрбер халыкта тарихи процесслар үзенә бертөрле этник үзгә формада бара. Шуның белән бергә халыкларның тарихи үсешендәге этник һәм иҗтимагый-икътисади факторларның үзара бәйләнешләренә аеруча әһәмият бирергә кирәк. Бу бәйләнеш тарих фәненең хәзерге этабында һәркем тарафыннан таныла. «Иҗтимагый һәм этник тарих, — дип язды Л.Н.Гумилев, — бер-берсен алмаштырмыйлар, алар безнең җир өстендә үтүче процессларны күзаллавыбызны тагын да тулыландыралар». Ләкин халыкларның этносоциаль тарихы әлегә өлешчә генә өйрәнелгән. «Нәтиҗәдә, — дип билгеләде Ю.В.Бромлей, — кешелекнең этносоциаль тарихының күп яклары бүгенгәчә тиешле дәрәҗәдә яктыртылмаган булып кала бирә... Шуның өстенә этносоциаль процесслар анализы еш кына этник проблематиканың үзен өйрәнү артында капланып кала. Икенче яктан, кайвакыт этник тарих барлык иҗтимагый тарихка каршы куела һәм шулай итеп соңгысыннан бөтенләй бер читтә кала». Бу факторларны халыкларның тарихи үсешендә бергә бәйләп өйрәнү исә аларның этник үткәннәрен эчке яктан, этносларның конкрет тарихи чорлардагы сәяси, иҗтимагый-икътисади тормыш шартлары призмасы аша тикшерергә мөмкинлек бирә. Шулай итеп, узган гасырларның этник, этникара процесслары кабат үз материаль нигезләренә кайталар, эчке закончалыкларын һәм үзләренә хас үзенчәлекләрен тирәнрәк ачалар. Шул ук вакытта этник тормыш фонында җәмгыятьнең иҗтимагый структурасы, иҗтимагый үсеше күпкә ачыграк күренә, тулырак сиземләнә төшә. Шул рәвешчә, халыкларның этносоциаль тарихы буенча тикшеренүләр хәзерге тарих фәненең үсеше өчен мөһим. Алар кешелекнең этник һәм иҗтимагый-икътисади тарихы өлкәсендәге белемнәрен шактый тулыландыралар һәм баеталар.

«Этносоциаль тарих» тарих фәнендә яңа төшенчә түгел. Ул үз эченә бер төркем проблемаларны ала, этносларның тереклек эшчәнлегенең һәртөрле сфераларын — географик таралышыннан алып икътисади, мәдәни һәм иҗтимагый аңына кадәр колачлый. Шуңа күрә этносоциаль тарих конкрет тарих фәне белән беррәттән этнография, археология, лингвистика һәм тарих белеменең кайбер башка өлкәләренең дә игътибарында тора. Гадәттә, мондый тикшеренүләрнең объекты төрле этносларның иҗтимагый структурасы, үсеше, җәмгыятькә бәйле яки үзара иҗтимагый бәйләнештә булган этник, этнодемографик, мәдәни процесслар, этникара мөнәсәбәтләр була.

Бу хезмәт исә аерата конкрет-тарихи характер йөртә. Монда төп игътибар конкрет тарихи чорда, билгеле бер территориядә яшәгән төрле этник төркемнәрнең иҗтимагый структурасы һәм үзара иҗтимагый рәвештә бәйләнгән этник процессларына юнәлтелә.

Хәзерге галимнәрнең күбесенең, шулай ук Урта Идел буе һәм Урал тарихында әйдәп баручы белгечләрнең фикеренчә, аерым бер этник берлекнең тарихын түгел, ә билгеле территориянең (мәсәлән, тарихи-этнографик өлкәнең, аерым дәүләтнең яки тарихи-географик регионның) этносоциаль тарихын өйрәнү күпкә отышлырак, чөнки бу очракта этноконсолидацияләүче һәм этнодивергент процессларның барлык үзара үрелешләрен, этник контактларның һәм аларны барлыкка китергән күптөрле, беренче чиратта сәяси сәбәпләрен бөтен нечкәлекләре белән ачарга мөмкинлекләр күбрәк. Югарыда әйтелгәннәр бигрәк тә полиэтник булулары белән һәркемгә билгеле Урта Идел буе кебек төбәкләргә кагыла.

Аерым этнос чикләрендә түгел, ә үзара бәйле этнослар системасында, тарихи регионнар, тарихи-этнографик өлкәләр яки сәяси берләшмәләр чикләрендә тикшерелгәндә этносларның бергә тупланууының этносоциаль процессларын һәм импульсларын өйрәнеп һәм объектив бәяләп була, алар márbөтен тарихи күренеш буларак кабул ителә. Бу очракта аерым этносның характеристикасы, аның иҗтимагый үсешенең үзенчәлекләре үзләре генә түгел, ә күп гасырлар чиктәш яки уртак территориядә үзара тыгыз бәйләнештә яшәүче халыклар системасында карала. Алда әйтелгәннәр миңа бу тикшеренүне үз дәверендә полиэтник составлы халыкка ия булган (монда Казан татарларының, мишәрләрнең, чуваш, нугай, башкорт, мари, удмурт, мордва һәм башкаларның борынгы бабалары яшәгән) Казан дәүләте (? — XVI гасыр) территориясе белән чикләргә мөмкинлек бирде.

Бу хезмәтнең максаты — Казан ханлыгындагы этносоциаль процессларны комплекслы өйрәнү (Казан дәүләте тарихында «ханлык» чорының башын мин шартлы рәвештә XV гасыр башында Урта Идел буе территориясендә Олуг Мөхәммәд урдасы барлыкка килүгә бәйлим, бу турыдан-туры историографик традицияләргә бәйле. Мәсәлән, М.Худяковның 1923 елда басылган «Очерки по истории Казанского ханства» хезмәтен кара). Моннан хезмәтебезнең төп мәсьәләләре килеп чыга: 1) Казан ханлыгы барлыкка

килгән этносоциаль нигезне тикшерү; 2) Казан ханлыгы халкының этносоциаль үсешенә хас төп тенденцияләрне өйрәнү. Бу мәсьәләләрне бергә туплап карау безгә Казан ханлыгының этносоциаль тарихын комплекслы һәм бербөтен рәвештә торгызырга мөмкинлек бирәчәк.

# КАЗАН ХАНЛЫГЫ ТАРИХЫ БУЕНЧА ТӨП ЧЫГАНАКЛАР ҺӘМ ӘДӘБИЯТ

## 1. Төп чыганаклар

Чыганакларның җитешмәве, беренче чиратта язма чыганакларның аз булуы Казан ханлыгы тарихын өйрәнүне шактый кыенлаштыра. Бу чорны тикшерүчеләр бары тик рус елъязмалары, илчелек китаплары, күчермә китаплардагы мәгълүматларга, рус гаскәр башлыкларының һәм чит ил сәяхәтчеләренең истәлекләре һәм язмаларына, берничә хан ярлыгына, Казан ханы Сафа Гәрәйнең Бөек Литва князьлеге хакимнәренә язган хатларының тәрҗемәләренә һәм матур әдәбият жанрындагы берничә әсәргә генә мөрәҗәгать итә алалар. Казан ханлыгында тупланган чыганаклар байлыгы дәүләт язмышын кабатлый. 1552–1556 елларда илнең Иван IV гаскәрләре тарафыннан яулап алынуы аның архивларында саклап калган борынгы төрки, болгар һәм Алтын Урда мирасын гына түгел, аның үз тарихын чагылдырган документларны да юк итүгә китерә. «Казан ханлыгы тарихына караган язма чыганаклар 1552 елда Казанны алганда тулысынча диярлек юкка чыкканнар», — дип язды С.О.Шмидт.

Казанда 1467 елдан 1479 елга кадәр идарә иткән Ибраһим ханның тархан ярлыгы күчермәсе — сакланып калган чыганаклардан Казан ханлыгы чорына караган әһәмиятле татар чыганагы. Бу документ Үзәк дәүләт борынгы актлар архивы (хәзерге РГАДА) фондларында КДУ аспиранты Р.Н.Степанов тарафыннан 1963 елда табыла. Бу документ Мәскәүгә 1685 елда эләккән, ярлык ияләре токымыннан булган Казан өязенең Тыңламас авылы кешесе Котлымөхәммәд Котлыгышев аның нәселенә әле «мөселман хакимнәре» тарафыннан ук бирелгән өстенлекләрне озайтуын сорап, үзендә сакланган ярлыкның күчермәсен рус патшасына җибәргән була (ярлык Котлыгышевлар нәселенә 1398 елда солтан Хәйдәр Гали тарафыннан бирелгән була, соңрак Ибраһим хан аны озайта). Патша канцеляриясе өчен ярлык күчермәсен тылмач Артык Иманаев рус теленә тәрҗемә иткән.

Ибраһим ярлыгы күчермәсенең беренче фәнни басмасын М.Г.Госманов, Ш.Ф.Мөхәммәдьяров, Р.Н.Степанов 1965 елда «Казан утлары» журналы битләрендә чыгаралар. Журналда документның фотокопиясе, транскрипциясе, хәзерге татар теленә тәрҗемәсе һәм сүзлек бирелә. Авторлар бу чыганакның оригинальлеген, аның Казан дәүләтенең иҗтимагый структурасын һәм аннан алдагы чорның (авторларда — Болгар чоры) иҗтимагый сәяси тарихын ачарга ярдәм итәрлек күпсанлы терминнарга бай булуын билгеләп үткәннәр иде.

Казан тәхетен 1521–1524 елларда биләгән Сәхиб Гәрәй ханның тархан ярлыгы да Казан ханлыгы чорының кыйммәтле чыганагы булып тора. Сәхиб Гәрәй ярлыгы шулай ук раслаучы тархан ярлыклары төркеменә карый. Аны татар археографы һәм этнографы Сәид Вахиди 1912 елда Казан губернасы Мамадыш өязенең Мамалай авылында таба. Фәнни хезмәт язганда ярлык тексты беренче тапкыр Һади Атласиның «Казан ханлыгы» китабында 1914 елда кулланыла. С.Г.Вахиди текстны беренче тапкыр җентекле комментарийлар белән рус һәм татар телләрендә 1925 елда бастырып чыгара. Үзенең тикшеренүе турында Сәид Вахиди 1925 елның 17 маенда Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте һәм Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыятенең берләштерелгән утырышында чыгыш ясый.

Хәзерге вакытка ярлыкның иң тулы археографик анализы Шамил Мөхәммәдьяров хезмәтләрендә бирелгән[1].

Казанда 1487–1495 һәм 1502–1518 елларда хакимлек иткән Казан ханы Мөхәммәд Әминнең тархан ярлыгы булуы да безгә билгеле. Ул Риза Фәхретдиндә сакланган һәм 1911 елда патша жандармериясе аның кулъязмаларын конфискацияләгәндә югалган. Бу югалту турында галим «Шура» журналының 1912 елның 22 нче номерында махсус хәбәр итә. Казан архивларында галимнең кулъязмаларын конфискацияләү турында мәгълүмат бар, дип белдерә Миркасыйм Госманов.

Казанда 1524–1531, 1533–1546, 1546–1549 елларда идарә иткән Сафа Гәрәй ханның Польша короле һәм Бөек Литва князе Сигизмунд I гә язган хатларының тәрҗемәләре шулай ук Казан ханлыгы тарихы буенча әһәмиятле чыганаклар. Чыганаклар Бөек Литва князе канцеляриясендә сакланган. Польша Республикасының Дәүләт архивлары генераль дирекциясе бу документларның ксерокопияләрен Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе җитәкчесе Д.Р.Шәрәфетдиновка 1996 елда Польшада бүләк итеп биргән иде. Текстны искәрмәләр һәм хәзерге рус теленә тәрҗемәсе белән Д.Г.Мостафина 1997 елда бастырып чыгарды.

Бу актлар XVI гасырның 30–40 нчы еллары вакыйгаларына Казан ханлыгының сәяси юнәлешен турыдан-туры билгеләүче Казан ханы карашын чагылдыралар һәм Урта Иделдәге татар дәүләтенең халыкара урынын, аның эчке халәтен, аерым алганда, этнодемографик үсешен һ.б. күрсәтәләр.

Казан ханлыгы тарихының әһәмиятле чыганаклары төркеменә татар шәҗәрәләрен кертергә була. Аларны ачыклау һәм язып алу белән күп кенә татар галимнәре шөгыльләнгән, шул исәптән Каюм Насыйри, Риза Фәхретдин, Миркасыйм Госманов, Марсель Әхмәтҗанов.

Казан ханлыгының этносоциаль тарихын торгызуда башкорт шәҗәрәләре дип йөртелгән һәм башлыча Раиль Кузиев хезмәтләрендә анализланган шәҗәрәләр зур әһәмияткә ия. Ләкин фактологик материалга бай булган татар һәм башкорт шәҗәрәләре еш кына аларның хуҗаларының билгеле амбицияләре белән тудырылган ялган информацияне дә үз эчләренә алуын искәртеп үтәсе килә (бигрәк тә XIX–XX гасырлардагы күчермәләр турында сүз йөрткәндә).

«Зафәр намә-и вилаят-и Казан» Казан ханлыгы чорының мөһим чыганагы булып тора. Ул Казанда яшәгән Әстерхан татары Шәрифи Хаҗитархани тарафыннан (аның мәшһүр Казан сәиде Кол Шәриф булуы ихтимал) 1550 елда язылган һәм төрек солтаны Сөләйманга җибәрелгән. 1965 елда Зәки Вәлиди бу язманы Төркиянең Кутахья өлкәсенә караган Зәйтиногуллары ильчи Таушанлы китапханәсе фондларындагы бер кульязма җыентыгында таба. Зәки Вәлиди бу документны бастырып та чыгара, ләкин тәрҗемә һәм аңлатмаларсыз. Соңрак чыганакны төрек галимәсе Мелек Үзйетгин бастырып чыгара, ул үз басмасында материалны төрек теленә тәрҗемә итә, аерым сүзләр һәм оригиналь теле турында грамматик кушымта бирә. 1995 елда «Идел» (№1) һәм «Гасырлар авазы — Эхо веков» (май) журналларында чыганакның татар һәм рус телләренә тәрҗемәләре дөнья күрде.

Раритетта Иван IV нең 1549–1550 елларда Казанга яу белән килүе турында сүз бара. Рус гаскәре җиңелүенең чын сәбәпләрен аңлатудан башка (рус елъязмаларында яуның уңышсызлыгы кинәт һава шартларының бозылуы — яңгырлар, җепшеклекләр белән аңлатыла иде) кульязмада тарихи шәхесләр исемнәре, урын атамалары һәм башка мөһим мәгълүматлар китерелә. Документ ул елларның шаһиты тарафыннан язылуы белән аеруча кыйммәтле.

Дәүләт өчен борылыш моменты, критик чор булган яулап алу алдындагы елларда яшәгән талантлы татар (төгәлрәк әйткәндә — болгар) шагыйре Мөхәммәдьяр поэмалары шулай ук Казан ханлыгы тарихын чагылдырган чыганаклар буларак кызыклы. Шагыйрьнең иҗаты XIX гасырның беренче яртысында И.Н.Березин эшчәнлеге аша фән дөньясында таныла. Ул Санкт-Петербургның Азия музее китапханәсенең кульязмалар фондында Мөхәммәдьяр тарафыннан якынча 1540 елда иҗат ителгән «Төхфәи мәрдан» поэмасы кульязмасын таба һәм аның кыскача тасвирламасын бастыра. 1857 елда «Төрек кавеменең халык мәкальләре» хезмәтендә И.Н.Березин поэмадан өзекләр китерә. 1939 елда Ленинградта СССР Фәннәр академиясенең Шәрыкне өйрәнү институты китапханәсенең кульязмалар бүлегендә Б.Ягъфәров Мөхәммәдьярның якынча 1541 елда язылган «Нуры содур» поэмасы кульязмасын таба. Соңрак Мөхәммәдьяр поэмаларының фән өчен яңа булган күчермәләре берничә кат табылды, бу турыда матбугатта махсус хәбәр ителеп килende. Мөхәммәдьяр поэмаларын бастырып чыгару һәм аларны һәрьяклап критик анализлау узган йөзьеллыкның икенче яртысында кат-кат башкарылды.

Казан тарихына караган язма чыганаклар белән беррәттән татар фольклоры һәм археологик чыганаклар зур кызыксыну уята. XV–XVI гасыр фольклор әсәрләреннән «Идегәй», «Алпамыш», «Чура батыр», «Ханәкә Солтан бәете» һ.б. кебек художестволы образлар белән беррәттән Алтын Урда, Казан һәм башка татар ханлыклары тарихыннан чынбарлык вакыйгаларын тасвирлаган эпик әсәрләрне билгеләп үтәргә мөмкин.

«Чура батыр» дастанына кыскача тукталыйк. Аның берничә варианты бар. Аларның күбесе 1890–1930 елларда Россиядә һәм аннан читтә язып алынган. Х.Пасойя мәгълүматларына караганда, «Чура батыр» дастанын башкорт Әбүбәкер Диваоглу беренче булып барлый һәм 1895 елда Ташкентта бастырып чыгара. Дастанны язып алучы икенче кеше В.В.Радлов булгандыр, мөгаен. Татарлар үзләре цензура таләпкиртәләре аркасында риваять-дастанның тулы текстын бик соңлап бастырып чыгаралар («Татар халык иҗаты: Дастаннар», 1984).

Бу чыганак 1552 елга кадәрге чордагы Казан һәм Кырым ханлыкларының эчке һәм тышкы сәясәте вакыйгаларын тасвирлый. Дастан текстында ул вакыйгаларда катнашучы билгеле шәхесләр турында мәгълүматлар күп. Эпик Чура батырның үзен тикшеренүчеләр рус елъязмаларында 1526 елда искә алынган Чура Нарыйковка тиңлиләр. Рус елъязмаларындагы (беренче чиратта Никон/Патриарх һәм Казан елъязмалары) мәгълүматлар буенча, «князь» Чура Нарыйков 1526–1546 елларда Казанда яшәгән һәм Казан ханлыгының сәяси тормышында актив катнашкан.

Каюм Насыйри, Гали Рәхим, Һарун Йосыпов, Фәрит Хәкимҗанов, Җәмил Мөхәммәтшин хезмәтләрендә анализланган эпиграфик һәйкәлләр Казан ханлыгы тарихы буенча әһәмиятле археологик чыганаклар булып торалар. Бу кабер ташлары безгә XV–XVI гасырларда татарларның таралу урыннарын шактый төгәл күзалларга мөмкинлек бирә. Альфред Халиков, Әзһәр Мөхәммәдиев, Равил Фәхретдинов, Фаяз Хуҗин, Альберт Борһанов, Илгизәр Газимҗанов, Айрат Ситдыйков һ.б. басмаларында Казан һәм

Казан ханлыгы турында кызыклы материаллар бар. Ләкин, кызганычка күрәдерме, Казан һәм башка өлкә археологларының археологик тикшеренү материаллары нәтиҗәләре әлегә бергә тупланмаган, алар турында публикацияләр төрле басмаларда таралган. Казан ханлыгы чоры буенча этнографик һәм лингвистик материал турында шуны ук әйтергә мөмкин — мәкаләләр һәм җитди монографияләр шулкадәр күп, хәтта аларның барысы белән дә танышып чыгу мөмкин дә түгел. Шулай ук безнең өчен бик мөһим материалларга ия булган башкорт, мари, мордва, нугай, удмурт, чуваш тикшеренүчеләренең күпсанлы басмаларын да билгеләп үтәргә кирәк.

Казан ханлыгы тормышын турыдан-туры чагылдырган татар чыганакларының әһәмияте никадәр зур булмасын, бу дәүләт тарихын аларга гына нигезләнеп төзеп булмый. Шуңа күрә илнең тарихын өйрәнүдә шул чор рус чыганаклары аерым кыйммәткә ия. Ш.Ф.Мөхәммәдьяров дөрес билгеләгәнчә, «рус чыганакларын кулланмыйча Казан татарлары буенча бер генә тарихи тикшеренүне дә башкару мөмкин түгел».

Казан ханлыгы тарихы буенча әһәмиятле материаллар рус мәдәниятенең искиткеч истәлекләрендә — елъязмаларда сакланган. Казан патшалыгы тарихы Мәскәү елъязмалары җыентыгында, аерым алганда Никон елъязмасында бигрәк тә тулы чагыла. Төньяк-көнчыгыш Русьның эре үзәкләрендә эшләгән башка елъязмачылар көнчыгыш күршеләре белән мөнәсәбәтне яктыртуны максат итеп куймыйлар. Мәскәү елъязмачыларының Казанга карата булган кызыксынулары исә татарлар белән көрәш Мәскәү дәүләте өчен Көнчыгышта алып барган сәясәтнең иң мөһим мәсьәләләренең берсе булуы белән аңлатыла.

Ул еллардагы рус елъязмаларыннан бигрәк тә Никон/Патриарх елъязмасын һәм Казан елъязмасын аерым карарга кирәк.

Никон елъязмасы XVII гасырның мәшһүр чиркәү эшлеклесе патриарх Никонныкы булган күчермәләренең берсе буенча шулай аталып йөртелә. Фәнни әдәбиятта Никон исеме белән йөртелгән елъязмалар җыентыгы XVI гасырның 20 нче еллары ахырында митрополит Даниил Рязанец тарафыннан төзелә һәм рус урта гасыр историографиясендә киләчәк елъязмаларга нык тәэсир иткән зур вакыйга була. Бу истәлек белән актив кызыксыну беренче чиратта аның рус тарихы һәм өлешчә күрше халыклар тарихы буенча мәгълүматларның иң тулы җыелмасын тәшкил итүе һәм башка чыганаклар буенча билгесез булган бербөтен хәбәрләр комплексын китереп җиткерүе белән аңлатыла.

Бу истәлекле язма фәнни әйләнешкә В.Н.Татищев тарафыннан кертелә, елъязманың исемен дә ул куя. «История Российская» хезмәтен язганда кулланылган «күчермә һәм монускрипларны» санаганда, В.Н.Татищев Никон яки «Никон патриарх кул куйган» һәм 1630 ел вакыйгаларынача алып барылган Воскресение монастыре елъязмасын да искә ала.

Елъязманы Татищев кулланган күчермәсе буенча беренче тапкыр 1767–1792 елларда Санкт-Петербургта А.Л.Шлецер һәм С.Башилов бастырып чыгаралар. Күчермә Шлецер тарафыннан да Никонныкы дип исемләнә, һәм шуннан соң бу атама фәнни әдәбиятта бөтен елъязмага карата беркетелә.

Рус елъязмаларының тулы җыентыгын бастырганда, Никон елъязмасының башка (яңа) күчермәләре дә кулланыла («Полное собрание русских летописей». — Т. IX–XIII. — СПб., 1862–1910). Әле Шлецерга ук билгеле булган, XVI гасырның 50 нче елларында митрополит Макарий соравы буенча төзелгән Патриарх күчермәсе басманың нигезен тәшкил итә, аңа Воскресение елъязмасыннан һәм «Патша һәм бөек князь Иван Васильевичның патшалык итә башлау елъязмасы»ннан өзекләр кертелә (Рюриковичларның чыгышлары белән легендар Рим императоры Август нәселеннән булулары турында кереш һәм 1520 елдан соңгы вакыйгалар турындагы өлешләр өстәлгән).

Никон елъязмасын моннан соң тикшерү шактый вакыт аның чыганакларын анализлау юнәлешендә барды. И.А.Тихомировның «Обозрение летописных сводов Руси северо-восточной» (1898 ел басмасы), Н.П.Лихачевның «Палеографическое значение бумажных водяных знаков» (1899), С.Ф.Платоновның «К вопросу о Никоновском своде» (1902), А.А.Шахматовных «Разыскания о древнейших русских летописных сводах» һәм «Обозрение русских летописных сводов 14–16 вв.» (1908, 1930), Н.Ф.Лавровның «Заметки о Никоновской летописи» (1927), С.П.Розановның «Никоновский летописный свод. Иоасаф как один из его составителей» (1930), Д.С.Лихачевның «Русские летописи и их культурно-историческое значение», А.Н.Насоновның «Летописные памятники хранилищ Москвы» һәм «История русского летописания» (1955, 1969), А.Г.Кузьминның «К вопросу о времени создания и редакциях Никоновской летописи» (1963), Я.С.Лурьеның «Общерусские летописи 14–15 вв.» (1976), Б.М.Клосcның «Никоновский свод и русские летописи 16–17 вв.» (1980) кебек хезмәтләрне атап үтәргә мөмкин.

Югарыда әйтеп үтелгән тикшеренүләр Никон (Патриарх) елъязмасының чыганакларын ачыклап кына калмадылар, ә елъязманың язылу урыны, аның төзүчесе, бу җыентыкның иҗтимагый-сәяси юнәлтелгәнлеге, кайбер мәгълүматларының уникальлеге, җыентыкның соңгы күчермәләрен формалаштыру

тарихы кебек авыр сорауларга да җавап бирделәр. Тикшеренүчеләрнең иң дәлилле нәтиҗәләрен кыскача бәян итик.

*Никон елъязмасының барлыкка килү урыны.* Никон елъязмасының төзелү урынын билгеләгәндә, тикшеренүчеләр беренче чиратта җыентыкның чиркәү әһелләре язмаларына хас булуына игътибар иттеләр. Елъязмада даими рәвештә чиркәү тормышы белән бәйле булган вакыйгалар билгеләп үтелә, язмада үгет-нәсихәт, моральгә зур урын һәм дини әдәбияттан, Библиядән өзекләр бирелә, текстка рус православие чиркәве изгеләренең тормыш юлын сурәтләүче кисәкләр урнаштырыла. Никон елъязмасын төзүченең чиркәү белән бәйле булуы җыентыкны иҗат итүне патриарх Никонга бәйләгән В.Н.Татищевтан башлап елъязманы иң соңгы булып өйрәнүче галимнәрнең берсендә дә шик тудырмый. Истәлекнең гомуми анализы Никон җыентыгы тупланышын Мәскәү митрополиты кафедрасы белән бәйләргә мөмкинлек бирә.

*Төзүченең шәхесе.* Никон елъязмасының төзүчесе-редакторы турында алынган мәгълүматлар тулысынча 1522–1539 елларда митрополит тәхетен биләгән Даниил шәхесенә туры килә. Рус чиркәве башлыгы буларак, Даниил дәүләттә югары һәм җаваплы урын биләгән һәм бу аңа борынгы китаплар һәм архив документлары белән файдалану мөмкинлеген тудырган. Даниилның даими рәвештә сәясәт белән кызыксынуын (аерым алганда ул дөньяви рус хакимиятенең Казан ханлыгына карата алып барылган экспансия сәясәтен тулысынча хуплаган) һәм ортодоксаль юнәлештәге сугышчан чиркәү эшлеклесе булуын (сүз ересь белән көрәш, чиркәүнең милек мәнфәгатьләрен яклау турында бара) искә алсак, күп кенә тарихи вакыйгаларны аңлатуда берьяклылык белән сугарылган гомумрус елъязмасын төзүдә аның катнашуы аңлашыла. Өстәвенә Даниил үз заманының белемле һәм укымышлы мәшһүр язучысы була.

*Никон елъязмасының чыганаклары.* Тикшерүчеләр тарафыннан Никон елъязмасы чыганакларының шактый зур төркеме билгеләнгән. Аларның барысын да санап чыгу безнең өчен үзмаксат түгел, шуңа күрә бу проблемага кыскача экскурс белән чикләник. Никон елъязмасы чыганакларын берничә төркемгә бүләргә мөмкин: Лаврентьево-Троицк төркеме чыганаклары, Новгород-София чыганаклары, Ростов төркеме, Бөек Мәскәү кнәзе җыентыклары, хронографлар, шәҗәрәләр. Лаврентьево-Троицк төркеме чыганаклары беренче чиратта Лаврентьево елъязмасы (1305 елга кадәр) һәм Троицк елъязмасының ике төрдәге Тверь эшкәртмәләре (Симеон елъязмасы һәм Владимир елъязмачысының төп чыганагы) белән күрсәтелгән. Новгород-София төркеме чыганаклары 5 нче Новгород елъязмасы (1445 елгача) һәм Никон елъязмасын төзегәндә ярдәмчел чыганак сыйфатында кулланылган 1 нче София елъязмасы белән чагылдырылган. Ростов төркеме чыганаклары Ермолин елъязмасы (бөек князь җыентыгының XV гасырның 70 нче елларындагы Ростов редакциясе), 1477 елгы елъязмалар җыентыгы, Мәскәү Академик елъязмасы составында Ростов җыентыгы (1419 елга кадәр), XV гасырның 70 нче елларының кыскартылган җыентыгы (Устюг елъязмачысының төп чыганагы), Типография елъязмасы (нигезләрен 1489 елның Ростов җыентыгы тәшкил иткән берничә редакциядә), кыскартылган 1493 елгы җыентык (Погодин елъязмасы) һәм 1495 елгы җыентык (Мазурин елъязмасы) белән күрсәтелгән. Бөек Мәскәү кнәзе җыентыклары 1477 елгы елъязмалар җыелмасындагы җыентык, 1479 елгы Мәскәү җыентыгы, Лихачев елъязмасы составындагы җыентык (1477–1488 еллар фрагменты) һәм Никон елъязмасын төзегәндә нигездә башка чыганакларны төзәтү өчен кулланылган 1493 елгы Мәскәү җыентыгы белән күрсәтелгән. Никон елъязмасының Тверь чыганагы 1414 елга кадәр алып барылган һәм Бөек Тверь кнәзе җыентыгының Кашин редакциясен чагылдырган (аның күп мәгълүматлары Никон елъязмасында чиста рәвештә түгел, ә башка чыганаклар мәгълүматларына кушып кулланылган). Никон җыентыгында хронографик материалның ике төре кулланылган. Шуларның берсе — рус хронографының (1516–1522 еллар редакциясе фәндә «1512 ел редакциясе» дигән исем белән беркетелгән) беренчел редакциясе. Көнбатыш-рус хронографы (аның беренчел редакциясе Никон елъязмасы белән якынча бер үк вакытта һәм бер үк даирәдә туа) Никон елъязмасының башка чыганагы булып тора.

Князьләр исемнәре белән бергә бирелгән тәфсилле шәҗәрәләр Никон елъязмасының аермалы үзенчәлеге булып тора. Бу мәгълүматлар укучыга нәсел агачын аңлату өчен бирелгән тарихи белешмәләр генә булып калмыйча, билгеле бер сәяси максатка хезмәт итәләр, алар Мәскәү князьләренең нәсел агачының олылыгы идеясен раслыйлар һәм аннан башка барлык рус җирләренең берлеге турында карашларны нигезлиләр (ягъни, гомумән алганда, Мәскәү — барлык рус җирләренең башкаласы, ә Мәскәү хакимнәре ул чорда төрле дәүләтләр составында булган барлык рус халкының хакимнәре дигән фикер алга сөрелә). Никон елъязмасында Архангел җыентыгыннан, 1479 елгы Мәскәү җыентыгыннан, Литва елъязмасыннан, «Литва князьлеге шәҗәрәсе»ннән, литва князьләренең башка шәҗәрәләреннән (алар, мәсәлән, Воскресение елъязмасында бар), бөек рус князьләренең нәсел башында Рим императорлары булу турындагы Чудов повестеннан, Спиридон-Савва посланиесеннән һәм башка чыганаклардан тарихи-генеалогик материаллар кулланыла.

Күрүебезчә, Никон елъязмасының чыганакларын хәтта өстән-өстән генә күзәтү дә аны төзүченең тирән белемле кеше булуы турында сөйли. Ләкин бер җитди моментны билгеләп үтәргә кирәк: тикшеренүчеләрнең күбесенең фикеренчә, Никон елъязмасын төзүче чыганак материаллары белән еш кына бик ирекле эш иткән. Елъязмачы каләме чыганаклар текстын кайвакыт шактый дәрәҗәдә үзгәрткән. Еш кына вакыйгаларда катнашучыларның этник чыгышы бозып күрсәтелгән (мәсәлән, Мстислав Храбрый воеводасы Ярун «кыпчак князе»нә әйләнгән), тарихи хикәяләргә яңа (ышанычлымы?) исем һәм фактлар өстәлгән (мәсәлән, легендар Кийның Идел буе болгарларына походы турында; Владимирның, имеш, 994 һәм 997 елларда болгарларны җиңүе турында; янәсе, Дмитрий Константинович 1375 елда Болгарга, Казанга яу белән баруы нәтиҗәсендә «Казанда ... юл һәм таможник» куя алган; 1555 ел алдыннан, имеш, Рюрик һәм аның токымы бик электән, әле Казан ханлыгы барлыкка килгәнче үк, Идел-Кама халыкларыннан ясак җыйганнар дигән хәбәр китерелә). Чыганак текстларын болай бозу — митрополит Даниилның иҗтимагый-сәяси карашлары һәм идеяләре җимеше (күчереп язучыларның техник хаталарын да бөтенләй үк читтә калдырырга ярамаса да). Шуларны карап, тикшерүгә керешик.

*Никон елъязмасын төзүченең иҗтимагый-сәяси карашлары*. Тикшеренүчеләр фикеренчә, бу чыганак текстында митрополит Даниилның Рус дәүләтенең XVI гасырның 20 нче елларындагы эчке һәм тышкы сәясәтенә булган карашлары аеруча ачык чагылган. Аларны түбәндәге юнәлешләргә төркемләп була: митрополия кафедрасының милек мәнфәгатьләрен яклау, дини һәм дөньяви хакимиятнең үзара мөнәсәбәтләре, ересь белән көрәш, Рязань князьлеге тарихына үзенчәлекле караш, рус-литва мөнәсәбәтләре, Русьның Казан ханлыгы белән көрәше. Аларны кыскача карап үтик.

*Митрополия кафедрасының милек мәнфәгатьләрен яклау.* Даниилның митрополия кафедрасына билгеләнүе Мәскәү митрополия йортының иммунитетын киңәйтүгә китерә. Даниил алга таба да митрополия йортыныкы булган җир биләмәләренә өстенлек хокукларын ару-талусыз яклап килә, 1527–1528 еллардагы җир актлары копияләренең Митрополия Китабын төзү дә шуңа бәйле. Никон елъязмасында да шул ук максат күздә тотыла һәм чиркәү милкенең кагылгысыз булуы турында фикер алга сөрелә. Текстны төзүче һәр кулай очракта митрополия кафедрасы биләмәләрен искә ала һәм аларның борынгыдан килүче тарихи традицияләрен ассызыклый.

*Дөньяви һәм дини хакимиятнең үзара мөнәсәбәтләре.* Митрополит Даниил «руханилык» һәм «патшалык» гармониясен һәм илаһи билгеләнүен агитацияләүгә бар көчен куя. Никон елъязмасында бөек князьләрнең митрополит һәм епископлар белән «совет да любовь» мөнәсәбәтләрендә булуларына күпсанлы мисаллар бар. Җыентык битләре бөек «князь со отцем своим митрополитом» яки «по благословению отца своего митрополита», митрополит исә «с сыном своим» яки «с сыном своим возлюбленным о Христе — великим князем» дигән гыйбарәләр белән чуарланган. Әле В.Н.Татищев тарафыннан ук билгеләп үтелгән бер үзенчәлек кызыклы: «Башка чыганакларда очраган дин әһелләре хакимиятен кимсетүче барлык вакыйгалар Никон елъязмасында төшерелеп калдырылган яки үзгәртелгән һәм яңача язылган. Мәсәлән, башкаларында «посла князь или повеле князь митрополиту или епископу» дип язылган урыннарда ул (төзүче) «и моли князь отца своего митрополита или епископа» дип язган».

*Ересь белән көрәш.* Максим Грекны хөкем иткән 1525, 1531 еллар соборларын оештыру һәм үткәрү митрополит Даниил эшчәнлегенең мөһим этабы булып тора. Әйтеп үтелгән ике собор арасында төзелгән Никон елъязмасында еретикларга каршы тәнкыйть бик күп урнаштырылган. Максим Грекның чиркәү тормышына бәйле карашларын нейтральләштерү максаты белән кайбер махсус мәкаләләр урнаштырылган. Үз алдына куйган максатларыннан чыгып, Даниил билгеле булган чыганакларның берсендә дә аналоглары очрамаган мәгълүматларны да Никон елъязмасына кертә. Мәсәлән, 1004 ел алдыннан елъязмада болай дип өстәлгән: «Того лета митрополит Леонт посади в темницу инока Андрияна, скопца. Укоряше бо сей церковные законы, и епископы, и презвитеры, и иноки; и помале исправися, и прииде в покояние и в познание истины, якоже и многим дивитися кротости его, и смирению, и умилению».

*Рязань князьлеге тарихына мөнәсәбәте.* А.Г.Кузьмин Никон елъязмасын төзүченең Рязань князьлеге тарихына артык игътибар итүен билгели. Бу игътибар елъязмага безгә билгеле булган башка елъязма җыентыкларында очрамаган Рязань тарихына кагылышлы күпсанлы мәгълүматлар кертүгә генә кайтып калмый, ә күпчелек гомумрус эчтәлекле текстларны Рязань яклы эшкәртмәдә (ләкин Мәскәү ягына зыян китермичә!) бирүдә чагыла. Бу хәл ике төп сәбәп белән аңлатыла: 1) XVI гасырның бер рәт чыганаклары митрополит Даниилның чыгышы белән Рязаньнан булуын күрсәтә («Даниил, по реклу рязанец», «Даниил рязанец» һ.б.); 2) җыентыкны төзүче XVI гасырның 20 нче елларындагы сәяси хәлне истә тота, ул вакытта Рязань князьлеге Мәскәү князьлегенә әле яңа гына буйсындырылган була, һәм бу актны аклау өчен бөек Мәскәү князьләрен бөтен рус җирләрен берләштерүчеләр итеп күрсәтү кирәк була.

*Рус-литва мөнәсәбәтләре.* Князьләр исемнәренә Киев һәм Владимир-Суздаль бөек князьләренә китереп җиткерелгән шәҗәрәләр өстәүне Мәскәү князьлегенең Литва җирләренә дәгъва итүе белән

аңлатырга мөмкин. Аяусыз рус-литва көрәшенә сәбәпче булган Смоленск князьлегенә хәтта аерым бер мәкалә багышланган. Никон елъязмасы төзүчесенең генеалогик экскурслары чиста тарихи белешмә бирүдән башка Литва дәүләтенең көнчыгыш җирләренең Русьныкы булуын күрсәтүне күздә тотуы көн кебек ачык. Бу мәгънәдәге үзенчәлекле өстәмә Никон елъязмасында 1415 ел алдыннан китерелә. Бөек Литва князе Витовтның: «Киев и вся страна Киевская в моеи области есть», — дип белдерүенә каршы җыентыкны төзүче ихтыяры буенча епископлар болай дип җавап бирәләр: «Но преже не твоя область бысть»... Воскресение елъязмасында язылганча, 1534 елда Даниил Литвага каршы сугыш ачу уңаеннан бөек князь Василий III янына киңәшкә чакырылган була. Митрополит бу ниятне хуплый һәм гаскәрләргә үзе фатиха бирә.

*Русьның Казан ханлыгы белән көрәше.* XVI гасырның 20 нче елларында татарларга каршы, аерым алганда Казан татарларына каршы, сугыш мәсьәләсе Мәскәүдә кискен тора. 1523 елгы яу вакытында Василий III әмере буенча Сура елгасы тамагында Казанга һөҗүмнең иң беренче плацдармы булып киткән шәһәр-кальга Васильсурск төзелә. Бөек князьнең Казанга карата алып барылган басып алу сәясәтенең митрополит Даниил тарафыннан тулысынча хуплануын Берсень Бәкләмишев һәм Федор Жареныйны тикшерү делосыннан күреп була. Берсень: «Яз у митрополита был и сидел есми у него один на один, и митрополит великому князю велику хвалу въздает, что город поставил, тем деи городом всю землю Казанскую возьмет», — дип белдерә. Ләкин 1524 елда Казан ханы Сәхиб Гәрәй, геополитик максатлардан чыгып, үзен Төркиянең номиналь вассалы дип таный һәм Казан ханлыгын төрек солтаны «йорты» дип игълан итә. Мәскәүдә Искәндәр солтан илчесенә бу уңайдан «изначала на тот юрт царей сажаем мы из своих рук» һәм «то изначала юрт государя нашего» дип белдерелә. Ул чорның дипломатик документларында Василий III тулы титул белән атап йөртелгән, бу титул буенча ул «князь Болгарский» булып та саналган. Рус князьләренең Казанга хокукларының электән килгәнлеген исбатлау өчен Никон елъязмасына башка билгеле чыганакларда тиңнәре булмаган мәгълүматлар кертелә, янәсе, әле легендар Кий үк «на Волжскиа и Камскиа Болгары ходив и победи», ә «в лето 6505 (997) ходи Володимер на Болгары Воложскиа и Камские, и, одолев, плени их». Б.М.Клосс фикеренчә, «[Никон елъязмасы составына] Идел буе болгарларына каршы походлар турында мәгълүматлар кертү тулысынча XVI гасырның 20 нче елларында, Никон елъязмасы төзелгән чорда Мәскәү хакимияте тарафыннан Казанга карата алып барылган басып алу сәясәте белән аңлатыла». Минемчә, елъязмада даими рәвештә «болгары» һәм «иже ныне глаголются Казанцы» бер үк халык булуларын искәртү, ягъни «әгәр без күп тапкырлар Идел буе болгарларын яулап алганбыз икән, ә нәкъ менә алар хәзер үзләрен казанлылар дип атап йөртәләр, димәк, казанлылар дәүләте — Казан ханлыгы (елъязмаларда — «царство», «земля») безнеке булырга тиеш» дигән фикер үткәрелүен дә шуның белән аңлатырга була. (Кызыклы мантыйк! Аннан чыгып эш итсәң, Урта Азия — грекларныкы, Испания — гарәпләрнеке, Англия норманнарныкы булырга тиеш һ.б.) 990 елларда булган дип фараз ителгән вакыйгалар турында хәбәр иткәндә дә Никон елъязмасын төзүче шуңа охшаш максаттан чыгып эш итә. Бу өзекне тулысынча китерик: «В лето 6498... Того же лета посла Володимер философа, нарицаемого Марка Македонянина, в болгары, иже есть в агаряны, иже Измаилтене глаголются и Срацини, яко от Сарры наречени от свободныя, яко Агарь раба бяше Сарре, и по многих именований и бесермени нарицаются, и Тотари, и друзии имена их демонскиа, сице глаголя: «яко приходиша ко мне прежде, егда еще не просвещен бехъ верою православною, хваляще свою веру скверную[2] ... ты же иди к ним, и проповежь им слово Божие, яко да веруют в господа Бога и спаса нашего Исуса Христа, и да крестятся божественным его крещение, и с нами единоверни и единосветни будуть, и небесных благых получат...» Философ же иде в Болгары, и много глаголав им слово Божие... Того же лета приидоша из болгар к Володимеру в Киев четыре князи, и просветишася божественным крещением; Володимер же честова их и много удовольствова». Мин Никон елъязмасындагы бу хәбәрне шик астына куймыйм. Утсыз төтен булмый, диләр. Ләкин бу мәгълүмат бик сагайта. Аның артында рус чиркәвенең Казан ханлыгын яулап алу алдыннан һәм бигрәк тә аннан соңгы чорда гына үзен ачык агрессив сиздергән сугышчан миссионер идеологиясе яшеренүе ихтимал. Бу мәгълүматның митрополит Даниил тарафыннан Никон елъязмасына кертелүе — түбәндәге идеяне алга сөрү ул: «Идел буе болгарларының бер өлеше (өстәвенә аларның феодаль элитасы) чукынуны үзләре теләп кабул иткән икән, димәк, «казанлылар» — болгарлар токымы — христиан диненә кертелергә тиеш». Явыз Иван, Лука Канашевич һәм К° үткәргән крестоносец миссионерлыгы тамырлары менә кайда!

Ачык публицистик юнәлешле тарихи повесть буларак «Казанская история» (варианты: «Казанский летописец») 1564–1565 елларда аноним автор тарафыннан төзелә. Автор сүзләре буенча ул Казан ханы Сафа Гәрәй сараенда әсир буларак яшәгән һәм Казан ханлыгының мөстәкыйль тормышының соңгы 20 елының турыдан-туры шаһиты булган.

Бу чыганак белән кызыксыну тарихчыларда XVIII гасырның икенче яртысында ук туа (1791 елда беренче басмасы чыга), һәм моны беренче чиратта истәлектә Казан дәүләтенең 300 еллык борынгы тарихы, аның Рус дәүләте белән мөнәсәбәтләренең 1552 елда яулап алынуга кадәрге дәвере чагылдырылуы белән аңлатырга мөмкин. Казан ханлыгы тарихы буенча чыганакларның бөтенләй җитешмәү шартларында «Казанская история» текстының башка рус елъязмаларында искә алынмаган вакыйгаларны сурәтләүче зур фрагментлары А.Лызлов, П.Рычков, Н.Баженов, И.Михайлов, Н.Загоскин тикшеренүләрендә киң кулланылды. Кайбер аерым мәгълүматларын В.Татищев, М.Щербатов, Н.Карамзин, В.Вельяминов-Зернов, Ш.Мәрҗани дә куллландылар. Ләкин XIX гасырның икенче яртысында бер төркем тарихчылар Н.М.Карамзин, С.М.Соловьев фикерләренә (ул «Казанская история»не «бик болганчык чыганак» дип атады) һәм В.В.Вельяминов-Зерновның Казан елъязмасы мәгълүматларының шикле һәм текстының компелятив булуын искәртүенә таянып, тарихи чыганак буларак аннан баш тарталар. Бары тик «Казанская история»не «Полное собрание русских летописей» (ПСРЛ) җыентыгында бастыруга әзерләү нәтиҗәсендә туган Г.З.Кунцевичның фундаменталь тикшеренүе генә аның тарихи чыганак булуын билгеле бер дәрәҗәдә аклады. Ләкин Г.З.Кунцевич та Казан елъязмасының «тарихи чыганак буларак бик күп төгәлсезлекләргә, җитешсезлекләргә, хаталарга ия булуын» билгеләп үтәргә мәҗбүр була. Текстның реалийлары нигезендә ул «Казанская история»нең төзелү вакыты 1564–1566 еллар чигендә булуын һәм бер төркем чыганакларын билгеләде. Алар арасында 1512 ел хронографы, Никон, Новгород V, Воскресение, София II һәм Львов елъязмалары, «Патшалык башы елъязмасы», разряд китаплары, космографияләр, христиан әдәбияты, татар риваятьләре бар. «Казанская история»не чыганак буларак өйрәнүне Г.Н.Моисеева дәвам итте. Ул аны авторының Иван IVнең басып алу сугышларын яклаучы үз тарихи-публицистик концепциясен берләштерү өчен беренчел чыганакларны тенденциоз рәвештә эшкәрткән дворян идеологиясе истәлеге буларак иҗтимагый-сәяси юнәлтелгәнлеген тикшерде. Г.Н.Моисеева чыганакның язылу вакытын төгәл билгеләде, 1564–1565 еллар һәм чыганаклар исемлеген илчелек китаплары, шәҗәрәләр белән тулыландырды. Ул шулай ук Г.З.Кунцевичка билгеле булмаган борынгы күчермәнең беренчел редакциясе буенча «Казанская история»не яңадан бастырып чыгарды (М.-Л., 1954).

XX гасырның 60 нчы елларында Казан елъязмасы чит ил галимнәре, бигрәк тә XVI гасырда Казанны яулап алуны рус историографиясендә идеологик нигезләү мәсьәләләре белән шөгыльләнүче Көнбатыш Герман һәм Америка тикшеренүчеләре игътибарын үзенә җәлеп итте. Чыганак аларны рус самодержавиесенең көнчыгышта экспансиясенең иҗтимагый-сәяси һәм дини сәбәпләре һәрьяклап чагылдырган тарихи-әдәби әсәр буларак кызыксындырды[3].

XX гасырның 80 нче елларында «Казанская история»не өйрәнүне Л.А.Дубровина дәвам итте. Ул СССР территориясендә Казан елъязмасының 281 күчермәсе булуын билгеләде. Л.А.Дубровина елъязманың 270 күчермәсен анализлап монография бастырып чыгарды, шуларның 60 ы фәнни әйләнешкә беренче тапкыр кертелгән иде.

Әйтеп үтелгәннәрне гомумиләштереп, «Казанская история»нең Казан ханлыгы тарихы буенча күпсанлы мәгълүматлары булган, ләкин үзенә карата бик игътибарлы һәм тәнкыйди мөнәсәбәт таләп итүче оригиналь (мәсәлән, анда информатор-татарлар турында мәгълүматлар бар) чыганак булуын билгеләп үтәсе килә.

Казан ханлыгы тарихын язу өчен XVI гасырның әдәби, сәяси характердагы рус чыганакларыннан «История о великом князе Московском» аерым кыйммәткә ия. Бу «История...» авторы князь А.М.Курбский 1552 елда Казанга каршы яуда актив катнашкан, һәм ул, вакыйгаларның шаһиты буларак, безгә татар дәүләте тормышының төрле якларын яктырткан кызыклы чыганак калдырган. Без бу хезмәттән Казан ханлыгының сәяси тарихы турында да, аның иҗтимагый-икътисади үсеше турында да мәгълүматлар табабыз. Казан дәүләте халкының этник составын тасвирлау шактый кызыклы, өстәвенә князь илдә дәүләт нигезен тәшкил итүче халыкны («Казан татарлары») һәм Казан ханнарына буйсынучы башка җирле халыкларны, мәсәлән, чувашларны төгәл аера.

XVI гасырның икенче яртысы — XVII гасырларга караган күчермә (писцовый) һәм сан алу китаплары Казан ханлыгы тарихы буенча бик кыйммәтле чыганаклар. Аларның материаллары дәүләт тарихын, аның этник һәм социаль үсешен, административ-территориаль бүленешен ретроспектив яктырту өчен кулланылырга мөмкин. Бу документлар дәүләт тарафыннан иманалы халыкка салым салу, җир биләү һәм крестьяннарга ия булу хокукларын билгеләү максатыннан төзелгән. Писцовый кенәгәләр, нигездә, һәр биләмәдәге крестьян хуҗалыкларына һәм җирләргә тасвирлама була. Мондый китаплар Мәскәүдән урыннарга хакимият тарафыннан махсус җибәрелгән комиссия эшчәнлеге нәтиҗәсендә төзелгән. Бу китапларда кешеләрнең иҗтимагый хәле һәм нинди этник төркемгә каравы шактый төгәл теркәлгән, хәтта еш кына Казан ханлыгының этносоциаль тарихын турыдан-туры чагылдыручы фактлар да китерелә.

Урта Идел буеның күчермә һәм сан алу китапларын, шулай ук алардан өзекләрне бастыру XIX гасырның 70 нче еллары ахырында башлана. Совет чорында чыганак буларак бу китапларга беренче мәртәбә М.Г.Худяков игътибар итә. «Материалы по истории Татарской АССР» (Л., 1932) китабында Казан шәһәренең 1565–1568 һәм 1646 ел күчермә китаплары М.Г.Худяковның «Казань в XV–XVI столетиях» дип исемләнгән кереш мәкаләсе белән бастырылган, анда автор аталган күчермә китапларның беренчесеннән алынган мәгълүматлар белән актив эш итә. XX гасырның 50 нче елларында Ш.Ф.Мөхәммәдьяров тикшеренүчеләр игътибарын бу китапларның чыганак буларак әһәмиятенә кабат юнәлтә. Урта Идел буе күчермә һәм сан алу китапларын комплекслы өйрәнү, аларның текстларын бастыру һәм фәнни әйләнешкә кертү буенча эшчәнлек 70 нче еллар уртасыннан шактый җанланып китә, һәм бу, беренче чиратта, Казан дәүләт университетының И.П.Ермолаев җитәкләгән галимнәре коллективы хезмәте нәтиҗәсе. Шулай ук бу юнәлештә актив эзләнүләр алып барган тарих фәннәре кандидатлары Д.Г.Мостафина һәм Р.Ф.Галләмов эшчәнлеген аерым билгеләп үтәсе килә.

Русьның Нугай Урдасы, Кырым ханлыгы, Төркия белән мөнәсәбәтләрен яктырткан һәм дипломатик характердагы күптөрле материалларның бай тупланмасын тәшкил иткән илчелек китаплары шулай ук Казан ханлыгы тарихы буенча кызыклы мәгълүматлар бирәләр[4]. Кызганыч ки, РГАДА фондларыннан Казан ханлыгы тарихы буенча өстәмә мәгълүмат бирә алырлык түбәндәге материаллар әлегәчә бастырып чыгарылмаган: 123 нче фонд, оп.1 (Россиянең Кырым белән бәйләнешләре), д.6, 7, 9–17, 19, 21–23, 25–60, 62, 64–79, 81, 82; 127 нче фонд, оп.1 (Россиянең Нугай Урдасы белән бәйләнешләре), д. 9–11. Шулай ук, кызганычка каршы, рус архивларында Мәскәү дәүләтенең Казан ханлыгы белән бәйләнешләре буенча документлар сакланмаган. Казан буенча эш кәгазьләре булуы безгә «о Казанских тетратех» турында искәртүләр булган архив документларыннан һәм «Акты, собранные в библиотеках и архивах Российской империи Археографической экспедицией академии наук» җыентыгының I томында бастырылган «Описи царского архива» (1575–1584) документыннан билгеле. Патша архивында Казан ханнарының шартнамә грамоталары, Казан феодалларының шартнамәләре исемлекләре һәм татарча язулары, башка документлар сакланган була. Мәсәлән, патша архивының 15 нче номерлы тартмасында, исемлеккә караганда, түбәндәгеләр сакланган: «А в нем грамота шертная Шигалея царя, и грамота шертная Сафа Кирея царя с Великим князем Василием; и грамоты шертные князей и всее земли казанские; и запись потверженая князей казанских, что присылали бити челом к Великому князю Табая князя, и Дангу, и Ибраим Бекшея, за свою вину, что ногайским мирзам шерт дали без Великого князя веленья, а привез ее из Казани Ондрей Пилъемов», ә 32 нче номерлы тартмада түбәндәге документлар күрсәтелгән: «А в нем книги старые Казанских царей, и посольства Адделетифа царя и Магмедъамина царя и Аереима царя с Великим князем Иваном Василевичем; и книги как Великому князю казанцы изменили и Шигалея царя из Казани выслали, а взяли себе царя на Казань Сагибгирея царевича Менлигиреева сына».

Сакланып калган башка илчелек китапларында да махсус Казан чыганакларына ишарәләүләр очрый.

Казан ханлыгы тарихын язуда шулай ук бастырып чыгарылган рус чыганаклары арасыннан төрле тарихи һәм хокукый актлар җыентыкларына кергән документаль материал да кулланылырга мөмкин[5].

Казан ханлыгы тарихы буенча чыганаклар арасында Көнбатыш Европа сәяхәтчеләренең язмалары аерым урын алып тора. XVI гасыр Рус дәүләтенең һәм аңа күрше булган Үзәк, Көнчыгыш, өлешчә Төньяк Европа, Урал арты һәм Көнбатыш Себер илләре һәм халыкларының иң тулы һәм дөрес тасвирламасын без Сигизмунд Герберштейнның «Записки о московитых делах» әсәрендә табабыз. «Записки...» ярты гасырдан артык Габсбург йортында хезмәттә булган тәҗрибәле Австрия дипломаты тарафыннан язылган. Үзләренең вакытлы союзнигы булган Бөек Мәскәү кнәзьлеге белән бәйләнешләрне ныгытуга кызыксыну белдергән Габсбург йорты вәкилләре Герберштейнны ике тапкыр — 1517 һәм 1526 елларда Бөтен Русьның бөек кнәзе Василий III киңәшчеләре һәм Бөек Литва кнәзе һәм Польша короле Сигизмунд I илчеләре арасында барган сөйләшүләргә арадашчы итеп җибәрәләр. Күрсәтмә инструкция буенча Герберштейн һәртөрле тармак буенча — гореф-гадәтләр һәм көнкүрештән алып сәясәт һәм икътисадка кадәр — барлык мөмкин булган мәгълүматны тупларга тиеш була. Герберштейн Мәскәүдә озаклап тора. Ул Василий III күңелен үзенә җәлеп итә, төрле иҗтимагый даирә вәкилләре белән, шул исәптән чит ил дипломатлары һәм сәүдәгәрләре белән дә, рус хезмәтендә булган чит ил кешеләре белән дә таныша.

Герберштейнның мордва һәм чувашлар турында мәгълүматлары аеруча кыйммәтле, чөнки аларның үз язма чыганаклары бөтенләй диярлек сакланмаган. Бу халыклар турында бик күп хәбәр итә — этник атамаларын китерә, аларның телен характерлый, төп шөгыльләрен, көнкүреш үзенчәлекләрен, диннәрен һ.б. тасвирлый. Казан, касыйм, кырым татарлары тормышыннан ачык мисаллар башка чыганаклардагы мәгълүматларны шактый тулыландыра. Герберштейн татар ханлыкларындагы җәмгыятьнең иҗтимагый катламнары турында гомуми мәгълүмат бирә. Кайбер терминнарның фонетик бирелеше, аларның эчтәлек үзенчәлекләре Герберштейнның Мәскәүдә, бөек кнәзь даирәсендә яшәгән һәм, димәк, татар-төрек

дөньясының иҗтимагый иерархиясен яхшы аңлаган татар информаторлары хәбәрләреннән файдалануын күрсәтә.

Гомумән алганда, С.Герберштейн «Записки...» китабында берничә гасыр дәвамындагы Көнчыгыш Европа халыкларының тормышы, көнкүреше, мәдәнияте һәм сәяси тарихының чуар сурәтен китерә. Герберштейнның информаторлары даирәсе киң һәм төрле булуын исәпкә алып, бу чыганакны Казан ханлыгының этносоциаль тарихын яктырту өчен оригиналь һәм бик мөһим хезмәт дип атарга мөмкин.

Ахырда тагын бер төркем чыганаклар — Көнчыгыш һәм Көнбатыш Европада төзелгән географик карталар турында берничә сүз әйтеп үтәсе килә. Әле А.Х.Халиков ук бу тип чыганакларны хәзерге татар халкының этногенезын һәм этносәяси тарихын өйрәнгәндә актив фәнни әйләнешкә кертергә тырышып караган иде. Хәзерге вакытта бу өлкәдә хәл тәмам үзгәрде һәм кайбер тикшеренүчеләр тарафыннан инде җитәрлек материал тупланылды. Европа мәдәниятенең бу үзенчәлекле истәлекләренең тирән һәм объектив анализы белән аерылып торган Дмитрий Хафизов һәм Гөлнара Әминова хезмәтләрен аерым билгеләп үтәсе килә. XIV–XVII гасыр географик карталарын тәфсилләп өйрәнүнең безгә Казан ханлыгының этносоциаль һәм сәяси тарихының кайбер «детальләренә» яңача карау мөмкинлеге бирүе шиксез. Мисал итеп «Moscoviae tabula... Battista Agnese» (1525), Антоний Видның Россия һәм Татария картасын (1537–1544), Сигизмунд Герберштейнның Московия картасын (1546), «La carta della Moscovia di G.Gastaldi» (1550) карталарын атарга мөмкин, аларны игътибар белән тикшерү безгә Казан ханлыгының полиэтник халкының яшәү урыннарын, илнең төп үзәкләренең кайда урнашуын билгеләргә, ханлык территориясенә рус экспансиясенең этапларын (карта төзүчеләрнең күзаллаулары буенча) ачыкларга мөмкинлек бирә.

Бу бүлек ахырында минем тагын бер кат Казан ханлыгы тарихы буенча чыганаклар кытлыгын билгеләп үтәсем килә. Шул сәбәп тикшеренүчеләрне элгәреге (Алтын Урда чоры) яки соңрак (XVI–XIX гасырлар) чорлар документларына, шулай ук Казан ханлыгының үзеннән түгел, ә күрше татар дәүләтләреннән чыккан документларга мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр итә. Ә бу, үз чиратында, минемчә, регионның XV гасыр — XVI гасырның беренче яртысы тарихы буенча тикшеренүләр сыйфатына шактый зыян китерә.

## 2. Төп әдәбият

Казан ханлыгы тарихын теге яки бу дәрәҗәдә чагылдыручы монографик тикшеренүләр, уку әсбаплары, фәнни мәкаләләр сан ягыннан шактый күп. Бу А.Лызлов, П.Рычков, К.Фукс, М.Рыбушкин, Н.Баженов, Х.Фәезханов, С.Шпилевский, Г.Перетяткович, Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, М.Пинегин, М.Рәмзи, Г.Әхмәрев, Һ.Атласи, Ә.Вәлиди, М.Худяков, Ә.Курат, Г.Баттал, Р.Фәхретдин, Г.Гобәйдуллин, Н.Фирсов, А.Башкиров, А.Смирнов, Х.Гыймади, Ш.Мөхәммәдьяров, М.Сәфәргалиев, Н.Калинин, Е.Чернышев, О.Притцак, С.Кинан, Я.Пеленски, М.Каратеев, А.Халиков, Ә.Булатов, Ю.Шамилоглу, С.Алишев, М.Әхмәтҗанов, А.Бахтин, Е.Бусыгин, В.Владыкин, М.Гришкина, В.Дмитриев, А.Иванов, Д.Исхаков, И.Измайлов, М.Зәкиев, В.Каховский, К.Козлова, Р.Кузиев, Н.Мокшин, Р.Фәхретдинов, Ф.Хуҗин, А.Борһанов, Р.Галләмов, Б.Хәмидуллин һәм башкаларның хезмәтләре.

Ләкин бәяләү өчен нигез итеп сыйфат һәм мәгълүмат күләмен алсак, Казан ханлыгы тарихы буенча хезмәтләр исемлеге бик кыскара. Бу исемлекне мин түбәндәгечә күзаллыйм:

— Әхмәрев Г. Казан тарихы. — Казан, 1909;

— Атласи Һ. Казан ханлыгы. — Казан, 1914. — 1 кисәк;

— Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. — Казань, 1923;

— Мухамедьяров Ш.Ф. Социально-экономический и государственный строй Казанского ханства. XV — первая половина XVI вв. — М., 1950 (рукопись диссертации... кандидата исторических наук);

— Алишев С.Х. Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV — XVI вв. — Казань, 1995;

— Исхаков Д. От средневековых татар к татарам нового времени (этнологический взгляд на историю волго-уральских татар XV — XVII вв.). — Казань, 1998;

— Алишев С.Х. Казан ханлыгы тарихыннан. — Казан, 2003.

Атап үтелгән җиде монографиянең эчтәлекләренә тукталып тормыйк. Бу хезмәтләргә җентекле тәнкыйди анализ бирүне мин максат итеп куймыйм, чөнки бу тикшеренүләрдә Казан ханлыгының этносәяси һәм иҗтимагый-икътисади үсешенә караган бик күп мәсьәләләр күтәрелгән — дәүләткә нигез салыну, ханлык оешу, дәүләтнең территориясе һәм административ төзелеше, Идел буе Болгары яки Алтын Урдадан этносәяси һәм этносоциаль күчүчәнлек, Казанның барлыкка килүе һәм дәүләт башкаласы булып формалашуы, Казан ханнарының эчке һәм тышкы сәясәте, аларның тормыш юлы, илнең икътисады һәм мәдәнияте, халыкның этник һәм иҗтимагый структурасы, этник территорияләр. Фәкать моңарчы беркайчан да тулаем басылып чыкмаган бер хезмәткә генә җентеклебрәк тукталырга ниятлим

(Мухамедьяров Ш.Ф. Социально-экономический и государственный строй Казанского ханства (XV — первая половина XVI вв.) / Институт истории АН СССР. Рукопись диссертации на соискание ученой степени кандидата исторических наук. — М., 1950).

Бу диссертация СССР Фәннәр академиясенең әгъза-корреспонденты, профессор М.Н.Тихомиров җитәкчелегендә языла һәм 1956 елда Мәскәүдә уңышлы рәвештә яклана.

Ул түбәндәге бүлекләрдән тора (күләме — 367 бит, кушымталары белән 381 бит):

Кереш.

1 нче бүлек. Чыганаклар.

2 нче бүлек. Казан ханлыгы хуҗалыгы.

§ 1. Казан ханлыгы халкының төп шөгыле турындагы фикерләргә кыскача күзәтү.

§ 2. XV–XVI гасырда Идел-Кама буенда игенчелек үсеше турында чыганакларда дәлилләр.

§ 3. Казан ханлыгында игенчелек системасы мәсьәләсе.

§ 4. Төп игенчелек кораллары.

§ 5. Бакчачылык, терлекчелек, чолыкчылык, аучылык һәм балыкчылык.

3 нче бүлек. Феодаль җир биләүчелек.

§ 1. Башлангыч искәрмәләр.

§ 2. Хан биләгән җирләр.

§ 3. Эре феодалларның җир биләмәләре.

§ 4. Сөйургал — Казан ханлыгында җир биләүнең төп төре.

4 нче бүлек. Крестьяннар хәле.

§ 1. Крепостной хокук мәсьәләсе.

§ 2. Крестьян җир биләмәсе.

§ 3. Крестьяннар түләгән салымнар һәм йөкләмәләрнең гомуми исемлеге.

5 нче бүлек. Казан ханлыгында һөнәрчелек һәм сәүдә.

§ 1. Татар феодаль шәһәре мәсьәләсе.

§ 2. Казан шәһәре.

§ 3. Эчке сәүдә.

§ 4. Тышкы сәүдә.

§ 5. Казан ханлыгында һөнәрчелек.

6 нчы бүлек. Казан ханлыгының дәүләт төзелеше.

§ 1. Буржуаз историографиядә Казан ханлыгының сәяси төзелешенең яктыртылуы.

§ 2. Казан ханлыгының оешуы.

§ 3. Феодаль җир биләүчеләр дәүләте буларак Казан ханлыгының сыйнфый эчтәлеге.

§ 4. Югары хакимият органнары.

§ 5. Югары идарә органнары.

§ 6. Җирле хакимият органнары.

§ 7. Җирле идарә органнары.

Йомгак.

Чыганаклар һәм әдәбият.

Кабул ителгән кыскартылмалар исемлеге.

Кушымталар:

№ 1. Борынгы сабан рәсеме.

№ 2. Сәхиб Гәрәй ярлыгының татарча тексты һәм русчага тәрҗемәсе.

№ 3. Татар АССР территориясендә X–XIII гасыр болгар археологик истәлекләре (торак урыннар исемлеге белән).

№ 4. Татар АССР территориясендә болгар-татар кабер ташлары таралышы картасы (халык яшәгән урыннар исемлеге белән).

№ 5. Казан ханлыгының үзәк өлеше картасы (картада күрсәтелгән торак урыннар исемлеге белән).

Галим үз тикшеренүендә файдалану мөмкинлеге булган (бастырылган һәм бастырылмаган рус, Европа һәм Көнчыгыш, шул исәптән татар) чыганакларның күбесен киң куллана. Ул чыганакларны автор диссертациянең беренче бүлегендә анализлый (8–53 б.). Мөхәммәдьяров: «Хезмәтебезнең чыганакларны өйрәнү ягыннан үзенчәлеге — Казан ханлыгының иҗтимагый-икътисади тарихы мәсьәләләрен нигезләрлек һәм яктыртырлык бердәм компакт чыганаклар фондының булмавы. Нәтиҗәдә рус телендә, шулай ук Көнчыгыш һәм Көнбатыш Европа телләрендә характерлары һәм чыгышлары буенча төрле булган чыганаклар эшкә тартылды. Казан ханлыгындагы иҗтимагый-икътисади мөнәсәбәтләрнең чын

хәлен төрле чыганакларның аерым ярлы кисәкләренә нигезләнеп торгызырга омтылу шактый кыен, әлбәттә. Мәсәлән, чыганакларның үзенчәлеге Казан ханлыгындагы авыл хуҗалыгы җитештерүчәнлеге һәм җир милкенең бүленешен төгәл билгеләргә мөмкинлек бирми. Казан ханлыгының иҗтимагый-икътисади тормышын турыдан-туры чагылдырган татар чыганакларының җитешмәвенә тагын бер кат үкенергә туры килә... Аларның күбесе 1552 елда Казанны алганда утта юкка чыккан дип уйларга кирәк...» — дип яза.

Тикшеренүдә кулланылган барлык чыганаклардан галим түбәндәгеләрен беренче урынга куя:

1) Сәхиб Гәрәй хан ярлыгы. «Барлык татар чыганакларыннан, — дип яза Мөхәммәдьяров, — Сәхиб Гәрәй хан ярлыгы XVI гасырның беренче яртысында Казан ханлыгындагы феодаль мөнәсәбәтләр тарихы буенча иң кыйммәтле чыганак булып тора...»;

2) Вельяминов-Зерновның Касыйм ханнарына багышланган «Исследование о касимовских царях и царевичах» хезмәтендә бастырып чыгарылган татар васыятьнамәләре (т.3, 231–240, 449–452 б.). «Васыятьнамә текстлары, — Мөхәммәдьяров фикеренчә, — гомумән алганда татар иҗтимагый-икътисади терминологиясе буенча шактый кызыклы материал бирәләр. Алтын Урда таралганнан соң барлыкка килгән татар ханлыкларының иҗтимагый-икътисади төзелешенең кайбер якларына танылган охшашлык хас булуын күздә тотканда, Касыйм ханлыгына караган бу васыятьнамәләрне Казан ханлыгындагы феодаль мөнәсәбәтләр тарихы буенча өстәмә чыганак буларак куллану мөмкин...»;

3) «XV–XVI гасыр Казан-татар эпиграфикасы». Автор: «Татар эпиграфик истәлекләренең кыйммәте, беренчедән, датасы төгәл куелган бу һәйкәлләрнең Казан ханлыгында татар халкының таралышын күрсәтүендә. Икенчедән, алар татар феодаль җәмгыятенең төзелешен өйрәнү өчен әһәмиятле материал бирәләр (кабер ташларында, гадәттә, җирләнгән кешеләрнең титуллары күрсәтелә). Моннан тыш эпиграфик һәйкәлләр Казан ханлыгы халкының сыйнфый бүленешен ачык билгелиләр. Таш һәйкәлләр, кагыйдә буларак, феодаль аксөякләр каберләренә куелса, такта һәм колгалардан юнып ясалган һәйкәлле фәкыйрь каберләр гади халыкка хас була...»;

4) Хисаметдин әл-Мөслиминең «Рисалә-и-Тәварихы Болгария»се, Кадыйр Галибәкнең «Җамиат тәварих» («Елъязмалар җыентыгы») һәм бердәнбер татар елъязмасын үз эченә алган Чыңгыз хан һәм Аксак Тимер турында риваять (автор фикеренчә, «бу чыганакларда иҗтимагый-икътисади үзенчәлекле фактлар сирәк очракларда гына искә алына. Шулай да Казан ханлыгының иҗтимагый-икътисади тарихи фактларының гомуми суммасында бу чыганаклардагы мәгълүматларны куллану файдасыз түгел...»);

5) Казан шагыйре Мөхәммәдьяр Мәхмүд Хаҗи угълының «Нуры содур» һәм «Төхфәи мәрдан» поэмалары. «Мөхәммәдьяр Мәхмүд угълы, заманының алдынгы кешесе буларак, үз поэмаларында Казан ханлыгында эчке каршылыкларның кискенләшүен чагылдыра алган. Ул Казан хакимнәрен кискен тәнкыйтьли... Монда автор һәр бүлектә ниндидер бер иҗтимагый мәсьәләгә кагылып үтә. Ул гадел һәм намуслы булырга өнди. «Төхфәи мәрдан» поэмасында шулай ук Казан ханлыгы составына кергән кайбер аерым кабиләләрнең Казан ханы хакимиятенә каршы көрәшләре дә чагылыш таба... Илдә муллык булсын өчен дин түгел, гадел идарә кирәк, дип саный автор... Автор фикеренчә, «золым» (эчке көрәш, дошманлык) илне һәлакәткә илтә. «Нуры содур» поэмасында зирәк, гадел хаким идеясен алга чыгарып, автор Казан ханлыгында эчке каршылыкларның, Казан ханлыгының җимерелүе алдыннан анда феодаль сыйныф эчендә көрәш кискенләшүен объектив рәвештә чагылдыра. Мөхәммәдьяр Мәхмүд угълы поэмаларының Казан ханлыгы тарихы буенча тарихи чыганак буларак әһәмияте нәкъ шушында, безнеңчә...» — дип яза Мөхәммәдьяров;

6) Фольклор материаллары: а) «татар феодаль җәмгыятендә феодаллар һәм крестьяннар хәлен шактый төгәл тасвирлаучы» татар табышмаклары һәм мәкальләре; б) Әмәт, Җик Мәргән, Чура батыр турында дастаннар. «Бу былиналар, шулай ук Чаллы бәе турында риваять тә язма чыганаклардагы Казан ханлыгының зәгыйфь үзәкләшүе һәм аның аерым өлешләренә сепаратизм омтылышлары хас булуы турында мәгълүматларны раслыйлар»; в) Иске Казан турында һәм Яңа Казанга нигез салу хакында риваятьләр; г) Кабан күле, Черек күл, Татар бистәсе һәм Казанда базар ачу турында хикәятләр; д) 1881 елда Каюм Насыйри тарафыннан бастырылган Казан шәһәре бәете — «бу бәет Болгар тарихын кыскача хикәяләүдән башлана, Казан ханлыгында мәдәният торышын яктырта һәм 1552 елда Казанны алуны тасвирлау белән тәмамлана»;

7) XV гасыр ахырының Мәскәү елъязмалар тупланмасы, Воскресение, Никон, Львов һәм Типограф елъязмалары. «Әлбәттә, — дип яза Мөхәммәдьяров, — бу елъязмаларда Казан ханлыгының иҗтимагый-икътисади тарихы буенча материалның төрле сәяси вакыйгаларны һәм Казан тәхетенә дәгъва белдерүчеләр арасында барган көрәшне, феодаль низагларны һәм рус-Казан сугышларын сурәтләгәндә очраклы гына бирелүе һич гаҗәп түгел. Рус елъязмаларының бу вакыйгаларның барысы турында бик яхшы хәбәрдар булуларын танырга кирәк. Елъязмалар татар феодаль җәмгыятенең иерархик структурасын торгызу өчен әһәмиятле материал бирәләр. Елъязма хәбәрләрендә теге яки бу татар сарае кешеләре яки административ

вазифа атамалары гына очрап калмыйча, бу вазифаларда хезмәттә торучыларның исемнәре дә аталуы әһәмиятле. Бу хәл Казан ханлыгының иҗтимагый-сәяси терминологиясе турында мәгълүматларның дөрес булуын тәэмин итә...»;

8) «Казанский летописец» («История о Казанском царстве») елъязмасы. Мөхәммәдьяров: «Казанский летописец»ның Казан ханлыгының иҗтимагый-икътисади тарихы буенча чыганак буларак кыйммәте искиткеч. М.Н.Тихомиров «Казанский летописец»ны «башка чыганакларда булмаган Казан тарихы буенча фактик материал байлыгы аркасында барлык тарихчылар тарафыннан кулланылучы» чыганак буласын бик төгәл билгеләде. «Казанский летописец»ның Казан ханлыгы халкының игенчелек шөгыльләре турында мәгълүматлары минем тарафтан Казан ханлыгының җитештерү көчләре үсеше дәрәҗәсен характерлаганда киң кулланылды. Төрле һөнәрләр, шулай ук эчке һәм тышкы сәүдә үсеше турында да шактый кыйммәтле хәбәрләр табылды. XVI гасырның икенче яртысында җирле тәхеттә идарә иткән Кырым династиясе — Гәрәйләр хакимиятенә каршы шәһәр халкы хәрәкәте турында искә алулар иҗтимагый мөнәсәбәтләрне билгеләүдә һичшиксез кызыклы булып торалар. XVI гасырның рәсми елъязмалары (Воскресенская, Никоновская) белән чагыштырганда, «Казанский летописец» тикшеренүчегә татар феодаль җәмгыятенең теге яки бу якларын ачыграк күзаллау мөмкинлеген бирүче детальләргә һәм тәфсилле вак-төякләргә бай. Мәсәлән, «Казанский летописец»та китерелгән Казанга нигез салыну хакында риваятьләр, XVI гасыр татар киемнәре һәм Казанның Арча кырында татар бәйрәмнәре турында этнографик мәгълүматлар шундыйлардан. Казан ханлыгындагы феодаль мөнәсәбәтләр турында мәгълүматлар «Летописец»ның бөтен тексты буенча таратылган. Шуңа күрә мин С.М.Соловьевның «Казанский летописец»ына биргән «бик чуалчык чыганак» бәясен артык кырыс дип саныйм...» — дип яза;

9) А.М.Курбскийның «История о великом князе Московском» китабы;

10) Тарихи һәм хокукый актлар җыентыклары;

11) Үзәк дәүләт борынгы актлар архивы фондларыннан бастырылмаган рус чыганаклары: а) 1565–1568 елларда Н.В.Борисов һәм Д.А.Кикин тарафыннан төзелгән, өязе белән Казан шәһәренең һәм өязе белән Свияжск шәһәренең писцовый һәм межалау китапларының күчермәләре. Мөхәммәдьяров: «Рус дәүләте эченә кергәннән соң 15 елда элеккеге Казан ханлыгы территориясендә иҗтимагый-икътисади мөнәсәбәтләр тамырдан үзгәргән дип уйларга ярамый. Писцовый китаплар материалы Казан ханлыгының аның Рус дәүләте тарафыннан яулап алыну чорындагы иҗтимагый-икътисади төзелешен үткәнгә карап яктырту өчен кулланылырга мөмкин. Писцовый китапларда Казан ханлыгы чорындагы татар феодаль җәмгыятенең җир биләү формалары һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләре чагылыш тапкан. Писцовый китапларда бирелгән мәгълүматлар Казан ханлыгының административ географиясен торгызу өчен аерым әһәмияткә ия. Писцовый китапларда торак урыннар административ берәмлек булган даругалар буенча тасвирлана. Писцовый китапларның даругалар турындагы мәгълүматын башка чыганаклар белән чагыштыру даругалар Казан ханлыгы территориясе бүленешен тәшкил иткән эре административ берәмлекләр булган дигән нәтиҗәгә китерде. Аерым мәгълүматларның һәр даруга чикләрендә топографик тәртиптә урнашуы бу торак урыннарның күбесен картада билгеләргә һәм Казан ханлыгы авыл һәм шәһәрләре картасын төзергә мөмкинлек бирә...» — дип яза; б) И.И.Болтинның 1603 елгы Казан өязе писцовый китабы. «Бу писцовый китапның әһәмияте, — Мөхәммәдьяров фикеренчә, — анда татарларның, чувашларның һәм элеккеге Казан ханлыгының башка халыкларының авыл һәм салалары тасвирлануында. Китапта Казан ханлыгының татар авылында хөкем сөргән җир биләү һәм хуҗалык формалары, иҗтимагый мөнәсәбәтләр чагылыш тапкан. Бу безгә дә әлеге китапны Россия тарафыннан яулап алыну чоры алдыннан Казан ханлыгының иҗтимагый-икътисади төзелешен характерлау өчен куллану хокукын бирде...»; в) Казан шәһәре буенча 1646 елгы писцовый китап; г) «Грамоты Коллегии Экономии» фондыннан Казан өязенә караган аерым дозор һәм башка китаплар, документлар; д) Россиянең татар ханлыклары һәм Төркия белән мөнәсәбәтләре буенча «дипломатик характердагы күптөрле материалларның бай тупланмасын тәшкил итүче» һәм «иҗтимагый-икътисади характердагы (мәсәлән, коллар белән сату итү, Казан ханлыгында Кырым феодалларының җир биләү характеры турында) бер төркем кызыклы мәгълүматларны» үз эчләренә алган илчелек делолары...;

12) С.Герберштейнның «Записки о московитых делах» китабы. «Безнең өчен, — дип яза Мөхәммәдьяров, — С.Герберштейнның Мәскәү дәүләте тирәсендәге илләрнең кыскача тасвирламасын биргәндә, XVI гасырның беренче яртысындагы Казан ханлыгын да сурәтләве бик әһәмиятле. С.Герберштейн татар дәүләтенең чикләрен күрсәтә, татарларның шөгыльләрен тасвирлый, татар җәмгыятенең иҗтимагый төзелеше турында кайбер мәгълүматлар бирә. С.Герберштейн хәбәр иткән мәгълүматлар ышаныч уята. Аларны башка татар һәм рус чыганаклары белән тиңләштерерлек, чөнки ул бу чыганакларны киң кулланган...»

Диссертациядә «алда атап үтелгән язма рус һәм татар чыганакларыннан тыш кайбер очракларда археология, этнография һәм лингвистика мәгълүматлары да җәлеп ителде» ди Мөхәммәдьяров. Автор «археологик чыганакларны куллану мөмкинлекләре бик чикле, чөнки борынгы чор һәм иртә урта гасырлар Татарстан тарихын аңлау өчен үтә әһәмиятле булган Татарстанны революциягә кадәрге чорда археологик өйрәнү һәм совет археологиясе казанышларының (А.П.Смирнов тарафыннан Болгар һәм Сувар шәһәрләре хәрабәләрен тикшерү, Н.Ф.Калининның Татарстанның авыллары буенча археологик экспедицияләре) безне кызыксындырган Казан ханлыгы белән турыдан-туры бәйләнеше юк диярлек» дип билгеләп үтә. Алга таба Мөхәммәдьяров: «Урта Идел буе халыкларының этнографиясе һәм лингвистикасы материаллары игенчелекне тасвирлаганда өстәмә материал буларак кулланылды. Ләкин бу материалның һәм аны өйрәнү алымнарының үзенчәлекләре бу чыганакларның язма чыганаклар белән чагыштырганда бик аз кыйммәткә ия булуына китерде... Шулай да чыганаклар даирәсен этнография һәм лингвистика мәгълүматлары исәбенә баетуны файдасыз түгел дип санайбыз».

Шулай итеп, Шамил Фатих улы Мөхәммәдьяров хезмәтенең һәртөрле чыганакларга нигезләнүен күрәбез. Алар авторга «Казан ханлыгының феодаль үткәне мәсьәләләрен тулысынча чишәргә мөмкинлек бирмәсә дә», нык ярдәм иткән.

Югарыда күрсәтелгәнчә, автор монографиядә Казан дәүләтенең сәяси һәм иҗтимагый-икътисади тарихы проблемаларының күбесенә кагылып үткән. Минемчә, Мөхәммәдьяров хезмәтен караганда, беренче чиратта аның хезмәтендә Казан ханлыгының дәүләт төзелеше турында мәгълүматны үз эченә алган алтынчы бүлеккә аеруча игътибар итәргә кирәк. Әйтелгәннәрне исәпкә алып, мин галимнең алтынчы бүлектә һәм шулай ук тикшеренүнең төп нәтиҗәләрен бирүче йомгак өлешендә китерелгән кайбер фикерләренә тукталып үтәчәкмен. Шамил Фатих улы хезмәте киң даирә укучыларга гына түгел, тарихчыларның да күбесенә таныш түгеллеген истә тотып, өземтәләрнең шактый күләмле булачагын алдан ук искәртеп үтәргә кирәк.

*Казан ханлыгының оешуы.* Мөхәммәдьяров: «1236 елдагы монгол яулап алуларыннан соң Болгар беркадәр автономия сыйфатларын саклап кала алган буйсындырылган ил буларак Алтын Урда составына керә. Бу вакытта Болгар дәүләте бер төркем феодаль кнзьлекләргә таркалган була, шулардан эрерәкләре — Болгар үзе, Җүкәтау һәм Иске Казан бәклекләре. Бары тик Болгар феодаль икътисади үсешенең билгеле бер этабында гына феодаль таркаулыкны җиңүгә нигез салына. Идел-Кама өлкәсендә феодаль таркаулыкта булган бәклекләрнең берләшү процессы Алтын Урда дәүләтенең әкренләп җимерелүе белән турыдан-туры бәйле. 1359 елда Бирдебәк ханның үлеме чорында Алтын Урдада көчәйгән феодальләшү процессы Алтын Урданың аерым эре феодаллары арасында сепаратизм хәрәкәтенең шактый үсүенә китерә... Алтын Урда дәүләтеннән бер-бер артлы бербөтен олыслар аерылып чыга.

Бу вакытта элеккеге Болгар дәүләте территориясе шулай ук таркала баручы Алтын Урданың аерым феодалларының сепаратистлык омтылышларын тормышка ашыруда әһәмиятле роль уйный башлый. Монда Идел артына, Мамай эзәрлекләүләреннән качып, Тимер Хуҗа килә. «Әмәт дастаны» герое феодал Әмәтнең дә Сарай ханнарыннан качып, Җанибәк ханның кызы белән шушында, Болгарга, Зөя елгасы буена килеп урнашуы да очраклы түгел. 1361 елда Болгар җире Алтын Урдадан аерылып чыга. Бу факт турында рус елъязмасы: «Булат Темирь, князь Ордынский, Болгары взял, и все грады по Волзе и улусы поимал и отня весь Волжский путь», — дип яза. Иске буржуаз тарих белемендә (С.М.Шпилевский, Н.Ф.Катанов, Н.Н.Фирсов, М.Г.Худяков) бу факт Болгар җиренең Булат Тимер тарафыннан яулап алынуы буларак каралды.

Күптән түгел бу мәсьәләгә Х.Г.Гыймади әйләнеп кайтты. [Сүз түбәндәге публикация турында бара: Гимади Х.Г. Народы Среднего Поволжья в период господства Золотой Орды // Материалы по истории Татарии. — Казань, 1948. — Вып.1. — С.185–225. — *Б.Х.*]. Аның фикеренчә, Болгар олысының икътисади көчләре үсеше «бары тик ясак җыю белән кызыксынган, ләкин аерым җирләрнең Урдадан аерылуын һич тә теләмәгән Алтын Урда ханнары сәясәтенә каршы килә. «Урда ханы Булат Тимернең Болгарга походын да, — дип яза Х.Г.Гыймади, — нәкъ менә шушы яссылыкта карарга кирәк. Һичшиксез, Булат Тимер һөҗүме Урда идарәсе астыннан чыгу юлына баскан халыкка каршы Алтын Урданың җәза чарасы була». Болгарның Булат Тимер тарафыннан тар-мар ителүе турындагы юрамасы хакына Х.Г.Гыймади турыдан-туры тартып-сузулар юлына баса — Хисаметдин әл-Мөслиминең «Тәварихы Болгария» әсәрендә тасвирланган Болгар шәһәрләренең Аксак Тимер тарафыннан пыран-заран ителүен Булат Тимергә кайтарып калдыра. Һәм, әлбәттә инде, Мамайның 1380 елдагы Руська һөҗүмен берничек тә Булат Тимернең Болгарга 1361 елгы походы белән тигезләргә ярамый.

Икенче яктан, 1361 ел походын бәяләгәндә, икенче капма-каршы якка да кереп китәргә кирәкми. Мәсәлән, А.Савичның бу мәсьәләгә карашы Х.Г.Гыймадиныкыннан бөтенләй аерыла. Бу никадәр сәер булмасын, А.Савич Булат Тимерне Казан ханлыгына нигез салучы дип таный: «Элеккеге Болгар

патшалыгында, Иделдә, 1361 елдан соң мөстәкыйль Казан ханлыгы оеша, һәм аңа Булат Тимер нигез сала»[6].

«Безнең фикеребезчә, — дип дәвам итә Ш.Ф.Мөхәммәдьяров, — Булат Тимер походын бәяләүгә А.Ю.Якубовский үзенең (Б.Д.Греков белән уртак) «Золотая Орда и ее падение» дип исемләнгән соңгы хезмәтендә иң дөрес якын килә».

А.Ю.Якубовский 1361 ел походын ул вакыттагы Көнчыгыш Европаның сәяси һәм иҗтимагый-икътисади тормышының барлык вакыйгалары белән өзлексез бәйләнештә тикшерә. Х.Г.Гыймади һәм А.Савич бу фактны Алтын Урданың гомуми тарихыннан бөтенләй аерып тикшерсәләр, А.Ю.Якубовский өчен исә бу вакыйга Алтын Урдада башланган гомуми таркалу процессы нәтиҗәсендә туган котылгысыз факт булып тора. «Болгарның аерымлануы, Идел сәүдә һәм хәрби юлының Булат Тимер (Пулад Темир) кулына көчүе белән бергә, әлбәттә, Алтын Урда берлеген авыр хәлдә калдыра», — дип яза А.Ю.Якубовский.

Болгар белән бер үк вакытта Алтын Урдадан Наручат бәклеге (Мокша елгасында бер өлкә) дә аерылып чыга...

XIV гасырның 60 нчы елларында мөстәкыйльлеккә ирешкән Алтын Урда бәкләре Булат Тимер һәм Тагай тиздән Болгар һәм Наручаттан күршеләренә һөҗүм ясый башлыйлар. 1365 елда Наручат хакиме Тагай Рязань җирләренә һөҗүм итә... Шулай ук Булат Тимер дә, Болгар хакиме буларак һәм андагы яклау һәм терәккә таянып, Идел буенча Болгар җиреннән югарырак урнашкан князьлек җирләренә һөҗүм ясый. Воскресение елъязмасы 1367 елгы бу походны болай тасвирлый: «Князь Ордынский именем Булактемирь, прииде ратью татарскою, и пограби уезд весь по Волзе даже и до Сундовити и села князь Борисовы, князь же Дмитрий Константинович с братом Борисом и 3 детьми, собрав вои, поиде противу ему; он же окаянный не ста на бой, но побеже за реку Пиану, и гоняше по нем много татар остаточных загонных избиша, а иные мнози в реце Пиане истопиша, не колико же их по зажитьем избиша, а Булактемирь в Орду бежа и тамо убиен бысть от Азиза царя». Шулай итеп, бу җиңелү Булат Тимерне Урдага качарга һәм Болгар җиренең алдагы язмышын кулыннан ычкындырырга мәҗбүр итә.

«Ләкин, — дип дәвам итә Мөхәммәдьяров, — Булат Тимернең ташлап качуы инде Идел-Кама ярларында барган дәүләт оешу процессы барышын туктата алмый».

Ермолин елъязмасында инде 6884 (1376) елда ук рус князьләре Дмитрий Михайлович Волынскийның һәм Дмитрий Суздальскийның Болгар шәһәренә походын сурәтләгәндә, болгар бәкләре Осан һәм Мәхмәт Солтан искә алына. Казан 1407 елда, күрәсең, Алтын Урдадан бәйсез булган, чөнки Шильдбергер Казанның Идегәй тарафыннан яулап алынуы турында хәбәр итә.

Шуңа күрә 1409 елда Вяткадан Болгарга һөҗүм иткән Анфал да, тар-мар ителеп, татарлар тарафыннан Алтын Урдага китерелә. Анфал походы турында иң тулы хикәя 2 нче София елъязмасында 6917 (1409) ел алдыннан сакланган. Мин өзекне шуннан китерәм: «В лето 6917 ходи Анфал на болгары Камой и Волгою, сто насадов Камью, а Волгою полтараста насадов, и тамо рать около его побиша татарове, а самого поимавше в орду повели, а Волжские насады не поспели».

Яңа Болгарда (Болгар-әл-җәдид) сугылган бер төркем тәңкә акчалар XV гасырның 10 нчы елларына карый. Бу хәл, Яңа Болгар исеме астында киләчәктә Казан ханлыгының башкаласы булачак Казан яшеренгән дип санаганда, элеккеге Болгар җирләренең ниндидер дәрәҗәдә мөстәкыйльлеген тагын бер кат раслый.

«Мәскәү летописьлар җыентыгында 6937 ел алдыннан искә алынган 1429 елгы Галичка татар походына, — дип дәвам итә Мөхәммәдьяров, — татарлар бары тик рус князьлекләренә күрше җирдә урнашкан ниндидер базадан гына чыга алганнар». Елъязманың текстыннан күренгәнчә, мондый база булып Болгар җире генә хезмәт итә алган. Елъязмачы татарларның Галичка һөҗүмнән соң Түбән Новгород янынннан узулары турында сөйли: «Приходиши татарове к Галичю, града не взяша, а волости повоеваша. На крещение же приидоша изгоном на Кострому и поплениша ю отъидоша на низ Волгою. Князь же великы посла за ними дядь своих, князя Андрея и Константина, и с ними Ивана Дмитриевича, с своими полкы. Доидоша же до Нижнего Новгорода и ту не угонивши их возвратившияся. Князь же Федор Стародубскы Петров да Федор Константинович, утаивая у князей и у воевод, своими полкы погнаша за татары и угониша зад, побиша Татар и Бесермен и полон весь отняша, царевича и князя Али бабы не догониша». Монда искә алынган җирле бәк Али баба күпмедер дәрәҗәдә «князь» Либей белән тәңгәлләштерелергә мөмкин. Воскресение елъязмасында «Ул тәхеттән 1446 елда, Казанны Мәхмүтәк яулап алганда бәреп төшерелә» дип хәбәр ителә.

Бу вакытта (XIV гасырның икенче яртысы һәм XV гасыр башы) Алтын Урданың үзәк олысларының халкы, эчке үзара феодаль ызгышлар һәм читтән һөҗүмнәр[7] нәтиҗәсендә туктаусыз бөлүдән качып, Алтын Урданың чикләренә — Болгар, Кырым, Себергә күченә. Аксак Тимер биләгән җирләргә уннарча мең

кешеләрне көчләп күчереп утырту шулай ук Алтын Урданың үзәк олысларының бушап калуына һәм Яңа һәм Иске Сарай, Үкәк, Бездеж кебек шәһәрләрдә тормышның әкренләп сүнүенә китерә. Ә 1395 елда Сарай Бәркәнең тар-мар ителүе, асылда, Алтын Урда дәүләтенең һәм аның Көнчыгыш Европа белән Урта Азия арасындагы сәүдә бәйләнешләрендә тоткан әһәмиятен юк итүгә тиң була (А.Ю.Якубовскийның 1930 елда басылган «Развалины Ургенча» хезмәтеннән өзек).

Ибне Гарәбшах Аксак Тимергә багышланган китабында («Чудеса предопределения в судьбах Тимура») хәтта «О том, как настал этот потоп (т.е. Тимурово нашествие) и смыл народы Дештские после поражения Тохтамышева» дип исемләнгән аерым бер бүлек бирә. Анда Алтын Урданың Тимер тарафыннан пыран-заран китерелүе турында сөйли: «Длился этот бой и погром около 3 дней; затем явилась пыль от бегства войска Токтамышева, показавшего тыл; рати его разбежались и отступили, а полчища Тимура разбрелись по владениям Дештским, да расположились (в них). Он покорил племена их и (ему) подчинились последние и первые из них. Завладел он движимым и разделил его, да недвижимым и унес его с собою, собрал (все) захваченное и роздал добычу, дозволил грабить да полонить, произвел гибель и насилие, уничтожил племена их, истребил говоры их, изменил порядки да увез (с собой все) захваченные деньги, пленных и имущество. Передовые войска его дошли до Азака и он разрушил Сарай, Сарайчук, Хаджитархан и (все) эти места».

Алтын Урданың үзәге һәм чик өлкәләре арасында бәйләнеш акрынлап өзелә һәм читтәге җирләрдә аерым халыкларның (Казан татарлары, нугайлар һ.б.) бергә туплануына ярдәм итүче мөстәкыйль дәүләт берләшмәләре барлыкка килә.

Үз вакытында В.В.Вельяминов-Зернов, бер төркем елъязмалар хәбәрләренә анализ ясап, Казан ханлыгына 1445 елда Олуг Мөхәммәднең улы Мәхмүтәк нигез салган дигән нәтиҗәгә килгән иде. Аның фикеренчә, «осенью 1445 года сложилось царство Казанское. Сын Улу-Мухаммеда — бывшего хана Золотой Орды, изганного оттуда — Махмутек убил Казанского вотчича князя Алибека, овладел городом, и чрез то положил начало новому ханству и новой династии царей».

В.В.Бартольд та шундый ук фикер тарафдары иде.

«Ләкин, — дип яза Ш.Ф.Мөхәммәдьяров, — рус, татар һәм төрек тарих белемнәрендә башка бер караш та киң таралган, бу фикер буенча Казан ханлыгына нигез салу 1437–1438 елларда Олуг Мөхәммәдкә кайтып кала. М.Г.Худяков, татар буржуаз-милли тарих белеме карашларын алга сөреп, хәтта Олуг Мөхәммәдне Казан ханлыгының нигез салучысы буларак идеаллаштыру юлына баса...»

«Соңгы вакытта, — дип дәвам итә Шамил Фатих улы, — Казан ханлыгының барлыкка килү мәсьәләсе А.Ю.Якубовский игътибарын җәлеп итте, һәм ул бер төркем кызыклы фикерләр белән чыга: «Казан ханлыгының барлыкка килүен Татар ханлыгы оештырылу дип карарга ярамый... Болгар өлкәсенең эчке тарихы ягыннан караганда, Казан ханлыгы оештырылу Болгар халкының Олуг Мөхәммәд яки аның улы Мәхмүтәк җитәкчелегендәге килмешәк татар олысы тарафыннан 1437 яки 1445 елда тулысынча буйсындырылуы дип кабул ителергә тиеш».

Ханлыкның 1437–1438 елларда Олуг Мөхәммәд тарафыннанмы, әллә 1445 елда Мәхмүтәк (Мәхмүд бәк) тарафыннанмы нигезләнүе хәлиткеч әһәмияткә ия түгел.

Даими феодаль ызгышлар һәм күршеләр һөҗүме шартларында беренче Казан ханнарына кадәр булган хакимияткә караганда күпкә көчлерәге барлыкка килү илнең икътисадына да, халыкның хәленә дә уңай тәэсир итәргә тиеш була.

Рус елъязмасында Болгар җиренә шул чорда ясалган берничә поход турында истәлекләр сакланган. Дүртенче Новгород елъязмасының 6903 (1395) ел алдыннан князь Юрий Дмитриевич походы турында хәбәренә тукталам: «Они же шедше ратью плениша землю Татарьскую и взяша град Болгары, и Жукотин, и Казань, Керменчук, пребыша 3 месяца воеюще, <u>и никто даже не помнит толь далече воевала Русь Татарскую землю</u> [Ш.Ф.Мөхәммәдьяров тарафыннан астына сызылган. — *Б.Х.*], и възвратишася с многою корыстью». Шулай ук 1431 елда Болгар җиренең князь Федор Давыдович Пестрый тарафыннан яулап алынуын күрсәтергә була. Бу поход хакында хәбәр Никон елъязмасында 6939 (1431) елда дип китерелә: «Тое же весны князь великы Василий Васильевич посылал ратью на Болгары Воложскиа и Камскиа князя Федора Давидовича Пестрого; он же шед, воева их и всю землю их плени».

Казан ханлыгы территориясенең Олуг Мөхәммәд яки аның улы тарафыннан яулап алынуы, күрәсең, җирле халыкның көчле хан килгәч үзәк хакимиятнең куәтләнүенә һәм үзара даими ызгышларның беркадәр тынуына өмет итүче өлешендә яклау таба. «Казанский летописец» бу процессны дөрес күреп ала һәм теркәп куя: «И мало в граде (в Казани. — *Ш.М.*) живущих, и нача збиратися Срачинии и Черемиса, развие по улусам Казанским, и ради ему (Улу-Мухаммеду. – *Ш.М.*) быша, а изоставшися от плена худыя Болгары молиша его, казанцы быти ему заступником бедам их, и помощника от насилия, воевания Рускаго, и быти царству строителя, да не до конца запустеют, и повинушася ему».

Казан ханлыгының барлыкка килүен Идел-Кама буе халыкларының Алтын Урданың кораллы отрядлары тарафыннан яулап алынуы нәтиҗәсе дип кенә сурәтләргә тырышуны ялгыш фикер дип танырга кирәк...»

Бу параграфның ахырында Ш.Ф.Мөхәммәдьяров «История Татарской АССР» (Казан, 1950. — 1 т. — 149 б.) китабыннан түбәндәге өземтәне китерә: «Өлкәдә җитештерү көчләренең үсүе җимерелгән Болгар урынына гомуми идарәне үз өстенә алырлык, һәм, иң мөһиме, илнең куркынычсызлыгын тәэмин итәрлек яңа үзәк төзүне таләп итә. Шуңа күрә XV гасырның 30 — 40 нчы елларында... таркау феодаль князьлекләрне күпкә куәтлерәк сәяси организмга берләштерүче җирле дәүләтчелек торгызыла».

*Казан ханлыгының югары идарә органнары*. Ш.Мөхәммәдьяров болай яза: «Казан ханлыгы, эксплуатацияләнүчеләрне изүгә корылган дәүләт буларак, массалар асылда дәүләт эшләренә тәэсир итә алмый торган итеп оештырылган була, һәм дәүләт җәмгыятьтәге күпчелеккә каршы куела.

Казан ханлыгы монарх эшчәнлегенә феодаль курия һәм феодаллар съездлары ярдәмендә юнәлеш бирелгән феодаль монархия була. Татар феодаллары дәүләте өчен феодаль монархия идарә итү формаларының иң кулае булгандыр, мөгаен, алар беренче һәм иң эре феодалны — хан шундый була — дәүләт башлыгы итеп куйганнар.

Татар феодаль дәүләте башында хан торган. Рус чыганаклары Казан ханын «царь» дип атыйлар. Хан баш сюзерен булып саналган. Ул дәүләттә иң югары хакимлеккә ия була. Хан йөзендә сугыш башлау һәм солых игълан итү, дәүләтнең хәрби көчләре белән идарә итү, олыс һәм даругаларга җитәкчеләр кую, салым җыю һәм ясак түләтү, иммунитет грамоталары чыгару, үзәк һәм җирле идарә түрәләрен билгеләү хокукы танылa. Югары хөкем шулай ук хан хокукы санала. Хан хакимлеге нindидер кануннар белән чикләнми. Сәхиб Гәрәй ярлыгы мөһерендәге Казан ханы титулы шуны дәлилли: «ал слтан гази гзалдания валдин абуалмзгр Сахиб граи бхадр хан хлдалла млка в аид слтна», ягъни «Бөек солтан, дөньяда һәм диндә шөһрәтле яулап алучы Сәхиб Гәрәй, баһадир хан, Алла аның дәүләтен мәңге имин кылсын һәм аның патшалыгын зурласын»...

...«Казанский летописец» хан дәрәҗәсенең тышкы билгеләрен ачык тасвирлый: «Сокровища же царьские, иже в Казани взято быша, венец царьскии, и жезл, и знамя Казанских царей и прочая царьская орудия в руце благочестивому царю (Ивану Грозному) богом предана быша».

Хан махсус мөһер — «нишан»га ия була. Ханнан чыккан барлык кәгазьләргә шушы мөһер сугыла. «И в Казани царь Магмед Амин перед великого князя послы на той грамоте шерть дал, и мешень свою к ней приложа, и отпустил Ивана (Григорьевича Морозова. — *Ш.М.*) к великому князю» яки «царь в Казани пред великого князя послы на грамоте шертной правду учинил и к записи шертной печать свою приложил» һ.б. шундый истәлекләр елъязмаларда еш очрый.

Атаклы 1523 елгы ярлыкка ал төстәге Сәхиб Гәрәй мөһере сугылган...

Хан гаиләсе әгъзалары «солтан» титулын йөрткәннәр. Бу титул борынгы татар истәлекләре текстларында очрый[8]... Мисал өчен бер текстның мәгънәсен китерәм: «Бу бөек солтанның нурлы кабередер. Садир угълы Идегәй 947 елда кяфер кулыннан шәһит китте». Бу дата 1540 елга туры килә. Солтан титулын хан хатыннары да йөрткәннәр, мәсәлән, Фатыйма Солтан...

Казан ханын феодаль монарх буларак карау мәсьәләсе тарихи әдәбиятта куелмады диярлек, — дип дәвам итә Ш.Ф.Мөхәммәдьяров. — Казан ханы феодаль төркемнәрнең вәкиле һәм яклаучысы була; ул илдә беренче феодал — җир биләүче була. Хан хокуклары нindидер канун яки даими оешма белән чикләнмәсә дә, аның көндәлек эшчәнлеге феодаль сыйныфының югары катламы тарафыннан тикшерелә һәм юнәлтелә. Ханга һәрвакыт үзенең даирәсендәге аксөяк феодалларның кәефләрен һәм теләкләрен исәпкә алырга туры килә».

Татар феодаллары сыйныфы мәнфәгатьләрен яклау өчен тудырылган хан хакимияте алар белән киңәшмичә булдыра алмый. Казан ханлыгында шундый хакимият һәм идарәне оештыруның билгеле бер тәҗрибәсе туплана.

Хан сарайга якын булган аксөяк феодаллар катламы һәм югары мөселман руханилары белән киңәш уздырганнан соң үз карарын кабул итә. Бу җыелыш «диван» дип аталган, хан каршындагы киңәшмә оешмасын тәшкил иткән. Диван даими эшләүче яки билгеләнгән вакытларда җыелучы орган булмаган. Аның төгәл составы да булмаган дип уйларга кирәк, ләкин аның илдәге сәяси тормышның гомуми юнәлешенә тәэсире шактый зур булган. Хан карамагындагы диванның эшчәнлеге ханның үз эшчәнлегеннән аерылгысыз була. Диван әгъзалары — феодаллар «олы түрәләр» (рус елъязмаларында «олы рядецлар») дип аталганнар. «Казанский летописец», мәсәлән, Сөембикә патшабикә белән Казан түрәләренең җыены булуы турында сөйли...

Хан каршындагы диванның төп әгъзаларын дүрт мәшһүр татар нәселе — Ширин, Барын, Аргын һәм Кыпчак гаиләләре вәкилләре тәшкил иткән. Алар махсус карачы (караучы) бәк исеменә ия булганнар. Рус

елъязмаларында бу термин, күрәсең, «князь князей» сүзтезмәсе белән бирелә (мәсәлән, Воскресение елъязмасында 1499 елда «Урак князь казанских князей» искә алына). Дүрт карачы арасында һәрвакыт «олы карачы» дип йөртелгән баш карачы аерылып торган. Бу дәрәҗәгә Булат Ширин бәк һәм аның улы Нур-Гали (Муралей) ия булалар. Күренгәнчә, карачы титулы нәселдән нәселгә тапшырыла. Карачы бәкләр институтының барлык татар ханлыкларында да булганлыгы билгеле — Кырымда, Себердә, Касыйм ханлыгында. Аның тамырлары Алтын Урдага барып тоташа, күрәсең. Аның дәүләт төзелеше турында Әл-Гомәри безгә түбәндәге искәрмәне калдыра: «... Бу солтанның (Үзбәк ханның. — *Ш.М.*) идарәчеләре — дүрт олыс әмире, шулардан иң зурысы «беклярибек», ягъни баш әмир дип атала... Һәр мөһим эш бары тик шушы дүрт әмир тарафыннан гына башкарыла...» «Беклярибек», ягъни «бәкләр бәге», рус елъязмаларындагы «князь князей» дигәнне аңлата.

«Зуррак әһәмияткә ия булган дәүләт мәсьәләләре буенча фикер алышу өчен, — дип дәвам итә Ш.Ф.Мөхәммәдьяров, — Казан феодаллары съезды — «корылтай» җыелган, рус чыганакларында ул «вся Казанская» дип атала. Бу съезд ханны төшергәндә яки яңасын сайлаганда, чит дәүләтләр белән шартнамәләр төзегәндә җыелган...

1551 елда «Царственная книга»да бирелгән «всей землей Казанской»ның тасвирламасы бу съездда катнашучыларны билгеләргә мөмкинлек бирә: «Кудайгул улан в головах да Муралей князь и вся земля Казанская, молланы и сеиты, и шихи и шихзады, и молзады, имамы, азии, афизы, князи и уланы, и мырзы, и ички, дворные и задворные казаки и чуваша, и черемиса, и мордва, и тарханы, и можары и вся земля Казанская тебе, государю, челом бьют...» Димәк, бу корылтай Казан иленең дөньяви һәм рухани феодаллары җыелышы була, һәм анда Казан ханлыгына кергән кабилә һәм халыкларның бәк-князьләре һәм старейшиналары, вәкилләре катнаша.

Ханнарның даими рәвештә феодаллар тарафыннан сайлануын Казан ханының үз феодалларына бәйле булуының тышкы чагылышы дип карарга мөмкин. Башта хан тәхете Олуг Мөхәммәд нәселе әгъзалары арасында буыннан буынга күчеп барса, тиздән тәхеткә кандидатларны «всей землей Казанской» җыенында феодаллар үзләре тәкъдим итә башлыйлар. Хан хәрби-феодал югары катламга буйсынуга эләгә.

М.Г.Худяковның бу съезд «бердәнбер халык теләкләрен белдерүче» булган дигән фикере сыйнфый җәмгыятьтәге сәяси өскорманы тупас бозып күрсәтү булып тора. Марксизм-ленинизм сыйнфый җәмгыятьтә (ә Казан ханлыгы шундый була) өскормага сыйнфыйлык хас дип өйрәтә. Шуңа күрә мондый җәмгыятьтә сәяси оешмалар бөтен җәмгыятьнең түгел, ә хакимлек итүче сыйныфның мәнфәгатьләренә генә хезмәт итә...

Югары мөселман руханияте Казан ханлыгының сәяси тормышында аерым урын алып торган. Ул бик зур куәткә ия була һәм дәүләт сәясәтенә һәрьяклап тәэсир итә. Моңа руханиларның бик зур җир биләмәләре биләве — вакыфлар сәбәп булып тора. Руханият вәкилләре бик еш татар феодаллары белән җитәкчелек иткәннәр. Алар феодаллар съездларында зур роль уйнаганнар. Бертөркем документлардан күренгәнчә, бу феодаллар беренче урында чыгыш ясый. Руханилар ханлыкның тышкы сәясәтендә актив катнашканнар...»

*Югары идарә органнары*. Ш.Мөхәммәдьяров яза: «Иң мөһим мәсьәләләрнең шактый өлешен хан үзенең киңәшчеләре белән бергә тикшергән, җитдирәкләрен диван утырышында караган. Казан ханлыгында махсус үзәк идарә органнары булган, алар тулысынча хан һәм аның феодалларына хезмәт иткән».

«Үзәк татар хакимиятенең төп үзенчәлеге, — дип яза Шамил Фатих улы, — дәүләт хезмәтендә торучыларның гомуми һәм шәхси функцияләренең тыгыз үрелеп баруында: югары дәүләт идарәсе органнары һәм ханның шәхси эшләре белән идарә итү органнары арасында төгәл аермалар булмый. Көнбатыш Европа һәм Русьтагы феодализмның билгеле бер этабына хас булган сарай-вотчина системасы шулай ук Казан ханлыгында да булган. Ханның шәхси хезмәтчеләре дәүләт хезмәте вазифаларын да башкарганнар. Хан хезмәтчеләре дәүләт белән идарә итү буенча төрле йөкләмәләр үтиләр. Казан ханлыгында министралитет мәсьәләсенең әле тарихи әдәбиятта күтәрелгәне юк.

Елъязмалар нигезендә Казан ханнары сараенда түбәндәге сарай чиннарын күзәтергә була.

Ханның сарай хезмәткәрләре арасында финанс идарәсе башлыгының («хранитель Казанский царев») әһәмияте зур булган. Бу атама «Казанский летописец»та, Сөембикәнең Казаннан киткәндә елавын тасвирлаучы бүлектә очрый: «...послав за казною их хранителя Казанъского царева, да тои сам пред самодержцем книги счетные положит».

Бөтен хан хуҗалыгы белән идарә иткән сарай башлыгының әһәмияте дә аннан кимрәк булмый. Бу чин Никон елъязмасында 1538 елда искә алына: «А сним Сафа Кирей царь послал человека Кул-Ахметя, ключника погребного, за грамотою, а писал царь к великому князю в грамоте, чтобы князь великий похотел с ним миру». Хан хакимиятендә ханның ат абзарлары белән идарә итүчесе дә шактый күренекле

урын биләгән. Никон елъязмасы 1551 елда сарай башлыгы һәм ат абзары хуҗасының аерым урын тотуларын ачык дәлилли: «А в горд Казань царь Шигалей послал дворецкого своего Шабаса-князя да конюшего своего Битикеа-князя с всем своим кошем и велел устраивати свой двор...»

«Башка сарай вазифаларыннан, — дип яза Мөхәммәдьяров, — чыганакларда ловчий (аучылык эшләрен алып баручы) һәм окружничий искә алына. Бу истәлекләр 1532 елга карый. Никон елъязмасы шушы елга карата Казан тәхетенә Җангалинең утыруын тасвирлый: «... а царь прислал к великому государю бити челом, что его государевым жалованьем сел на царство, Бибея-князя ловчего... а с ним вместе царь прислал к великому князю окружничего своего Бурнака-князя з грамотою». Ловчий (ханның ауларын оештыручы) функцияләре күпмедер дәрәҗәдә аңлаешлы булса, окружничий вазифасының эчтәлеге шактый томанлы. Львов елъязмасы бу терминны башкачарак сыйфатлый һәм аның функцияләрен бераз ачыкларга мөмкинлек бирә: «А с ним вместе прислал Яналей царь к великому князю оружельничего своего Бунака князя с грамотою». Күрәсең, оружельничий ханның арсеналы белән идарә иткән.

Монгол-төрки халыклары өчен ау борынгы чорларда зур хәрби-хуҗалык әһәмиятенә ия булган. Ау үзенә күрә хәрби маневрларның бер төре һәм азык-төлек чыганагы булган. Ау кагыйдәләре Чыңгыз хан Ясасында төгәл билгеләнә, ә сәлҗүкләрдә махсус «Ау китабы» була. «Казанский летописец»та Сафа Гәрәй хан авының кыскача тасвирламасы сакланган: «Обретоша его со птицами ловащь и со псы, впросте, в мале дружине; а побиша Казанцов 3000, бывших с ним, шатры и казну его всю, бывшую тут, разграбиша, бывшего хлебокормлю яша жива, и самого же царя мало жива не яша: мало жив во град утек; 5 или 10 юнош с ним, и град осади».

Бу хикәядә искә алынган «хлебокормля» сүзенә ия кеше шулай ук хан сараеның күренекле бер түрәсе булган: ул хан кухнясы өчен җавап биргән.

Казан ханнарының сарай көнкүрешендә хөрмәтле «аталык» вазифасын үтәүче — хан балаларын тәрбияләүче, ягъни ата урынына булган кеше бар. Ихтимал, аталык ханның ышанычлысы булгандыр.

Казан ханлыгының сарай-вотчина идарә системасында канцелярия мөһим урын биләгән. Казан ханнарының канцеляриясендә махсус диваннар булгандырмы, без белмибез. Канцелярия мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү өчен махсус дьяклар (бахши) штаты тотылган. Кайбер тикшеренүчеләр фикеренчә, санскрит теленнән алынган бу сүз башта уйгыр күчереп язучылары тарафыннан кулланылган һәм Казан ханлыгында да шул ук мәгънәдә йөргән. Дьяк-бахшиларның шактый төгәл хокукларга ия булган бюрократик оешмаларны барлыкка китерү юлында һөнәрләшүләренә ишарәләр дә очрый. Беренчеләрдән булып, күрәсең, тышкы мөнәсәбәтләр буенча ведомство бүленеп чыккан. Бахшилар һәрвакыт Мәскәүдәге хан илчелекләре составына кергәннәр. Мәсәлән, бахши Бозек 1507, 1512, 1516, 1519 еллардагы илчелекләрдә катнашкан. 20 нче елларда Мәскәүгә килүче илчелекләрдә бахши сыйфатында Ибраһим-бакшей күп тапкыр искә алына. Чыганаклар дьякларның гына түгел, илнең югары түрәләренең илдәге бер эш тармагына җаваплы булуы турында нәтиҗә чыгарырга хокук бирә...

Хан хезмәтчеләре арасында теге яки бу дәрәҗәдә вазифаларның төгәл бүленүе бары тик тышкы мөнәсәбәтләр юнәлешендә генә билгеләнә.

Ш.Ф.Мөхәммәдьяров диссертациясен йомгаклаганда, нинди нәтиҗәләр ясавын кыскача карап үтик.

«Казан ханлыгының иҗтимагый-икътисади һәм дәүләт төзелешен тикшерү ханлык территориясендә феодаль мөнәсәбәтләр хөкем сөрүен күрсәтә. Казан татарлары һәм өлкәнең башка халыклары XV гасыр — XVI гасырның беренче яртысында феодаль формация кичерәләр.

Халыкның төп шөгыле, Казан ханлыгындагы феодаль җитештерү ысулының нигезе игенчелек була. Казан ханлыгының җир эшкәртү культурасы Идел буе болгарларының җир эшкәртү культурасын дәвам итә. Казан арты һәм Тау ягы дәүләтнең төп игенчелек районнары була...

Җир эшкәртү Казан ханлыгында җитештерүнең төп чарасы һәм шарты булган. Җиргә мөнәсәбәт буенча аерым кешеләр, төркемнәр һәм сыйныфларның җәмгыятьтә тоткан урыны билгеләнгән... Татар феодаль җәмгыяте ике төп халык төркеменнән торган: феодаллар һәм крестьяннар... Феодалларның югары катламын әмирләр (бәкләр, морзалар) тәшкил иткән. Феодалларның икенче категориясе — әмир балалары. Өченче катлам оланнар йомышлы гаскәр башлыклары булган феодаллардан торган. Феодалларның иң түбән катламы казаклар булган. Феодалларның аеруча абруйлы катламын югары мөселман руханилары тәшкил иткән.

Казан ханлыгында җир биләү мөнәсәбәтләренең гадәти формасы булып нәселдән килүче хәрби лен системасы торган (феод — сөйургал — вотчина).

Феодаллар иммунитетлы булганнар, бу хокукка ханнар бүләкләве түгел, ә феодалларның җир биләмәләре нигез булып торган. Лен-феодка туры килүче сөйургал алга киткән Казан феодализмына хас булган мөнәсәбәтләрне чагылдырган...

Берничә тапкыр кабатланган (1496, 1546, 1551 һ.б.) крестьяннарның Казан ханнарына һәм аның феодалларына каршы чыгышлары татар феодал җәмгыятендә көчле эчке каршылыклар булуын ачык дәлилли.

Җитештерү көчләренең үсеше һәм шуңа бәйле рәвештә хезмәт бүленеше, һөнәрчелек белән сәүдәнең авыл хуҗалыгыннан аерылуы Казан ханлыгы территориясендә шәһәр тибындагы торак пунктлары барлыкка китерә. Казанда шактый халыкның һөнәр-сәүдә белән шөгыльләнүе Казанның ханлыкта зур сәүдә үзәге булуын күрсәтә...

Казан ханлыгында феодаль җитештерү мөнәсәбәтләре феодаль дәүләт һәм феодаль хокукка нигезләнә. Казан ханлыгы татар феодалларының крестьяннар өстеннән хакимлек итүнең сәяси коралы, татар феодалларының диктатурасы була. Казан ханлыгы халыкның күпчелеге дәүләт эшләренә тәэсир итүдән читләштерелгән форма буенча оештырылган була. Казан дәүләте монархның-ханның эшчәнлеге феодаль курия һәм феодаллар съездлары тарафыннан юнәлтелгән феодаль монархия була. Ханлыкның дәүләт оешмалары сыйнфый характерда булган һәм идарә итүче феодаллар сыйныфы мәнфәгатьләренә хезмәт иткән.

«Нәтиҗә ясаганда, — дип яза Шамил Фатих улы, — бу хезмәтнең бер ягын ассызыклап үтәсем килә. Мин ханлыкның феодаль үсешенең барлык мәсьәләләрен хәл итүне максат итеп куймадым. Шуңа күрә мин ясаган кайбер нәтиҗә һәм фаразларга киләчәктә ТАССР халыклары тарихын өйрәнгәндә аныклык һәм төзәтмәләр кертелергә мөмкин...»

# КАЗАН ФЕОДАЛЬ ДӘҮЛӘТЕНЕҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ ҺӘМ ҮСЕШЕ

## 1. Казан дәүләтенең барлыкка килүе

Идел буе Болгары үсешен илне 1236 елда басып алган монгол яулары тоткарлый. Язма һәм археологик чыганаклар кайбер тарихчыларның болгарлар монголларга каршылык күрсәтмичә буйсынганнар дигән фикерләре белән килешергә мөмкинлек бирми. Киресенчә, монголлар болгарлар җирендә каты каршылыкларга очрыйлар, һәм бу хәл болгарларның югары патриотизмын һәм дәүләтләренең сәяси һәм иҗтимагый-икътисади яктан нык булуын раслый.

Монгол империясенең соңрак мөстәкыйль дәүләткә әверелгән Җүчи олысы составына Идел буе Болгарының килеп керүе илнең этносоциаль үсешенә җитди тәэсир итә. Болгарның XIII гасыр уртасы — XV гасыр башы тарихы Җүчи олысы (Алтын Урда) тарихы белән тыгыз бәйләнгән. Яңа дәүләт берләшмәсе биләмәсенә өлешләренең берсе сыйфатында кереп, Идел буе Болгары үз мөстәкыйльлеген югалта. Ләкин ул «югалту» еш кына бары тик шартлы характер йөртә — XIII–XIV гасырлар дәвамында Идел буе Болгары билгеле дәрәҗәдә автономиясен саклап кала, моны бер төркем дәлилләр раслый.

1. Монгол (Урда) ханының Идел буе Болгары территориясендә турыдан-туры идарә итмәве мәгълүм (җирле хакимнең болгар нәселе яки монголлар вәкиле булуы монда принципиаль роль уйнамый). Болгар феодаль элитасы яулап алучылар хакимиятен таный, шуның өчен Бату хан тарафыннан үзләренең элеккеге җир биләмәләре белән бүләкләнә. Бату хан вафатыннан соң хәл үзгәрми — «Житие князя Федора Смоленского и Ярославского» тасвирында болгар феодалларының, рус князьләре кебек үк, «ходят в орду к царю (т.е. к хану), отчин свои просити у царя на столования своя» диелгән.

Бу чор болгар хакимнәренең кайберсенең исемнәре сакланган. Мәсәлән, Мәхмүд әмир һәм аның улы Хәсән бәк исемнәре билгеле. Хәсәннең каберендәге язу (датасы шактый бәхәсле):

«... Бу бөек һәм шөһрәтле хаким (солтан),
хакимнәр (солтаннар) ярдәмчесе
хөрмәтле һәм җиңелмәс...
Мәхмүд әмир улы Хәсән бәкнең күмелү урыныдыр».

Кабер ташындагы язу әмир титулының монгол-урда вакытында да нәселдән нәселгә күчүен һәм Болгарда сәяси хакимият күчүчәнлеге саклануын күрсәтә. Хәсәннең титулатурасында «хакимнәр (солтаннар) ярдәмчесе» формуласының искә алынуы исә аның Урда хакимнәренә буйсынуын раслый. Күрәсең, Хәсән әмир һәм аның атасы нәкъ менә монгол ханнарына үз дәрәҗәләре саклануын үтенеп («отчин свои просити») йөргән болгар бәкләре булганнар да инде.

Бату ханның улы Сартак тарафыннан «Казан Урдасы» оештырылуы[9] да XIII гасырның икенче яртысына (төгәлрәк 1257 елга) карый, ягъни Казан дәүләтенең нигезе салына.

XIV гасыр башында әмирләр Мөэмин улы Әхмәд һәм Бүләмшаһ бәк улы Бүләртай исемнәре билгеле.

1361 ел. «... Булат Темир, князь Ордынский, Болгары взял, и все грады по Волзе и улусы поимал, и отня весь Волжский путь»[10] дип белдерелә рус елъязмасында.

1370 елдан башлап рус елъязмаларында «князь Болгарьскыи Осанъ» исеме күп тапкырлар искә алына. Өстәвенә тагын бу Хәсәнгә каршы 1370 елда Мамай рөхсәте белән «хан илчесе» Ачихуҗа белән князь Дмитрий Нижегородский җитәкчелегендәге рус гаскәрләре яу белән килә. Хәсән җиңелә, ә аның урынына вакытлыча Мамай вәкиле «Салтан Баков сын» утыртыла. Ә.Г.Мөхәммәдиев фикеренчә, нәкъ менә Хәсән Идел буе Болгарына алмаш булып килгән Казан һәм Казан дәүләтенең күтәрелүен башлап җибәрә, бу хәл нумизматик материалда да ачык күренә. (Галимнәрнең бер өлешенең, шактый киң чыганаклар даирәсенә таянып, Хәсәнне Чыңгызид, Олуг Мөхәммәднең атасы дип күрсәтергә омтылуын билгеләп үтәргә кирәк.)

XIV гасырның икенче яртысында фольклор чыганаклары, имеш, «хан» Тимер (Тамерлан) тарафыннан үтерелгән Болгар хакиме Габдулла исемен искә алалар.

XIV гасыр ахырында елъязмаларда «Казанский царь Ентяк» исеме дә теркәлгән.

2. XIII–XIV гасыр Көнчыгыш һәм Европа язма истәлекләре Җүчи олысының төньягында «Бөек Болгар» дип аталган өлкә булуын билгеләп үтәләр. Мәсәлән, бу турыда 1253 елда Идел буйларында булган Гильом Рубрук яза. Бәлки, бу традицияләр дәвамы булгандыр (мәсәлән, әл-Гарнати, Марко Поло һ.б. әсәрләрендә Хазарияне искә алу кебек), ләкин факт үзе гыйбрәтле.

3. Бер төркем тикшеренүчеләр фикеренчә, XIII гасыр болгар феодаллары кайбер үз шәһәрләрендә җирле акча системасы нигезендә тәңкә акча сугуны яңарталар. Алар фикеренчә, XIII гасыр уртасыннан XIV гасыр башына кадәр сугылган бу акчалар бары тик Идел буе Болгары территориясендә һәм аның

икътисади йогынтысы булган мохиттә генә йөргән. Р.Г.Фәхретдинов «Болгарның Алтын Урдадан бәйсез булырга омтылышы шул рәвешле чагылыш тапкан» дип билгеләп үтә. (Ләкин барлык тикшеренүчеләр дә бу карашны хупламый. Көнчыгыш Европа нумизматикасы буенча зур белгеч Ә.Г.Мөхәммәдиев 1983 елгы хезмәтендә болай яза: «Болгарның монгол династиясе ханнарына карата нинди дә булса автономиясе тәңкә акчалар буенча күзәтелми. Күпсанлы XIII гасыр Болгар акчалары — Җүчи Кыпчак олысының рәсми дәүләт акчалары».)

4. XIV гасырның беренче яртысында Болгар өлкәсе хакимнәре җитди сәяси адымнар ясыйлар. Мәсәлән, 1330–1331 елларда Болгар илчеләренең Мисыр солтаныән-Насыйрга барулары аеруча кызыклы факт. Шул турыда безгә, әл-Макризига таянып, үзенең «Связи между Нилом и Волгой в XIII–XIV вв.» хезмәтендә хәзерге Мисыр тарихчысы Әмин әл-Холи хәбәр итә. С.Х.Алишев фикеренчә, «Болгар ханы илчеләре бөек Үзбәк хан рөхсәте беләнме, әллә Алтын Урданы читләтепме — ничек җибәрелгән булуларына карамастан, бу хәл барыбер Болгар патшалыгының автономиясен һәм мөстәкыйль сәяси чыгышларга сәләтле булуын аңлата».

5. XIV гасырның икенче яртысында Идел буе болгарлары яшәгән территорияләрнең Урдадан чыгучылар тарафыннан басып алынуы шулай ук бу җирләрнең билгеле бер дәрәҗәдә мөстәкыйль булуларын дәлилли. Мәсәлән, 1361 елга каршы рус елъязмачысы түбәндәгене хәбәр итә: «Булат-Темир, князь ордынский, Болгары взял, и все грады по Волзе и улусы поимал, и отня весь Воложский путь». Мондый вакыйгалар Туктамыш хан идарә иткән чорда да булгалаган (1380–1398).

Күргәнебезчә, Болгар төбәгенең Алтын Урдага буйсынган дәвердә билгеле бер автономиягә ия булуын раслаучы дәлилләр җитәрлек.

Инде Алтын Урда чорында илнең иҗтимагый-икътисади һәм мәдәни тормышын күзәтеп үтик.

Алтын Урда чорында Идел буе болгарларының иҗтимагый-сәяси тормышына яңа иҗтимагый мөнәсәбәтләр үтеп керә башлый. Ләкин, кайбер яңалыкларга карамастан, Идел буе Болгары эчендә әле XIII гасыр башында ук локальләшә башлаган болгар «бәклекләре»нең үзенчәлекле иҗтимагый-сәяси төзелеше сакланып кала. Беренче чиратта моны Урда ханнары хакимлек иткән чорда регионда әйләнештә булган иҗтимагый терминология буенча күрергә мөмкин.

Монгол (Урда) ханнары һәм ясаклы болгар халкы арасында арадашчы ролен уйнаган иң югары иҗтимагый-сәяси титул «әмир» титулы булган. Болгарларда XIII гасырдан күпкә алданрак барлыкка килгән һәм русларның «великий князь» төшенчәсенә тәңгәл бу титул сакланып кына калмыйча, Урда чорында регионда тагын да киңрәк тарала. Алда билгеләп үтелгәнчә, бу титул буыннан буынга күчә торган була, ә тәхетне нәсел буенча тапшыру болгарларда XV гасыр уртасына кадәр саклана.

«Хан» һәм «солтан» титуллары, алар белән җирле феодаллар һәм ясаклы халык бик яхшы таныш булсалар да, Урда чоры Болгар өлкәсендә кулланылмаган. А.Х.Халиков моны «болгарларның монгол изүенә каршы үзенә күрә бер протесты» дип атый. Минемчә, моның асылы башкада — Чыңгыз хан нәселеннән булмаган җирле аксөякләрнең зур мәгънәгә ия бу титулларны кулланырга хокуклары булмаган. Феодалларны шулай «дәрәҗә баскычына төзү» (ранжирлау) гадәте бөтен дөньяда билгеле.

Алтын Урда чоры болгарлар эпитафияләрендә феодаль таркау Болгарның аерым өлкәсенә ия булучыны билгеләгән «бәк» титулы еш очрый.

Урта гасырлар ислам дөньясында киң таралган, «князь» төшенчәсенә якын «мәлик» титулы да болгарларга ят булмый. Моны Сәфәр мәлик һәм Шамар мәлик каберләренә куелган Болгар кабер ташлары раслый, дөрес, монда аларның аталарының чыгышы Харәзем һәм Ираннан булуы искәртелгән.

Урда чоры Болгарында хуҗа, хаким мәгънәсен аңлаткан «хуҗа» титулы киң таралган соционимнардан була. Тиешле милек күләме сакланганда, титул нәселдән нәселгә дә күчә алган. Еш кына Урда ханнары һәм аларның түрәләре мондый хуҗаларны «тамгачы» дип аталган салым һәм ясак җыючылар итеп билгеләгәннәр, шундый мисалны Суварлы Ибраһим тамгачыга 1314 елда Олы Тарханда куелган кабер ташыннан укырга мөмкин.

XIII–XIV гасырларда җир биләүче мәгънәсендә «алпавыт» дигән яңа иҗтимагый термин барлыкка килә, моны шулай ук эпиграфик мәгълүматлар буенча күрергә була.

Алтын Урда чоры болгарлар эпиграфикасында сирәк кенә мәгънәсе буенча «хуҗа» терминына якын «сахиб» гарәп соционимы очрый.

Атап үтелгән феодалларның күбесе шулай ук нәселләре белән хәрбиләр — «йори» да булганнар. Бу болгар термины ике кисәктән тора: «йау» — сугыш һәм «ир» — ир-ат. Аның борынгы төрки сүзе «чериг-чирү» — гаскәр белән бәйле булуы да мөмкин. Бу нәсел буенча күчүче вазифа, ә бәлки шөгыль дә булган, аның турында кайбер шәҗәрәләрдә дәлилләр очрый: «Мөхәммәд-Мир Мәхмүд улы Әтрәч йори улы Гали йори улы Хәсән йори улы Әйүб йори улы Йагкуб йори улы Арс-Сирадж йори» һ.б. Бу хөрмәтле титулны йөртүче сюзеренының хәбәр итүеннән соң ук билгеләнгән урынга корал, атлар һәм хәрби отряд белән

килеп җитәргә тиеш булган. Алар тарханнар кебек үк берникадәр льготаларга ия булганнардыр, мөгаен. Соңгыларының Урда чоры Болгарында булулары хакында миңа билгеле түгел, ләкин аларның башта болгарларда, ә соңрак Казан ханлыгында да булуын исәпкә алсак, мондый титулның һәм тархан ташламаларының Урда чоры болгарларында да булуын фаразларга мөмкин. Соңгылары билгеле дәрәҗәдә XIV–XV гасырларда Җүчи олысында кертелгән сөйургал льготаларына тиң була, шуңа күрә «йори» титулы бик тиз «сөйургал» титулы белән тиңләшә алган. Д.Г.Мөхәммәтшинның һәм Ф.С.Хәкимҗановның Казан ханлыгының Җөри даругасының (хәрби-административ берәмлек) атамасы «йори» терминына бәйле дигән гипотезалары кызыклы.

Болгарның үз рухани, хөкем һәм хакимият югары катламнары да булган. Алар арасында «шәех» — баш рухани, «казый» — баш рухани-судья, «бахши» — канцелярия эшләрен алып баручы вазифалары аерылып тора. Бу кешеләр гадәттә аксөякләр нәселеннән булган.

Изге мөселман урыннарына хаҗ кылучыны аңлаткан «хаҗи» теонимы да таралыш ала. Болгарлар арасында бу теонимны шактый кеше йөрткән була. Мондый титул хөрмәт билгесе булып саналган һәм бернинди өстенлекләр бирмәгән.

Дәүләттә игенчеләр, һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр күп булган. Шуның белән бергә инде ярым крепостной һәм коллар катламы да барлыкка килә. Соңгыларын күбесенчә хәрби тоткыннар һәм сатып алынган әсирләр тәшкил иткән. Мәсәлән, рус елъязмаларында 1375 елда Новгород яугирләренең Кострома һәм Түбән Новгородны талаулары, ә аннары Болгарга килеп барлык әсир христианнарны сатулары турында хәбәр бар.

Җүчи олысы буенча абруйлы тарихчы Г.А.Федоров-Давыдов фикеренчә, бу дәүләтнең утрак тормышлы районнарында, гомумән алганда, әле XIII гасыр башында ук формалашкан феодаль мөнәсәбәтләр әллә ни зур үзгәрешләрсез үсешен дәвам иткән. Мондый хәл шулай ук Болгар төбәге өчен хас була. Димәк, элеккеге салымнар да сакланган дип фаразларга кирәк: «гошер» — дәүләткә яки феодалга түләнгән уннан бер өлеш, «хәраҗ» — җир-төтен салымы, «җизья» — кяферләрдән җыелучы салым, «зәкят» — мөселманнар тарафыннан фәкыйрьләр файдасына салым һ.б. Моннан тыш Болгар территориясенә тагын Урда ханнары керткән салымнар була: «тамга» — халык саны алу мәгълүматлары нигезендә уннан бер күләмендә алынган ясак, «калан» — уңыштан, терлектән натуралата түләү, «сука салымы» — җир салымы һ.б. Төрле йөкләмәләр дә булган — хәрби, төзелеш, почта йөкләмәсе. Һәм болар барысы аерым Урда феодаллары һәм түрәләре тарафыннан регионда үткәрелгән бер тапкыр була торган бик зур салымнарны исәпкә алмыйча.

Яулап алынган Болгарның Алтын Урда дәүләтенә керүе Идел буе Болгарлары икътисадының чәчәк атуына китерә, бу монгол ханнарының эчке сәясәтенә турыдан-туры бәйле була, шуңа күрә Болгар төбәге Евразиянең иң алга киткән һәм икътисади прогрессив регионнарының берсе буларак үзенең алдынгы урынын саклап кала.

Бу чорда өч кыр системасына таянган игенчелек халыкның төп шөгыле булып кала. Җир эшкәртү кораллары һәм үстерелгән культуралар исемлеге сизелерлек үзгәрешләр кичерми. Болар барысы да Алтын Урда чорында Болгар төбәге игенчелегендә әле монголларгача нигез салынган гадәтләр үсешен дәвам итүен ачык дәлилли. Бу исә, А.Ю.Якубовский бик төгәл билгеләгәнчә, өлкәне («Булгар с его областью») Алтын Урданың иң мөһим игенчелек районнары рәтенә куя.

Болгарлар терлек һәм кош үрчетү белән актив шөгыльләнгәннәр. Урда чоры Болгар көтүлекләрендә күпчелекне вак терлек төрләре тәшкил итә башлый, мөгезле эре терлек икенче урынга күчә, атлар — өченчегә. Кәрваннар белән монда еш кына ишәк һәм дөяләр килгән. Терлекчелек продукциясе халыкны азык-төлек белән генә түгел, һөнәрчеләрне материал белән дә тәэмин иткән. Аерым алганда болгар осталары эшләгән югары сыйфатлы күн әйберләр бөтен дөньяга таралган.

Болгарларның шөгыльләренә аучылык һәм балыкчылыкны да өстәргә була. Моны болгар торак урыннарындагы остеологик материал дәлилли. Шулай ук җыючылык һәм чолыкчылык, ягъни җиләк-җимеш һәм урман умарталары балын җыю да халык кулланышында булган.

Алтын Урда чорында болгарларда әле монголларга кадәр үк барлыкка килгән һөнәрләрнең бар төрләре дә үсешен дәвам итә: тимер кою, тимерчелек, бакыр кою, зәркәнчелек, чүлмәк ясау, пыяла әйберләр ясау, күн эшкәртү, туку, сөяк кисү, киез басу һ.б. Алар барысы да эчке резервлар һәм Түбән Идел буе, Кавказ, Кырым, Харәзем, Русь һәм башка төбәкләрдән килүче һөнәрчеләр хисабына үсеш алган.

Идел-Урал регионы өчен болгарларның сәүдәгә маһирлыгы зур роль уйнаган. Җүчи олысының башлангыч ныгу чорында ул монгол ханнары өчен дә бик әһәмиятле була, чөнки Урда икътисадына һәм дәүләттәге товар-акча мөнәсәбәтләренә нигез сала. Моны күп тикшеренүчеләр, аерым алганда Г.А.Федоров-Давыдов һәм Ә.Г.Мөхәммәдиев билгеләп үтәләр. Болгар иленең үзбилгеләнүгә омтылышы

шартларында сәүдәгәрләр элекке хәлләренә тиз әйләнеп кайталар һәм яңа үрләр яулый башлыйлар. Бу турыда күпсанлы язма һәм археологик чыганаклар сөйли.

Болгарда һөнәр һәм сәүдә үзәкләре — шәһәрләр булган. Археологик чыганаклар Алтын Урда чорында Болгар илендә шәһәрләрнең күплеген һәм алардагы тормышның бик интенсив булуын раслый. Алар арасында XIII гасырның икенче өлешеннән башлап XIV гасыр ахырына кадәр Болгарның номиналь үзәге һәм бик аз вакыт Чыңгызидлар резиденциясе булган Болгар шәһәрен, Самар, Кәкреш, Әтрәч, Кирмән, Урмат, Чаллы, Кирмәнчек, Җүкәтау, Наручад, Алабуга, Казан һ.б.ларны атарга мөмкин. Г.А.Федоров-Давыдов фикеренчә, «Алтын Урда чоры Идел буе Болгары шәһәрләре мәдәни яктан да, иҗтимагый яктан да, территориаль мөнәсәбәттә дә монголларга кадәрге шәһәрләр дәвамы булган». XIV гасырның икенче яртысында аларның күбесе болгар солтанатлары (бәклекләре) үзәкләренә әверелә.

Алда сөйләнелгәннәргә нигезләнеп, Алтын Урда чорында болгарларның иҗтимагый тормышы, гомумән алганда, монголларга кадәрге чор традицияләрен дәвам итә, шулай ук Болгар төбәгенең икътисади үсешендә күбесенчә Урда ханнарының регионда алып барган сәясәтләренә бәйле җитди алгарыш күренә дияргә була.

Алтын Урда чорына кагылышлы сизелерлек үзгәрешләр Болгар иле халкының матди һәм рухи мәдәнияте өлкәсенә карый. Беренче чиратта бу хәл Болгар җирләренә яңа кешеләр, шул исәптән Урта Азия, Кавказ, Төньяк Кара диңгез буе мәдәни үзәкләреннән һәм шулай ук Себер һәм Монголиянең кайбер районнарыннан күчеп килүчеләр белән бәйле була. Шулай ук бу процесста Алтын Урда дөнья империясенә әйләнгәннән соң, көнчыгышта Көнбатыш Себер һәм Харәземнән алып көнбатышта Дунай Болгары патшалыгына кадәр чиксез зур территориядә болгар сәүдәгәрләре алып барган актив эшчәнлек әһәмияте кечкенә булмый. Моннан тыш Алтын Урда үзе дә Мисыр һәм Сүриядән алып Тын океангача сузылган башка монгол олыслары белән тыгыз бәйләнештә торган. Болгар төбәге Көнбатыш илләре өчен дә ачык булган, ә болгарлар үзләре Русь, Прибалтика, Үзәк Европа һәм Скандинавия өлкәләрендә сәүдә иткәннәр. Шулай итеп, болгарлар дөнья мәдәниятенең бик күп казанышларын үзләштерү мөмкинлегенә ия булганнар һәм үзләштергәннәр дә.

Җүчи олысының дәүләт буларак формалашу һәм үсеш чорында Идел буе болгарлары яшәгән территорияләрдә нинди этник процесслар барган соң?

1. Монгол яулап алулары вакытында җирле халыкның шактый өлеше элек торган урыннарын ташлап, чагыштырмача яңа, алдан яхшы өйрәнелгән урыннарга күченергә мәҗбүр ителә, бу җирләргә болгарлар әле X–XII гасырларда ук үтеп керә башлаган булалар. Иделдән көнбатышка таба, Кама аръягына — Мишә һәм Казансу ярларына, Зөянең түбән агымына, Вятка һәм Чыпца елгалары буйларына, Агыйделнең түбән агымындагы җирләргә күпләп күченү күзәтелә. Халыкның бер өлеше элекке биләмәләрендә — Камадан көньякта да кала, ләкин бу районнар инде монгол гаскәрләре килгәнгә кадәрге кебек үк тыгыз булмый.

Болгар җирләренең көнбатыш районнары да үзгәрешләр кичерә. Аерым алганда Сура елгасы бассейнында һәм Иделгә якын районнарда торак урыннар саны кисәк кими. Юлов шәһәрлеге урынында урнашкан, бу җирләрнең элеккеге үзәге булган зур торак урыны юкка чыга һәм кабат торгызылмый. Моңа капма-каршы буларак тагын да көнбатышрак районнарда болгарлар тибындагы торак урыннарның саны артуы күзәтелә. Шулай итеп, монгол явыннан соң Идел буе болгарлары яшәгән территориянең үзәктән читләшү процессы башланып китә һәм вакыт узу белән аның күп үзәкле территориягә әйләнүенә китерә.

Алтын Урдада Үзбәк хан идарә иткән һәм татар дәүләтенең чәчәк атуы белән билгеләнгән чорда (1312–1342) Болгар иле халкының бер өлеше кабат Камадан көньякта урнашкан җирләренә әйләнеп кайта, ләкин инде яңа үзләштерелгәннәрен дә саклый.

Бу вакытта Идел буе болгарлары яшәгән территориянең көньяк чикләре, элеккечә Уса елгасы һәм Иделнең Самара борылышы (Жигули), Самара елгасының түбән агымы, аның уң кушылдыгы Кинели буенча үткән. Монда Самара археологлары тарафыннан үзендә чүлмәк ясау, тимер кою һәм сөяк кисү буенча һөнәрчеләр эшчәнлеге эзләрен саклаган беренче Сухоречие торагы кебек XIII–XIV гасыр эре болгар авыллары калдыклары тикшерелә. Аннан көньякка таба болгар авылларыннан якын гына кыпчакларның күчеп йөрү урыннары урнашкан, моны аларның Самара елгасының сул ярында табылган курган каберлекләре раслый.

Камадан көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыштарак урнашкан җирләр Урда чоры Болгарында да, аңа хәтле дә тулысынча үзләштерелмәгән була. Сок һәм Кондырча елгалары бассейны территориясендә халыкның утрак урыннары бик аз була, монда күчмә дала халыклары еш үтеп керә. 1391 елда Аксак Тимер белән Туктамыш арасындагы хәлиткеч сугышның нәкъ менә шушында, Сок һәм Кондырча арасында үтүе очраклы түгел.

Төньякка таба Идел буе болгарларының җирләре элеккечә Зур Чирмешән, Чишмәнең югары агымнарына, Зәйнең түбән агымыннан Түбән Камага хәтле чыккан. Төньяк-көнчыгышта болгар авыллары

Чаллы елгасы бассейнында һәм ешрак Ык елгасының урта һәм югары агымында урнашканнар, мәсәлән, шундыйлардан шактый зур мәйданнарны биләгән Бикбул торак урыннарын атарга була. Сөн елгасы буенча болгарлар Агыйделгә чыкканнар, ә Болгар миссионерлары Агыйделнең урта агымнарына да барып җиткәннәр, моны төзелү вакытлары XIV гасырның беренче яртысыннан да соңрак булмаган Башкортстанның Чишмә районында урнашкан мөселман мавзолейлары дәлилли. Агыйделнең Башкортстандагы көньяк борылышындагы болгар-урда керамикалы Берек торак урынын исәпкә алганда, алар күпкә көньяккарак та үтеп кергәннәр.

Агыйдел тамагыннан төньяккарак Кама һәм Вятка буенча Болгар протектораты астына кергән җирләр урнашкан була. Монда әле монгол явына кадәрге чорда болгардан чыккан һәм 1236–1240 елларда монголлардан качкан халык тыгыз урнашкан ике өлкә аерылып тора. Шуларның берсе — Чыпца елгасы буенда урнашкан Карин җире дип аталучы территория, монда болгар элементлары шактый ачык чагылган Чыпца мәдәнияте аерылып тора, икенчесе — Кама буендагы Пермь җире.

Болгарларның яшәү урыннары төньяк-көнчыгышта Вятка тамагыннан узмаган. Урда чоры болгар истәлекләренең шактый зур төркеме булган Кирмәнкә бассейнын үз эченә алган Вятка тамагыннан Болгар территориясе Мишә, Казансу һәм Ашыт-Иләтнең югары агымнарына таба сузылган. Болгар территориясе Казансуның ике яры буйлап Иделгә төшкән, мариларның борынгы бабалары утырган Иләтнең урта һәм түбән агымы районнарын читләтеп үтеп, Иделнең уң ярына, Зөя бассейнына чыккан. Зөя һәм аның югары агымына кадәр диярлек сул яры буйлары Болгарның көнбатыш чиге булган. Болгарлаштырылган Бортас иле территориясе исә Алтын Урда чорында билгеләнми диярлек.

Шулай итеп, Алтын Урда чорында Болгар җире территориясе якынча түбәндәге размерларда була: көньяктан төньякка — 450 км, көнчыгыштан көнбатышка — 500 км, гомуми мәйданы — 225000 кв. км тирәсе. Бу территориядә монголларга кадәр булган халыкның өчтән бер өлешеннән дә кимрәге яши, чөнки монгол явы нәтиҗәсендә бик күп кеше юкка чыга. Безгә бу турыда гарәп һәм рус язма чыганаклары, шулай ук Идел буе Болгарының монголлар тарафыннан яулап алыну проблемасына багышланган тикшеренүләр хәбәр итә.

2. XIII гасырның икенче яртысында һәм Алтын Урданың үсеш чорында Идел буе болгарларының яшәү урыннарына монгол гаскәре белән бертөрле этник төркем вәкилләре үтеп керә. Рус язма чыганаклары, ә аларга ияреп шактый тикшеренүчеләр монгол гаскәренең күпсанлы булуын һәм 600 мең яки аннан да күбрәк — миллионга кадәр (!) сугышчыны берләштерүен хәбәр итсәләр дә, аларга җитди анализ белән карарга, башка төрле чыганакларга таянырга туры килә. Гаскәр башлыклары җитәкчелегендәге бу гаскәрнең аз санлы — 25 тән алып 130 меңгә кадәр кешеле, ләкин бик хәрәкәтчән һәм бик яхшы оештырылган булуын раслый. Шәрекъ язма истәлекләре нигездә шул саннарны китерә. Өстәвенә гаскәрдә монголлар саны 50 проценттан артмаган, монгол гаскәренең калган өлешен алар тарафыннан яуланган төрки яки башка көнчыгыш халык һәм кабилә вәкилләре, аерым алганда Урта Азия төркиләре тәшкил иткән. Көнчыгыш Европаны яулап алганнан соң монгол гаскәре сугышчыларының күбрәк өлешенең туган далаларына кире кайтуы әйтелә. Бу вакытта Көнчыгыш Европаның җирле халкы берничә миллион, шул исәптән Идел буе болгарларын һәм башка җирле халыкларны үз эченә алган Идел буе Болгарының XIII гасыр башында халык саны 200 меңнән дә ким булмавын исәпкә алсак, җирле этник мохитенә монгол-татарларның тәэсире әһәмиятле булмавы аңлашыла. Этник конверсация[11] процессында алар җирле болгар-кыпчак-угыз халкы арасында бик тиз юкка чыгалар, моның турында мисырлы әл-Гомәри ачык яза. Шул уңайдан бик еш өземтәләр китерелә: «Борынгы чорда бу дәүләт кыпчаклар иле булган, ләкин аны татарлар яулап алганнан соң, кыпчаклар аларның кул астында кала. Соңрак алар (татарлар) белән кыпчаклар кушылганнар һәм туганлашканнар, һәм җир аларның (татарларның) табигый һәм раса үзенчәлекләреннән өскә чыккан һәм алар барысы да кыпчаклар шикелле булып беткәннәр, гүя алар (алар белән) бер нәселдән, чөнки монголлар (һәм татарлар) кыпчак җирләрендә урнашып, алар белән никахлашканнар һәм яшәргә төпләнгәннәр. Шул рәвешле нинди бер илдә һәм җирдә озак вакыт дәвамында булу кеше холкын үзенә яраклашырга мәҗбүр итә һәм тумыштан килгән үзенчәлекләрне үз табигатенә тиң итеп үзгәртә». Монгол-татарларның ассимиляция процессы аларның аз санлы булулары нәтиҗәсе һәм шуңа күрә закончалыклы күренеш. Җучи олысы хакимнәренең якын кардәшләре Мисыр мәмлүкләре белән берлектә Хулагу династиясе монголларына каршы көрәшүләре дә, турыдан-туры ук булмаса да, Алтын Урда монгол-татарларының кыпчаклашуын раслый. Дөрес, региондагы моңа этәрүче геополитик хәлне дә исәпкә алмыйча булмый. Л.Н.Гумилев бик төгәл билгеләгәнчә, монгол «тамчысы» болгар-кыпчак «диңгезендә» эзсез диярлек эреп югала, һәм аннан бары тик патшалык итүче династия генә кала. Нәкъ менә шуңа күрә XIII–XIV гасырларда Шәрекъ дөньясы елъязмачылары Җучи олысын Кыпчак дәүләте («Дәште Кыпчак») дип исемләгәннәр.

Ләкин, минемчә, монгол-татарларның җирле этник мохиттә уйнаган һәм аларның сәяси хакимияткә ия булуларында чагылган үз-үзен тотышларының актив сыгылмалылыгы белән бәйле булган ролен бөтенләй читкә кагарга да ярамый. Нәкъ менә шушы фактор Алтын Урдада, аерым алганда аның төньяк регионнарында, «татарлар» абруйлы терминының (этноним–политоним–соционим) киң таралуына сәбәп була, ул әкренләп макроэтнонимга әверелә бара. Һәм бу хәлгә моңа башта үзләре үк булышлык иткән монгол аксөякләре дә каршы тора алмый. Ниһаять, 1242–1246 елларда Бату ханның үз ставкасы итеп Болгар шәһәрен сайлап алуын, ә Бәркә һәм Мәнгу Тимер идарә иткән чорда Болгар һәм аның тирәлеге еш кына Урда ханнары һәм аларның күпсанлы яраннары торган урын булуын онытырга ярамый. Моны язма чыганаклардан тыш археологик материаллар да дәлилли.

Мәсәлән, Болгар шәһәрлеге әйләнә-тирәсендә йә монголлар, йә монголларның көнбатышка таба хәрәкәте вакытында алар арасына тартылган Көнчыгыш Себер — Көнчыгыш азиат кабиләләре вәкилләре җирләнгән кечерәк курганнар казып тикшерелгән иде. Себер төбәге раса үзенчәлекләренә хас булган мәҗүси каберлекләр кайбер башка урыннарда да билгеле.

Моны антропологик материал да исбатлый. Тикшеренүчеләр бу чор Болгар җире халкының бер өлешендә монголоид элементының күпкә булмаса да артуын билгеләп үтәләр. И.Р.Галимҗанов яза: «...Көньяк Себер яки Үзәк Азия кыяфәтле монголоид морфокомплексы урта гасыр шәһәр (Болгар) җәмгыятенең иҗтимагый элитасына хас була... Хан төрбәсе (Болгар), Мари-Лугов каберлеге һәм җыелма «Урта гасырлар Урта Идел буе күчмә халыклары» сериясендә чагылган Урта Идел буе халкының монголоид төркемнәре Урта Идел буе территориясе Алтын Урда серияләре арасында аерым урын алып торалар. Бу серияләрдә Үзәк Азия яки Көньяк Себердән башлангыч алган монголоид морфотибындагы баш сөякләре өстенлек итә — ачык чагылган брахикран баш сөяге уртача профильләнгән борынлы эре һәм яссы бит өлеше белән яраша. Бәлкем, бу төркемнәр генетик яктан Алтын Урданың үзәк яки көнчыгыш өлкәләре белән бәйледер... Шулай итеп, безнең тарафтан көньяк, көньяк-көнчыгыш дала халкы белән тиңләштерелә алган антропологик тип (монголоид, Көньяк Себер яки Урта Азия чыгышлы тип) йә Алтын Урда составындагы Идел буе Болгары тирә-юнендә, йә шәһәр халкы мохитендә билгеләнә. Аз санлы булулары аркасында, иҗтимагый хәлләре һәм этнокультур гореф-гадәтләренә бәйле рәвештә аның җирле халык белән бәйләнешләре чагыштырмача зәгыйфь булган һәм нигездә элекке вакыттагы структурасын саклап калган антропологик составын сизелерлек үзгәртә алмаган... Элеккеге вакыт белән чагыштырганда (Алтын Урда чорында) этногенетик бәйләнешләр характеры үзгәрми диярлек, бигрәк тә элекке Идел буе Болгарының үзәк өлкәләренең авыл төркемнәре арасында. Алтын Урданың үзәк мәркәзләренең берсе — Болгар шәһәре халкы формалашканда, үзенчәлекле шартлар нәтиҗәсендә бераз башкарак этногенетик хәл туа. Краниология һәм археология мәгълүматлары буенча, монда килмешәк һәм җирле этнокультуралар төркемнәренең үзара тәэсир итешүе күзәтелә. Аларның баштагы механик симбиозы иртә Алтын Урда чоры ахырына таба акрынлап биологик төсмер ала. Шәһәр җәмгыятенең монголлардан яки Үзәк Азия һәм Көнчыгыш Себер кабиләләре вәкилләреннән торган өске катламы гына чыгарма булып тора. Аларның үзенчәлекле иҗтимагый хәлләреннән (Алтын Урданың үзәк хакимияте вәкилләре булган җирле хәрби-административ аппарат) һәм этнокультур традицияләреннән чыгып, аларның җирле халык белән бәйләнешләре шул исәптән генетик яктан да минималь булган...»

3. Алтын Урда чорында этник процессларга Идел-Урал регионы һәм Дәште Кыпчак арасындагы элек тә күбесенчә шартлы чикләрнең юкка чыгуы нык тәэсир итә. Бу хәл Урта Идел буе һәм Евразия далалары халыклары арасында этник бәйләнешләр көчәюенә китерә.

XIII–XV гасырларда Идел-Урал регионы күбесенчә әле монголларга хәтле үк башланып киткән кыпчак миграцияләре мәйданына әверелә. Кыпчакларның Идел-Кама буйларында күпләп күченеп йөри башлаулары XIII гасырның беренче өлешенә туры килә. Ул күчеш турыдан-туры монгол яулары белән бәйле. Бу турыда безгә язма чыганаклар һәм археологик казылма материаллар хәбәр итә. XIII гасыр ахырында һәм XIV гасырда кыпчак һәм кыпчаклашкан этник төркемнәрнең Урта Идел төбәгенә килүе дәвам итә. Минемчә, бу процесс өчен Алтын Урда чорында кыпчак далалары халкының мөселманлашуы, нәтиҗә буларак бу халыкның мөселман мәдәнияте югары үсеш алган регионнарга тартылуы да әһәмияткә ия булган. Шулай ук көньяк далаларда күчмә җитештерүчәнлек үсеше өчен урын җитешмәве һәм далада табигать үзгәрешләре дә зур роль уйнаган.

Шулай итеп, Алтын Урда чорында болгар халкының тышкы факторлар тәэсирендә дифференциациясе фонында аның Көнчыгыш Европаның башка этнослары белән интеграция процессы бара. Өстәвенә кыпчаклардан тыш XIII–XIV гасырларда Идел буе болгарлары яшәгән территориягә шулай ук Урта Азия, Кавказ, Ираннан чыккан кешеләрнең дә үтеп керүе билгеләнә. Бу турыда Болгар шәһәрлегенең төньяк-көнбатыш ягында табылган киң әрмән колониясе калдыклары, Суварның Алтын Урда чоры катламындагы торак калдыклары, Урда чоры Болгарының төрле җирләрендә куелган эпитафияләр һәм шулай ук

атропологик материал сөйли. Бу эмигрантлар күбесенчә феодаль аксөякләр катламына караганнар һәм Болгар иленә үз хезмәтчеләре белән килгәннәр. Бу хәл, әлбәттә, Урда чоры Болгары халкының этносоциаль составын баета һәм катлауландыра.

Бу фактлар, болгарларның Алтын Урданың көньяк районнарында да булуы белән беррәттән, XIII гасыр ахыры — XIV гасырның беренче яртысында Алтын Урдада төрле шартлар аркасында тәмам формалашып җитә алмаган һәм XIV гасырның икенче яртысында таркалган гомуми Алтын Урда этносы формалаша башлавына китергән этникара интеграция процессы булган дигән нәтиҗә чыгарырга мөмкинлек бирә.

4. Элеккечә үк Алтын Урда чорында да Идел буе болгарларының җирле угро-фин кабиләләре вәкилләре белән катнашуы дәвам итә. Моңа шактый дәрәҗәдә болгар этносының бер өлешенең угро-фин халыклары яшәгән территорияләргә актив миграциясе һәм шулай ук региондагы угро-фин халкының өлешчә мөселманлашуы сәбәп булып тора.

5. Алтын Урда чорында Идел буе болгарлары һәм угро-фин этник төркемнәренә көнчыгыш славян халкы да үтеп керә. Моны Болгар иленең төрле өлкәләрендә табылган аларның XIII–XIV гасыр торак урыны калдыклары дәлилли. XIV гасырның икенче яртысында югары катлам рус феодалларының экспансионист омтылышларын көчәйтүгә китергән рус этносының үсешенә бәйле рәвештә бу процесс тагын да активлаша.

6. XIV гасырның икенче яртысында Җүчи олысында башланган һәм дәүләтнең таркалуына китергән этносәяси кризис, рус һәм Урда феодалларының Урта Идел буе территориясенә, аерым алганда болгар солтанатларына яулары, Туктамыш белән Аксак Тимер арасында барган коралды көрәш шартларында, шулай ук табигать катаклизмнары аркасында Идел буе болгарлары торган урыннарының көньяк районнарыннан инде XIII гасырда ук Казан дәүләте чикләре формалаша башлаган һәм чагыштырмача тыныч булган Казан тирә-юненә күпләп күчеп утыра башлыйлар. Бу чорда Идел буе болгарлары «болгар» политонимын, «мөселман» теонимын һәм төрле урыннарга бәйле атамаларны — «болгарлылар», «казанлылар», «җүкәтаулылар» һәм башкаларны төп үзатама итеп кабул итәләр. Болгар халкының Болгар иленең төньяк районнарына миграциясе кыпчак миграциясе белән бергә бара, ул XV гасырның беренче яртысында тагын да көчәя.

Болгарларда урыннарга бәйле төрле этнонимнар булуы XIV гасырның соңгы өчтән бер өлешендә Җүчи олысының кайчандыр бердәм Идел буе Болгарын тәшкил иткән төньяк тарафында, Кама аръягында — Болгар, Җүкәтау, Тубылгытау, Балынгуз; Кама алдында — Кашан һәм Казан; Идел каршында — Әтрәч һәм Тәтеш; болгарлашкан бортаслар җирләрендә — Наручад, Төмәнлек һәм Нижнепьянское бәклекләре булуы белән бәйле.

Аксак Тимергә каршы орышларда җиңелүләр Туктамыш хан хакимиятен хәлсезләндерә. Һәм бу хәл XIV гасыр ахырында болгар феодалларында Үзбәк хан вафатыннан соң ачык сизелгән сепаратист омтылышларның көчәюенә һәм болгар өлкәләренең Алтын Урда карамагыннан тәмам аерылып чыгуларына китерә. Моны Идел буе болгарларының бәйсезлеген мөселман дөньясына таныту максаты белән Болгардан Каһирәгә илчелек юнәлтү факты исбатлый.

Идел буе Болгарының Алтын Урдага буйсынуыннан чыгуы мөстәкыйль Болгар җирләрен басып алырга омтылган Урда һәм рус феодаллары тарафыннан хәрби басымның активлашуына китерә. 1396 һәм 1399 елларда рус князьләре Казанга яулар оештыралар. 1405–1407 елларда Болгар җирләренең Кама арты районнарын Идегәй яулап ала. 1407 елда, М.Г.Сәфәргалиев фикеренчә, Болгар илендә Урда вәкиле Җәләлетдин идарә итә. 1409 елда Новгород гаскәре Идел буе болгарлары җиренә хәрби экспедиция оештыра. Ә 1431 елда Болгар яулана һәм Болгар бәклеге бөтенләй бетерелә. Елъязма хәбәр итә: «...Тое же весны князь велики Василей Васильевич посылал ратью на Болгары Волжскиа и Камскиа князя Федора Давидовича Пестрого; он же шед, воева их и всю землю их плени...». Бу җиңелү һәм аерым алганда XV гасырның беренче өлешендә Болгарда күзәтелгән табигый катаклизмнар болгар халкының регионның төньягына таба күченүен дәвам итү нәтиҗәсе булып тора. Хакиме үз тирәсенә болгар династиясе вәкилләрен туплый алган Казан ныгытмасы тәмам өлкәнең сәяси, икътисади һәм мәдәни мәркәзенә әверелә.

Яңа дәүләтнең башкаласы Казанның еш кына Яңа Болгар (Болгар әл-җәдид) дип аталуы, дәүләтнең XVI гасыр яртысына кадәр еш кына Болгар иле (Болгар вилаяте) дип исемләнүе күзәтелә. Яңа төбәк халкының озак еллар дәвамында XV гасырда өстенлек итә башлаган «казанлы» политонимы белән беррәттән «болгар» этно-политонимын да куллануы бик гыйбрәтле. Шулай итеп, яңа дәүләт халкы Идел буе Болгары һәм Казан дәүләте арасындагы дәвамчылыкны ассызыкларга тырышкан. Шундый хәл 1445 елда Казанда турыдан-туры Урда династиясе урнашканнан соң да күзәтелә.

## 2. Казан дәүләтендә Урда династиясенең турыдан-туры хакимияте урнашуы

*Илдә дәүләтнең нигезен тәшкил итүче халыкның этнотрансформациясе*

Бу мәсьәлә Казан ханлыгы тарихында, ә киңрәк алганда электән Урта Идел буе территориясендә яшәгән күп халыкларның (беренче чиратта Казан татарлары тарихында) этносоциаль һәм сәяси тарихында иң принципиаль проблемаларның берсен тәшкил итә. Хәзерге вакытка тикшерелгән чыганаклардан беренче булып бу проблемага «Казанская история» («Казан елъязмасы») кагыла. Соңрак аны Андрей Лызлов, Петр Рычков, Шиһабетдин Мәрҗани, Владимир Вельяминов-Зернов, Мөхәммәд-Морад Рәмзи, Гайнетдин Әхмәрев, Риза Фәхретдин, Габделбари Баттал, Һади Атласи, Михаил Худяков, Әкъдәс Нигъмәт Курат, Алексей Смирнов һәм башка шундый күренекле тарихчылар җентекләп өйрәнәләр. XX гасырның икенче яртысында бу мәсьәләгә карата үз фикерләрен С.Х.Алишев, М.И.Әхмәтҗанов, Д.М.Исхаков, Н.Ф.Калинин, Ә.Г.Мөхәммәдиев, Ш.Ф.Мөхәммәдьяров, М.Г.Сәфәргалиев, М.Г.Госманов, Р.Г.Фәхретдинов һәм башка галимнәр, аерым алганда А.Г.Бахтин язып чыктылар. Бу мәсьәлә буенча тарихчыларның фикерләре еш кына принципиаль рәвештә аерылалар, һәм проблема гомумән алганда тәмам чишелмәгән булып санала.

* * *

1419 елда Алтын Урда тәхетенә Бөек Литва кнәзе Витовт ярдәмендә куелган Олуг Мөхәммәд хан утыра. Ул Җүчи хан нәселеннән була. Төрле чыганакларда аның атасы буларак Тимер хан, Җәләлетдин, Эчкеле Хәсән һәм башка Чыңгызидлар атала. Кайбер чыганаклар Туктамыш ханны Олуг Мөхәммәднең бабасы дип күрсәтә. Хәзерге вакытта Олуг Мөхәммәднең иң дөрес шәҗәрәсе дип түбәндәгене атарга була: Олуг Мөхәммәд — Хәсән — Чинче — Тулак Тимер — Кончак — Сарыча — Үз-Тимер — Тукай Тимер — Җүчи — Чыңгыз хан.

Тәхеткә Олуг Мөхәммәднең утыруы Туктамыш хан һәм Идегәй әмир вафатыннан соң Җүчи олысында башланган үзара ызгышларны туктатмый. Бу турыда үз хроникасында әл-Гайни яза. Нәкъ шушы сәбәп, М.Г.Сәфәргалиев фикеренчә, Алтын Урданың ике мөстәкыйль өлешкә бүленүенә китерә. Кайчандыр бердәм булган Җүчи олысының көнчыгыш өлешендә Нугай Урдасы барлыкка килә һәм Себер, Үзбәк һәм Казакъ ханлыклары формалаша башлый. Ә көнбатыштагы территорияләр Олуг Мөхәммәд, Дәүләт Бирде һәм Баракъ ханнар арасында рәхимсез көрәш объектына әверелә.

Олуг Мөхәммәднең таянычы булган Бөек Литва кнәзе Витовтның 1430 елның октябрендә үлеп китүе ханны авыр хәлгә куя. Литвада үзара талаш башлана. Олуг Мөхәммәднең үзара дошманлашкан Литва феодал төркемнәренең берсен яклавы ике дәүләт арасындагы дустанә мөнәсәбәтләрнең өзелүенә китерә. Литва феодаллары Олуг Мөхәммәдкә каршы позициягә басалар, аның Русьтагы һәм Кырымдагы дошманнары белән якынаерга тырышалар.

Аннан соңгы 6 елда Олуг Мөхәммәд турында мәгълүматлар бик аз. Бары тик ханның Галич-Звенигород кнәзе Юрий Дмитриевичны җиңәргә һәм «Всея Руси» тәхетендә ныклап урнашырга омтылган Мәскәү кнәзе Василий II гә ярдәм күрсәтүен күпчелек рус елъязмалары искә алуын һәм шулай ук хан белән Чыңгызид Кече Мөхәммәд арасындагы каршылыклар турында Иосафат Барбаро информациясен генә билгеләп үтәргә була.

Ике Мөхәммәд арасындагы каршылыклар 1437 елның яз башында җитди сугыш хәрәкәтләре башлануына китерә. 1438 елда Олуг Мөхәммәднең Дәште Кыпчактан куылуы белән тәмамланган бу сугышны аның шаһиты булган Иосафат Барбаро тәфсилләп сурәтләгән. Аның тасвирлавыннан күренгәнчә, хан алып барган эчке һәм тышкы сәясәтнең кайбер яклары белән килешмәгән үз вассаллары тарафыннан хыянәтне Олуг Мөхәммәднең җиңелүенең төп сәбәбе дип атарга була. Үз иярченнәре ташлаган һәм Кече Мөхәммәд кебек «шулкадәр хәтәр дошман белән көрәшергә көч тапмаган»[12] Олуг Мөхәммәд «кечкенә дружинасы белән»[13] Урдадан кача.

Гаиләләре белән иң якын туганнары һәм дусларыннан торган үз Урдасы белән Дәште Кыпчактан куылганнан соң, Олуг Мөхәммәд хан төньякка юл тота һәм тиздән Белев (Биләү) шәһәрендә төпләнә. Шуннан соң хан бөек кнәзь Василий II белән килешү турында сөйләшүләр башлап җибәрә, ләкин кнәзь алардан баш тарта һәм ханга каршы 40 меңлек армия җибәрә. Белев янәшәсендәге орышта Олуг Мөхәммәд сугышчылары җиңү яулый. Шул сугыштан соң Олуг Мөхәммәд турында чынбарлыкка туры килгән мәгълүматлар бик аз. Аның Казанда булу-булмавы төгәл билгеле түгел дип фараз итик. Бары тик ханның

Түбән Новгородны яулап алуы һәм Мәскәүгә каршы яу оештыруы гына төгәл билгеле. 1445 елның язында Олуг Мөхәммәд һәм Василий II гаскәрләре арасында яңа бәрелеш булып ала. Евфим монастыре янындагы данлыклы бу орышта Василийның гаскәрләре тар-мар ителә, үзе әсир төшә. Хәер, тоткынлыкта ул озак булмый, ханга вәгъдәләр биреп, йолым түләп котыла.

1445 елның октябрь-ноябрендә Олуг Мөхәммәд хан Урдасы Казан диварлары янында барлыкка килә. Хан бу борынгы шәһәрдә, ниһаять, үзенә сыеныр урын табарга уйлаганмы, әллә шәһәрне бөтен Алтын Урда территориясендә үзенең хакимиятен торгызу өчен плацдарм буларак кулланырга ниятләгәнме? Бу сорау, күрәсең, җавапсыз калыр. Нәкъ түбәндәге сорау кебек үк: Олуг Мөхәммәд хан Казанда булганмы һәм монда идарә иткәнме?

«Казанский летописец» Олуг Мөхәммәдне, имештер, үз улы Мәхмүд тарафыннан үтерелгән беренче Казан ханы дип атый. Ләкин чыганаклар каршылыклы. 1445 елга карата Воскресение елъязмасы түбәндәгене хәбәр итә: «Тое же осени царь Мамотяк, Улу-Магометов сын, взял город Казань, вотчича казанского князя Либея убил, а сам в Казани сел царствовати». Ә менә бусы 1445 ел вакыйгалары турында Никон елъязмасы хәбәре: «А царь Мамутяк пришед из Курмыша Казань взял, а Казанского князя Азыя убил, а сам на Казани воцарился, и оттоле нача царство быти Казанское». «Родословная книга»дан мәгълүмат: «...у Улу-Мазмета сын Мамотяк, то первый царь на Казани».

Минемчә, рус елъязмаларында язылганча, Казанның Мәхмүд хан тарафыннан яулап алыну фактын дөреслеккә якынрак дип санарга мөмкин. Күрәсең, шул вакыттан башлап Казан дәүләтендә Урда династиясенең турыдан-туры хакимияте урнаша. «Казанский летописец»тан тыш Көнчыгыш Европа дәүләтләре территориясендә иҗат ителгән һәм актив фәнни-тикшеренү әйләнешенә кертелгән XV–XVI гасыр язма чыганакларының башка берсендә дә Олуг Мөхәммәднең беренче (яки нindидер башка номерлы) Казан ханы буларак күрсәтелмәве шундый фикергә этәрә. Бәлки, моңа ишарәләүче нindидер «төрки-татар чыганаклары» да бардыр. Ләкин алар күпкә соңрак барлыкка килгән, һәм алардагы мәгълүматларның чынбарлыкка туры килүе шактый шартлы булса кирәк. Шәхсән миңа мондый чыганаклар билгеле түгел. Нигездә Олуг Мөхәммәд эшчәнлеген игътибарсыз калдырмаган һәм хәтта аны шактый тәфсилле яктырткан, бер-берсенә бәйләнмәгән өч рус язма чыганагының (Воскресение елъязмасы — XVI гасыр гомумрус тупланмасы, Никон елъязмасы — XVI гасыр гомумрус елъязмасы, Мәскәүдә шулай ук XVI гасырда төзелгән татар патшаларының шәҗәрәләр китабы) ханның Казан шәһәрендә булуын, бигрәк тә аның монда патшалык итүе турында бөтенләй искә алмаулары шактый гыйбрәтле.

Шул ук вакытта Олуг Мөхәммәднең күрсәтелгән сәяси процессларда уйнаган ролен инкарь итәргә дә ярамый. Идел буеның урта гасырлар тарихын тикшерүче В.В.Вельяминов-Зернов, Н.Ф.Калинин һ.б. абруйлы галимнәр шундый фикердә торганнар, бүгенге көндә мондый карашны С.Х.Алишев, Р.Г.Фәхретдинов һәм кайбер башка галимнәр яклый.

Ләкин бу мәсьәләгә карата башка фикерләр дә булуын билгеләп үтәргә кирәк. А.И.Лызловның «Казанский летописец»ы дәлилләренә нигезләнгән фикере буенча, «Казан Урдасы» 1257 елдан башлангыч ала һәм Бату хан улы Сартак тарафыннан оештырылган була. Рус елъязмаларының, татар шәҗәрәләренең, эпик хикәятләрнең һәм башка төрки-татар чыганакларының чагыштырмача анализына нигезләнеп тикшеренүче Марсель Әхмәтҗанов фикеренчә, Казан ханлыгы тарихында беренче дата итеп 1361 елны санарга кирәк. Һәм нәкъ шушы вакыттан алып XVI гасыр уртасына кадәр, М.И.Әхмәтҗанов фикеренчә, бу дәүләттә һәрвакыт татар хакимнәре династиясе идарә итә. Казан тарихын яхшы белгән С.Х.Алишев та Казан ханлыгының оешу дәверен 1370 еллар белән билгели. Тарихчы-нумизмат Әзһәр Мөхәммәдиев фикере буенча беренче Казан ханы, ягъни Казан тәхетендә беренче Чыңгызид 1422 елдан алып 1445 елга кадәр идарә иткән Гияс әд-Дин була, ул Казанда 1422 еллардан алып XV гасырның 30 нчы еллары ахырына кадәр сугылган тәңкәләр буенча яхшы билгеле. Ә.Г.Мөхәммәдиев фикеренчә, Никон елъязмасында сүз нәкъ менә аның турында бара («князя Азыя убил...»). Күпчелекне тәшкил итүче башка тикшеренүчеләр, «Казанский летописец»ның 1438 елда Олуг Мөхәммәднең Казанда патшалык итә башлавы турындагы мәгълүматына таянып, аны беренче «чын», «тулы хокуклы» (аңа кадәр булган Казан хакимнәреннән аермалы буларак) Казан ханы дип саныйлар. Һади Атласи, Зәки Вәлиди, Михаил Худяков, Габделбари Баттал, Риза Фәхретдин, Әкъдәс Нигъмәт Курат шундый караштa (төрле вариацияләрдә) тордылар; бүгенге көндә бу гипотеза Шамил Мөхәммәдьяров, Миркасыйм Госманов, Равил Әмирханов тарафыннан яклау тапты. Төрле рус елъязмалары мәгълүматларын берләштерергә тырышу да бар. Имеш, Казан тәхетен башта Олуг Мөхәммәд биләгән, ул җирле «болгар» хакиме Галимбәкне (рус елъязмаларындагы Либейны) ил белән идарә итүдән читләштергән; Олуг Мөхәммәднең 1445 елгы вафатыннан соң Галимбәк Казан тәхетен кире кайтармакчы була һәм шуның өчен гомерен бирә; Олуг Мөхәммәднең улы Мәхмүд Казан ханы була. Соңгы караш Шиһабетдин Мәрҗани тарафыннан әйтелгән иде, һәм ул җитди игътибарга лаек, чөнки, беренчедән, ул төрле чыганаклардагы мәгълүматларны бергә

туплый, ә икенчедән, аталган тикшеренүченең безгә төрле сәбәпләр аркасында танышу мөмкин булмаган күпсанлы шәрекъ чыганакларын һәм шәрекъ историографиясен өйрәнүен дә онытырга ярамый.

Билгеле булган язма, археологик, фольклор чыганакларын тирәнтен анализлау һәм киләчәктә яңа чыганакларны җәлеп итү — алдагы көндә бу катлаулы һәм принципиаль сорауга төгәлрәк җавап табу мөмкинлеген бирер дип өметләнергә кала.

Казан дәүләтендә турыдан-туры (җирле хакимият вәкилләре нәселе булмаган) Урда династиясе хакимияте урнашкач, монда нинди үзгәрешләр барлыкка килә соң?

Бу мәсьәләнең этник аспектын алып карыйк. Кайбер тикшеренүчеләр фикеренчә, Алтын Урда чорында билгеле бер этноэволюциягә дучар булган җирле халык Урта Идел буена Олуг Мөхәммәд Урдасы килү белән этник планда җитди үзгәрешләр кичерми, «үзенең төп массасында абориген болгар чыгышлы булып кала». Татар шәҗәрәләрен өйрәнүгә күп еллар багышлаган галим М.И.Әхмәтҗанов болгарларны «Казан ханлыгының төп халкы» дип атый[14]. Элегрәк шундый ук караштa торган Р.Г.Фәхретдинов үзенең соңгы хезмәтләрендә XV гасыр уртасында Урта Идел буена «шактый күләмдә татар халкы» килүен һәм аның «Казан татарлары халкының тәмам формалашуында зур роль уйнавын» билгеләп үтә. М.З.Зәкиев үзенең кайбер хезмәтләрендә шулай ук Идел буена Олуг Мөхәммәд Урдасы килүе белән «Казан ханлыгында демографик ситуация җитди үзгәрә» дип билгели.

Бу мәсьәләне ачыкларга тырышып карыйк. Беренче чиратта якынча гына булса да, XV гасыр уртасында монда яшәгән җирле халык санын һәм Олуг Мөхәммәд Урдасының зурлыгын билгеләү зарур. Этнолог Дамир Исхаков үзенең хәзерге Идел буе татарларының тарихи демографиясе буенча махсус хезмәтендә чагылдырган фикеренчә, «XV гасыр башында чын мәгънәсендә болгар төркемнәре бик үк күпсанлы булмаганнар дип уйларга кирәк». Тикшеренүче «Казанская история»гә таяна, анда Олуг Мөхәммәднең Казанга килүе турында болай диелгән: «И ради ему бысть изо оставшихся от плена худыя болгары. И молиша его казанцы быти ему заступника бедам их, и помощника от насилия, воевания рускаго, и быти царьству строителя, да не до конца запустеют, и повинишася ему». Бу очракта, Д.М.Исхаков фикеренчә, «худыя болгары» төшенчәсе сәяси һәм иҗтимагый мәгънә белән беррәттән демографик мәгънәгә дә ия һәм «көчсез», «аз санлы» дигәнне аңлата. Әмма галим бу чор болгар халкын сан ягыннан бәяләүне читләтеп үтә. Ләкин Д.М.Исхаковның XVI гасырның беренче яртысында җирле төп халык санын 180–240 мең кеше дип исәпләвен (аның фикеренчә, региондагы демографик ситуациягә җитди тәэсир итмәгән Олуг Мөхәммәд урдасы көчләрен авторның реаль күзаллавы тексттан күренә) исәпкә алганда, XV гасыр уртасында бу халык саны 100 меңнән дә ким булмаган дигән нәтиҗә чыгарырга була. Ә «Казанский летописец» хәбәренә тәнкыйть күзлегеннән карасак һәм Казан дәүләтенең үз составына җирле халык рәтләренә Идел буе Болгары һәм Алтын Урда үсеше чорларында килеп кергән хазар, бәҗәнәк, кыпчак, угыз, татар һәм башка төрки этник компонент һәм элементларны алган болгар халкын гына түгел, шулай ук казанлыларга үз ирке белән буйсынучы башка кабилә һәм халыкларны да алуын истә тотсак, бу сан иң кимендә ике тапкырга арта.

Казан диварлары янына килгән Олуг Мөхәммәд Урдасының якынча саны язма чыганаклар буенча билгеле. Мәсәлән, «Казанская история» урдадагы 3 мең татар турында хәбәр итә, ә Патриарх яки Никон елъязмасы «...худое оно малое безбожных воинество... Татар тогда было доброе мало» дигән мәгълүмат бирә. Болар барысы да Олуг Мөхәммәд Урдасын «иң кимендә 200 мең кеше» дип бәяләгән Равил Фәхретдинов белән килешмәскә нигез бирә. Өстәвенә бу очракта рус елъязмаларына ышанырга була, күп тапкырлар (Белев, Түбән Новгород, Мәскәү, Евфим монастыре янында) рус гаскәрләрен тар-мар иткән дошманның көчен кечерәйтүдән аларга ни файда? Ә сугыш югалтуларын («...преднии полци великого князя биша Татар под Муромом и в Гороховцеи во инех местех...») һәм татарларның бер өлешенең соңрак оештырылган Касыйм ханлыгы территориясенә китүен исәпкә алсак, 1445 елда урданың (Олуг Мөхәммәднең үз Урдасы, Урдага инде Урта Идел буе территориясенә кергәч тупланган сугышчыларны санамыйча) бик аз санлы булуы көн кебек ачык булып кала. Бу очракта без Алтын Урда тарихында аналоглары күп булган мөлкәтсез Чыңгызидның бер төркем иярченнәре белән «кояш астында үзенә урын эзләү» очрагына юлыгабыз...

Шулай итеп, Урта Идел буена аз санлы Олуг Мөхәммәд Урдасы килүе турында нәтиҗә чыгарырга була. Берничә буын дәвамында, күрәсең, көньяк дала вәкилләре җирле якын тугандаш этник мохиттә «эреп югалган». Шуңа охшаш хәлне без Дунай буе Болгар патшалыгы, Киев Русе, Англия һәм башка кайбер дәүләтләрнең оешу чорында күзәтә алабыз, ләкин бер аерма белән — анда абориген һәм килмешәк халыклар арасында тугандашлык бәйләнешләре булмый.

Ләкин сан критерийларыннан гына чыгып, XV гасыр уртасында Казан дәүләтендә барган этник процессларда татарларның ролен киметеп күрсәтергә ярамый. Татарларның бөтен Көнчыгыш Европа территориясендә сәяси хакимияткә ия булуларында чагылган үз-үзен тотышларының актив һәм

сыгылмалы булуына һәм килмешәкләр белән җирле халык арасында уңай комплементарность (аңсыз рәвештә бер-берсенә охшауны сизү) булуына бәйле (моны «Казанская история» авторы да билгеләп үтә). Олуг Мөхәммәд Урдасы татарларының пассионар басымы XV гасыр — XVI гасырның беренче яртысында болгар этносының сыйфат үзгәрешенә, трансформациясенә, татар этносы җирлегендә Казан татарлары субэтносы формалашуына китерә (яки татар суперэтносы составында Казан татарлары этносы). Моңа шулай ук «от Златыя Орды, от Асторохани, и от Азова, и от Крыма...» 15 тыныч халыкның күченүе һәм җирле идарә итүче аксөякләр даирәсенең даими рәвештә Кырым, Әстерхан, Себер, Зур һәм Кече Нугай Урдаларыннан чыгучылар белән тулылануы да шактый зур өлеш кертә.

Нинди мәгълүматлар безгә XV — XVI гасырның беренче яртысында болгар этносы трансформация кичергән дип расларга мөмкинлек бирә соң?

Белүебезчә, тотрыклы динамик система буларак этноска үсеш күчүчәнлеге һәм өзлексезлеге генә түгел, ә вакыт дәвамында үзгәрү дә хас, һәм бу хәлне гадәттә этник процесслар дип исемлиләр[16]. Этносның теге яки бу компонентында теләсә нинди үзгәреш аның эчендә барган процессны чагылдыра һәм этник процесс буларак классификацияләнә ала. Этник системаның система буларак тулаем алганда сакланып калуы, аның аерым компонентларының үзгәрү очрагы турында сүз алып барганда, мондый этник процесслар «этноэволюцион» дип атала (минемчә, Алтын Урда чоры Идел буе болгарларында этник үсешнең шушы төре күзәтелгән). Эзлеклелекне «өзү» белән бәйле этник процесслар исә «этнодискрет» яки «этнотрансформацион» процесслар дип аталалар[17]. Трансформацион этник процесслар эволюцион этник үзгәрешләрнең үзенчәлекле нәтиҗәсе булып торалар һәм яңа этник берләшмәләр тууына китерәләр.

Яңа этник берәмлек формалаштыручы трансформацион процессның булуын без еш кына этник үзатама алышынуында чагылыш тапкан халыкның этник үзаңы үзгәрүе призмасы аша билгели алабыз[18]. Әмма без җәмгыять үсешенең феодаль чорында этник үзаңның бик тотрыксыз һәм үзгәрүчән булуын да истә тотарга тиешбез. Бик еш ул этнополитик, этногеографик, этноконфессиональ, этносоциаль һәм чиста этник үзенчәлекләрне үз эченә ала, бу, әлбәттә, еш кына этносның үз-үзен атавында да чагыла.

Без чыганакларда Казан ханлыгының дәүләт нигезен тәшкил иткән этносның нинди атамаларын очратабыз соң? Алар дүртәү — болгарлар (болгар), татарлар (татар), мөселманнар (мөслим, мөселман), казанлылар (казанлы, Казан кешесе). Дәүләтнең төп халкы мохитендә атап үтелгән атамаларның үсешенә тәэсир иткән төп факторларны билгеләп карыйк.

«Болгарлар» атамасында этник, географик һәм сәяси факторларның тәэсире шиксез, иҗтимагый һәм дини факторлар булуы ихтимал. Этник фактор — Казан ханлыгының төп халкы үзен иң элек Кара диңгез буе Бөек Болгар дәүләте һәм Хәзәр каганаты, соңрак Идел-Кама буе Болгар дәүләтләренең нигезен тәшкил иткән халык токымы дип санавыннан формалашкан. Географик фактор буларак Урта Идел буеның X гасырдан да калмыйча «Болгар иле» дип исемләнүен һәм бу атаманың XVIII–XIX гасырларга кадәр саклануын исәпкә алып формалашкан. Беренчел этник «болгар» атамасы политоним сыйфатын Бөек Болгар дәүләте, Идел буе Болгары, Алтын Урда (бер өлешен «болгар олысы» тәшкил иткән), Казан ханлыгы (чыганакларда ул еш кына «Болгар иле», «Болгар вилаяте» дип тә исемләнә, дәүләтнең башкаласы Казан башта — XV гасыр тәңкәләрендә — Болгар дип атала) чорларында үзләштерә. Казан ханлыгы чорында «болгар» атамасына «татарлар»га буйсынучы ясаклы халык дигәнгә ишарәләүче билгеле бер иҗтимагый мәгънә дә беркетелгән булуы мөмкин. Бу атаманың дини төсмере исә болгарларның ислам динен татарлар яки кыпчаклар белән чагыштырганда күпкә иртәрәк кабул итүләре һәм Урта Идел буе халкы хәтерендә соңгылары «мәҗүси»ләр яки «кяфер»ләр белән тиңләштерелүе нәтиҗәсендә формалашкан. (Минемчә, Урта Идел буе төрки халкының күпчелек өлеше тарафыннан «татар» атамасының XX гасыр башына кадәр танылмавы нәкъ менә шуның белән аңлатыла.)

«Татарлар» атамасының этник, сәяси һәм иҗтимагый эчтәлекләргә ия булуы шиксез. Казан ханлыгы халкының бер өлеше, һичшиксез, үзенең чыгышын Алтын Урда яки хәтта Үзәк Азия татарларына бәйләгән. Аларның этник атамасы инде VI гасыр уртасында ук, Төрки каганат оешу чорында, политоним сыйфатын ала, ә соңрак «татар» атамасы эчтәлеге Уйгыр, Сир («Түрк сир бодун»), Кимак, Кыргыз һәм башка каганатлар чорларында үсешен дәвам итә. Алтын Урда (чыганакларда «Җүчи олысы», «Татария», «Дәште Кыпчак» дип исемләнә) һәм аннан соңгы татар ханлыклары, аерым алганда Казан ханлыгы чорында «татар»лар политонимы Төньяк Азия һәм Көнчыгыш Европаның киң даирә халкының аңында ныгый. Беренчел этник «татар» атамасы Алтын Урда, Казан, Кырым, Касыйм, Әстерхан, Себер ханлыклары, Зур һәм Кече Нугай Урдалары чорында соционим төсмерен ала. Бу дәүләтләр үсешенең нәкъ менә шушы чорларында дәүләтләр белән идарә итүне үз кулларында тоткан «татар»лар йөзендә этнократия формалаша.

«Мөселманнар» атамасында дини фактор ачык чагыла. Ягъни «мөселманнар» үзатамасы — беренче чиратта конфессионим, вакыт дәвамында ул беркадәр этник билгегә трансформацияләнгән.

«Казанлылар» атамасы исә сәяси эчтәлекне ачык чагылдыра[19]. Бу эчтәлек, ихтимал, әле Идел буе Болгары чорында ук формалашкандыр, ә аннары Алтын Урда һәм Казан дәүләте чорында үсеш алган[20].

Алда санап үтелгән Казан ханлыгының дәүләт нигезен тәшкил итүче халык үзатамаларның кайсысы өстенлек иткән соң? Чыганаклардан күренгәнчә, бу «казанлылар» атамасы булган. Мәсәлән, «Казанская история» авторы (ул, Казан ханлыгында 20 ел яшәдем, дип белдерә) җирле төп халыкка карата бу этнонимны 300 тапкырдан артык куллана (мәсәлән, «убитых же казанцев на том бою 42000», «с русью бьяхуся казанцы», «народ казанский», «царь с казанцы своими», «казанские люди» һ.б.), ә «татарлар» һәм «болгарлар» этнонимнарын бик сирәк куллана. Бүтән рус чыганаклары шулай ук «казанлылар» этнонимына өстенлек бирәләр (мәсәлән, Никон елъязмасын[21], илчелек китапларын һ.б. кара). Казан ханлыгының дәүләт нигезен тәшкил итүче халык арасында бу этнонимның өстенлек итүе турында безгә күпсанлы шәрекъ чыганаклары белән (шул исәптән безнең көннәргә кадәр сакланмаганнары белән дә) таныш булган XX гасыр башы татар тарихчылары да хәбәр итә, аерым алганда Гайнетдин Әхмәрев, Габделбари Баттал һәм Газиз Гобәйдуллин. Хәзерге тикшеренүчеләрдән Сәлам Алишев, Мирфатыйх Зәкиев, Фаяз Хуҗин һ.б. бу турыда яза.

Казан ханлыгы чорындагы җирле төп халык арасында «казанлылар» атамасы җиңүенең сере нәрсәдә соң? Җавап, күрәсең, бу атаманың универсальлегендә, аның «болгарлар» һәм «татарлар» этнополитонимнарына карата «нейтраль» булуында яшеренгәндер. Бу процесска, минемчә, этник мөнәсәбәттә катнаш никахлар бик көчле тәэсир иткән, алардан туган буын баштан ук «кризислы», икегә аерылган була, һәм бу халәт «болгарлар» яки «татарлар» этнонимнарының икесенең берсенә яки башка ниндидер этнонимга өстенлек бирү мөмкинлеген юк итә.

Шулай итеп, башта сәяси эчтәлеккә ия булган һәм Алтын Урданың Болгар олысы Казан «бәклеге»ндә яшәүчеләрне аңлаткан «казанлылар» термины Казан ханлыгы чорында төп халыкның конкрет этнонимына әверелә (борынгы кытайларда «человек Срединного государства», Рим империясе гражданнарында «римляне», XV–XVI гасырда русларда «московиты» атамаларын куллану кебек) һәм әкренләп әйләнештән төшеп баручы «болгарлар» этнонимын алыштыра.

Алда әйтелгәннәр, минемчә, XV гасыр — XVI гасырның беренче яртысында болгар этносының этнотрансформация кичерүенең мөһим дәлиле булып тора, бу хәл татар этносы җирлегендә Казан татарлары субэтносы формалашуына китерә.

XV гасыр уртасында Казан дәүләтенең иҗтимагый-сәяси тормышында нинди үзгәрешләр күзәтелә соң? Урда ханының инде оешкан һәм тормышның күп өлкәләрендә җирле традицияләр үсешен дәвам иткән феодаль дәүләт белән җитәкчелек итә башлавын билгеләп үтәргә кирәк. Әмма бу дәүләтнең сәяси статусы үзгәрә — аның белән Чыңгыз хан токымыннан булган хан идарә итә башлый, ә бу хәл дәүләтнең абруен шактый күтәрә һәм күршеләренең, аерым алганда Сарай хакимнәренең һәм рус князьләренең аңа карата мөнәсәбәтен үзгәртә. Казан дәүләте территориясенең монгол явына кадәрге Идел буе Болгары чикләренә киңәюе, Мәхмүд хан идарә иткән чорда чыганакларда Казанга каршы Урда Сарае һәм рус феодаллары оештырган яу-һөҗүмнәр турында бернинди дә мәгълүмат булмавы моны ачык дәлилли. Шиһабетдин Мәрҗани бик дөрес билгеләгәнчә, «бу чорда Казан дәүләте көч-куәт туплый».

Дәүләтне оештыру рәвешендә 1445 елдан соң аерым үзенчәлекләр барлыкка килә. Казан дәүләтендә хакимиятне үз кулларына төшергәч, Урда феодаллары җирле халык өстеннән үз хакимлекләрен ныгыту өчен регионның сәяси тормышында гына түгел, ә хуҗалык һәм икътисад өлкәләрендә дә әйдәп баручы рольне уйнарга омтылырга тиеш булалар. Мәхмүд тарафыннан «князь Либей»нең үтерелүе бу сәясәтнең җирле феодаль кланнарга[22] каршы юнәлтелүен һәм дәүләттә өстенлек итәргә омтылуны раслый, моңа җирле феодаллардан җитештерүнең төп чарасы булган җир биләмәләрен тартып алу аша ирешкәннәр. Казан ханлыгында нигездә Олуг Мөхәммәд Урдасы вәкилләреннән формалашкан җир биләүчеләрнең яңа катламы барлыкка килә. Казан ханлыгында Ширин, Барын, Аргын, Кыпчак, Мангыт һ.б. урда кланнарының активлашуы моны раслый. Алар, күрәсең, дәүләтнең төрле өлкәләре белән идарә иткәннәр. Бу клан башлыклары ханның якыннары булганнар. XVI гасыр башында ике тапкыр Мәскәү князьлегендә булып киткән Сигизмунд Герберштейн болай яза: «У татарских царей есть четыре советника, к которым в важных делах они прибегают прежде всего. Первый из них называется Ширни, второй — Барни, третий — Гаргни, четвертый — Ципцан».

Аерым кешеләрнең, төркемнәрнең һәм сыйныфларның җәмгыятьтәге урыны җиргә булган мөнәсәбәтләреннән чыгып билгеләнгән. 1445 елдан алып Казан дәүләтенең феодаль иерархия баскычы түбәндәгечә булган. Илдә югары хакимият хан кулында була, һәм дәүләтнең барлык җирләре хан милке булып санала, крестьяннар алардан община нигезләрендә даими түләү шарты белән кулланганнар. Түләү феодал-тарханнар яки хан администрациясе вәкилләре аша төрле салым һәм ясаклар формасында башкарылган.

Казан ханлыгы тарихының күпчелек вакыйгалары монда идарә иткән ханнар белән тыгыз бәйле булганлыктан, хакимлек итү елларын күрсәтеп, мин аларның исемлеген бирүне кирәк таптым:

(? — 1438 — 1445 еллар — Олуг Мөхәммәд)[23];

1445 — 1467 еллар — Мәхмүд;

1467 ел — Хәлил;

1467 — 1479 еллар — Ибраһим;

1479 — 1484 еллар — Гали (Илһам);

1484 — 1485 еллар — Мөхәммәд Әмин;

1485 ел — Галинең икенче тапкыр хакимлек итүе;

1486 ел — Мөхәммәд Әминнең икенче тапкыр хакимлек итүе;

1486 — 1487 еллар — өченче тапкыр Гали хан;

1487 — 1496 еллар — өченче тапкыр Мөхәммәд Әмин;

1496 ел — Мамук;

1497 — 1502 еллар — Габделлатыйф;

1502 — 1519 еллар — дүртенче тапкыр Мөхәммәд Әмин;

1519 — 1521 еллар — Шаһ Гали;

1521 — 1524 еллар — Сәхиб Гәрәй;

1524 — 1532 еллар — Сафа Гәрәй;

1532 — 1536 еллар — Җангали;

1536 — 1546 еллар — икенче тапкыр Сафа Гәрәй;

1546 ел — икенче тапкыр Шаһ Гали;

1546 — 1549 еллар — өченче тапкыр Сафа Гәрәй;

1549 — 1551 еллар — Үтәмеш Гәрәй (анасы Сөембикә — регентша);

1551 — 1552 еллар — өченче тапкыр Шаһ Гали;

1552 ел — Ядегәр Мөхәммәд.

1445 елдан алып 1552 елга кадәр Казанда идарә иткән ханнар исемлеген игътибар белән караганда, тәхеттә хакимнәрнең бик еш алышынуы гаҗәпләндерә — 106 ел дәвамында 13 хан алышынган, өстәвенә аларның кайберләре 3 — 4 тапкыр идарә иткән. Бу, М.Г.Худяков фикеренчә, «дәүләт эчендәге сәяси бүленеш» белән аңлатыла, «ул югары хакимият өчен даими көрәш тудыра һәм теге яки бу хакимнең патшалык итүен ясалма рәвештә өзә». Дәүләттә хан хакимияте җирле кланнар һәм партия агымнарына буйсына башлый, һәм бу хәл, М.Г.Худяков фикеренчә, «Казан ханнарының дәүләт идарәсендә уйнаган төссез рольләренә бик туры килә, алар күпчелек очракта төрле партияләр кулында уенчык кына булганнар». Дәүләт күләмендәге әһәмиятле карарларны хан бары тик диван әгъзалары — хан каршындагы киңәшмә ризалыгы белән генә кабул итә алган. Диван эре феодаллар һәм руханиларның югары катламыннан торган. Бу киңәшмәнең дөньяви әгъзалары «карачы» — караучы атамасын йөрткәннәр. Алар арасында «олы карачы бәк» — баш караучы аерылып торган. Бу дәрәҗәгә башлыча Ширин татар нәселе вәкилләре ия булган, күрәсең, чөнки рус елъязмаларында әмир Булат Ширин —«карача Казанский большой», ә аның улы Нургали «большой карача Казанский» дип исемләнгән. «Олы карачы бәк» дәрәҗәсенең Ширин нәселендә атадан улга күчүенә игътибар иткәндә, ул буыннан буынга күчүче түрәлек дәрәҗәсе булган. Аерым дәүләт вазифаларын асыл татар нәселләре белән берләштерү Казан ханлыгы дәүләт төзелешенә хас үзенчәлек булып тора.

Мөһим дәүләт мәсьәләләрен чишү өчен (ханнар сайлау яки тәхеттән төшерү, солых яки сугыш игълан итү, халыкара шартнамәләр төзү һ.б.) «корылтай» дип исемләнгән җир биләүчеләр, хәрбиләр һәм руханилар съезды («вся земля Казанская») җыелган. Халыкның башка катламнары корылтайда катнашмаган, шуңа күрә аны халык җыелышы дип атап булмый. М.Г.Худяков санаганча, рус чыганакларында Казан ханлыгында корылтай җыелуның 14 очрагы теркәлгән. Ул 1496 елда Мамук ханны төшергәндә чакырылган, 1516 елда, 1518 елда, 1519 елда — Шаһ Гали ханны тәхеткә сайлаганда, 1524 елда — Мәскәү белән солых игълан итү өчен, 1530 елда, 1532 елда — Сафа Гәрәйне тәхеттән төшергәндә, 1536 елда — Сафа Гәрәйне тәхеткә утыртканда, 1542, 1546, 1551 елларда. Корылтайның башка елларда да чакырылган булуы бик мөмкин. Күпчелек тикшеренүчеләр фикеренчә, Казан ханлыгында корылтай җыю Көнчыгыш Европага монголлар алып килгән традиция чагылышы булып торган.

Дәүләттә хан, югары катлам руханилар һәм әмир-карачылар тәшкил иткән югары феодаль катламнан соң бәкләр, морзалар, угланнар, казаклар һәм буйсынучы халыкларның феодальләшүче югары катламнары торган. Күрүебезчә, Казан ханлыгында титуллы аксөякләр составы шактый төрле булган. Монда болгар феодаллары һәм Алтын Урда аксөякләре токымы да, Кырым феодал кланнары вәкилләре дә (шулай ук Алтын Урда аксөякләре нәселе) була, аларның саны XVI гасырның беренче өчтән бер өлешендә шактый

арта. Казан аксөякләре составы даими тулыланып торган, алар арасына Нугай Урдасыннан, Касыйм, Себер ханлыкларыннан бәк һәм морзалар өстәлеп торган.

Әмирләр, бәкләр һәм морзалар илдәге эре җир биләүчеләрнең төп контингентын тәшкил иткәннәр. Бу феодалларның күпчелегенә хан тарафыннан хәрби яки башка хезмәтләре өчен аларга беркетелгән җирләрдән үз файдаларына ясак җыю хокукы бирелә, ягъни алар сөйургалга ия була. Соңгысының иясе, җирле крестьяннары белән бергә җир биләмәсен нәсел буенча алып, алардан элек ясак формасында хан казнасына киткән салымны җыйган. Шуның өчен сөйургал иясе ханга кирәк булганда үз алай-гаскәрен туплап хезмәткә килергә тиеш булган, бу турыда күп чыганаклар хәбәр итә. Казан ханнары Ибраһим һәм Сәхиб Гәрәй тарафыннан бирелгән сөйургал-тархан ярлыклары сакланган. Ярлыклар икесе дә хан исеме белән башлана һәм ярлык ияләренең нәсел вәкилләре ия булган өстенлекләрне раслый.

XV гасырдан башлап Казан дәүләтенә сөйургал яки тархан ияләренә караганда ваграк булган хезмәт кешеләре институты үтеп керә башлый. Феодалларның бу төркемен хезмәткә килүче угланнар һәм казаклар тәшкил иткән. Күрсәткән хезмәтләре өчен алар шулай ук аерым авыллардан ясак һәм башка түләүләр җыю хокукына ия булганнар. Кайбер авыл атамаларында мондый биләмәләр хуҗаларының исеменә бәйле истәлекләр сакланып калган — Кощак-Уланово, Большие Казаки һ.б.

Мөселман руханилары дәүләттә хөрмәтле урын биләгәннәр. Һәрвакыт сәетләр (Мөхәммәд пәйгамбәр нәселеннән булган дин әһелләре) арасыннан сайланган руханилар башлыгы ханнан кала илдә беренче кеше булган. Төрле ханнар алышыну чорында ул, үзенең өстенлекле хәленнән чыгып, гадәттә вакытлы хакимият башында торган. Еш кына илнең рухани башлыгы дипломатик бурычларны да үтәгән, бу хәл исә аның белемле һәм дөньяви эшләрдән дә хәбәрдар булуын таләп иткән.

Руханилар санына шулай ук шәехләр, муллалар, имамнар, дәрвишләр, хаҗилар, хафизлар, мөдәррисләр дә кергән. Алар Казан ханлыгы халкы арасында мәдәният, аң-белем тарату эшендә мөһим миссия башкаралар. Моңа дини уку йортларының киң челтәре һәм шулай ук Казанда үзәк мәчет каршында югары уку йорты булуы ярдәм итә.

Ислам дине өстенлек итсә дә, Казан ханлыгында дин иреге танылуын аеруча билгеләп үтү зарур. Күпмедер дәрәҗәдә бу хәл Хазар иле, Идел буе Болгары һәм Алтын Урдадан сакланып калган тәртип һәм гореф-гадәтләргә бәйле була. Казанның үзендә христианнар өчен гыйбадәтханә — әрмән чиркәве урнашкан була, ә илнең угро-фин халыкларының күпчелеге һәм төрки халыкның бер өлеше бабалардан калган мәҗүсилек йолаларын үтәүне дәвам иткәннәр. Ислам көчләмичә, ирекле рәвештә, күп очракта полиэтник дәүләт эчендә этнокультур интеграция алып барган этнокультур бәйләнешләр көчәюе нәтиҗәсе буларак таралган.

Казан ханлыгы төзелешендә төрле түрәләр шактый зур катлам тәшкил иткәннәр. Аларның кайбер дәрәҗә-вазифаларын Казан ханнары ярлыкларыннан укып, күреп була. Алар арасында казыйларны, тәртип сакчыларын, таможня хезмәтчеләрен, ясак һәм салым җыючыларны, тылмачларны һ.б. аерып атарга мөмкин. Казан тарихы буенча абруйлы тикшеренүче М.Г.Худяков фикеренчә, күпсанлы вазифалы кешеләр һәм түрәләр тарафыннан хезмәт күрсәтелүче катлаулы административ идарә итү системасы Казанга тулысынча Сарайдан, ягъни Алтын Урдадан «алып киленгән» була.

Феодаллар, руханилар һәм түрәләр халыкның өстенлекле, хакимлек итүче катламын тәшкил иткәннәр. Һәм аларны «кара халык»ка (ягъни күпчелеккә) капма-каршы куючы рәвешендә «аксөякләр» дип атаганнар. Юридик яктан ирекле саналган крестьяннар чынбарлыкта феодалларга буйсынганнар һәм гомуми саны егермегә якын төрдәге салымнар түләгәннәр[24]. Алар арасында ясак, калан, хәрәҗ, гошер, җан башыннан салым, төтен саны, баҗ, куниш салымы, ныгытмалар һәм күперләр салуда катнашу, хан хезмәтчеләрен ашату йөкләмәләрен атарга була. Дәүләтнең ясаклы халкының чагыштырмача азчылык өлешен шәһәрләрдә яшәгән һөнәрче һәм сәүдәгәрләр тәшкил иткән.

Ясаклы халыкның Казан ханнары алып барган эчке сәясәтенә риза булмавы еш кына дәүләттә иҗтимагый кризис тудырган. Алар бигрәк XV гасыр ахыры — XVI гасырның беренче яртысында — 1496, 1531, 1545–1546, 1549, 1551 елларда, күбесенчә Сафа Гәрәй хан[25] хакимлек иткән чорда булгалап торганнар. Мондый очракларны рус елъязмачылары: «Не хотят казанцы меншие болших слушати и покорится им», — дип билгеләп үтәләр. Ләкин Казан ханлыгында иҗтимагый кризислар беркайчан да этник проблемаларга әверелмәгән — моны бигрәк тә ассызыклыйсы килә[26]. Бу хәл шактый дәрәҗәдә Казан хакимияте тарафыннан дәүләт оешуның беренче көннәреннән үк алып барылган тигез милли сәясәт нәтиҗәсе була[27].

Кайбер нәтиҗәләр чыгарыйк:

1. Җирле халык белән чагыштырганда аз санлы Олуг Мөхәммәд Урдасының Урта Идел буена килүе җирле төп халыкның этник үсешенең трансформациясенә, сыйфат үзгәрешенә, Казан ханлыгы чорында татар этносы (суперэтносы) эчендә Казан татарлары субэтносы (этносы)[28] формалашуына китерә[29].

2. 1445 елдан соң Казан ханлыгы төзелешенең кайбер үзенә генә хас яклары барлыкка килә, алар Урта Идел буе халкының һәм Евразия далалары халкының дәүләт төзелеше традицияләренең синтезы булып тора.

Һәм хезмәтнең бу өлешендә әйтергә теләгән соңгы фикер. Үзара икътисади һәм мәдәни бәйләнгән һәм үзләрен, тугандаш яки тугандаш булмаган телләрдә сөйләшүләренә карамастан бер үк сәяси кербөтеннең өлешләре итеп сизгән халыкларның дәүләтләре эчендә кешелек җәмгыяте үсешенең төрле чорларында метаэтник этнополитик җәмгыятьләр оешкан[30]. Метаэтник берләшмәләр теге яки бу дәрәҗәдә полиэтник составлы бөтен дәүләтләрдә дә формалашкан, ләкин аларның барысын да этнополитик дип атап булмый. Соңгыларында бары тик төрле халыклар арасындагы мөнәсәбәтләрдә үзәккә омтылу юнәлешләре өстенлек иткән. Димәк, бөтен ил халкына әкренләп иҗтимагый-икътисади, мәдәни, ә күп очракта тел интеграциясе өчен дә шартлар булган очракта гына мондый хәл туган. Сыйнфый җәмгыятьләрдә барлык этносларның тулысынча тигез хокукларга ия булуы гомумән мөмкин булмаса да, шулай да кайбер дәүләтләрдә төрле тарихи чорлар дәвамында теге яки бу дәрәҗәдә дәвамлы һәм тотрыклы «этник тынычлык» барлыкка килгән, һәм этнополитик берлеккә тупланган халыкларның күбесе аны саклап калуда кызыксынган була. Бу тынычлык этник антогонизмнар һәм конфликтлар үсеше аркасында бозылса, берлек үзе дә таралу куркынычы астында калган. Шулай итеп, халыклары бары тик үзәктән идарә итү белән генә берләштерелгән, үзара көндәлектә иҗтимагый-икътисади һәм мәдәни йогынты ясамаган, басып алу нәтиҗәсендә туган империяләр өчен мондый берлекләр хас булмый. Барлык әйтелгәннәрне исәпкә алып, Казан ханлыгы чорында яңа этнополитик берлек[31] оешуы күзәтелүен билгеләп үтәргә кирәк — тотрыклы этник тынычлык, иҗтимагый-икътисади, мәдәни һәм тел интеграциясе булган халык үзенең сәяси бербөтенгә каравын аңлаган (моны XVI гасыр уртасында Урта Идел буе халыкларының бәйсезлек өчен бердәм көрәшүләре ачык дәлилли) һәм бу бербөтенне үзенең Ватаны дип таныган. Кызганыч ки, 1552 ел вакыйгалары регион тарихын кисәк үзгәртә.

Бу бүлектә әйтелгәннәрдән чыгып, түбәндәге нәтиҗәләргә киләбез:

1. Идел буе Болгарының XIII гасырның беренче яртысында формалашучы Алтын Урда дәүләтенә керүе, сәяси мөстәкыйльлегенең кайбер әһәмиятле элементларын югалтуы Идел-Урал тарихи-этнографик өлкәсе халкының этносоциаль үсешенә җитди тәэсир итә:

а) 1236–1237 еллардагы монгол яулары Идел буе Болгары халкының кисәк кимүенә китерә һәм Идел буе болгарлары яшәгән территориянең үзәктән читләшү процессын башлап җибәрә; Алтын Урда чорында болгарларның яшәү территориясенең күп үзәкле булуы этносның этнополитик менталитетында билгеле бер үзгәрешләргә китерә, бу хәл үз чиратында этносның үзатамасында чагыла;

б) Алтын Урда чорында болгар халкының иҗтимагый-сәяси тормышына яңа социаль мөнәсәбәтләр үтеп керә башлый, ләкин, гомумән алганда, монгол явына кадәрге чор традицияләре үсешен дәвам итә;

в) Алтын Урда чорында сизелерлек үзгәрешләр Болгар иле халкының матди һәм рухи мәдәнияте өлкәсендә барлыкка килә, бу XIII–XIV гасырларда Урта Идел буе территориясенә яңа этник элемент килеп керүенә һәм Идел-Урал регионы белән Кыпчак далалары арасындагы элек тә күбесенчә шартлы булган чикләрнең юкка чыгуына бәйле була; җирле халыкның этнокультур кыяфәтенең күпмедер үзгәрүе шактый дәрәҗәдә үз этнокультур, аерым алганда этноконфессиональ традицияләрен саклап калган Идел буе болгарларының этноэволюциясенә китерә.

2. XIII гасырның беренче яртысындагы монгол явы һәм басып алынган Болгар иленең ярым мөстәкыйль олыс хәлендә Алтын Урда дәүләтенә керүе белән бәйле тетрәүләргә карамастан, Идел буе болгарларының икътисады традицион үсешен дәвам итә һәм хәтта сизелерлек алга китә. Моңа җирле һәм Урда феодаллары алып барган сәясәт шактый ярдәм итә; нәтиҗә буларак Болгар иле Евразиянең алга киткән һәм икътисади яктан мөстәкыйль регионы буларак үзенең әйдәп баручы торышын саклап кала.

3. Хан хакимиятенең тышкы сәясәт, эчке дәүләт һәм табигать катаклизмнары тарафыннан какшатылуы XIV гасыр ахырында болгар феодалларының сепаратистик омтылышларын көчәйтә һәм XIV–XV гасырлар чигендә болгар өлкәләренең Алтын Урда дәүләтеннән бөтенләй аерылып чыгуына китерә; моңа шактый дәрәҗәдә регионның икътисади мөстәкыйльлеге һәм аның этник аерымланганлыгы да нигез була.

4. XIV–XV гасыр чикләрендә Казан дәүләте тәмам формалаша, аның хакиме үз тирәсенә болгар һәм Алтын Урда династияләре вәкилләрен берләштерүгә ирешә; бу дәүләт тормышның күп өлкәләрендә әле монгол явына кадәрге Идел буе Болгарында ук формалашкан җирле традицияләрне үстерүне дәвам итә.

5. 1445 елда Казан дәүләтендә турыдан-туры Алтын Урда династиясе (Чыңгыз хан һәм аның улы Җучи нәселе) хакимияте урнаштырыла, бу вакыйга региондагы этносоциаль хәлне җитди үзгәртә:

а) Казан ханлыгы чорында регионның Алтын Урда дәверендә этноэволюция кичергән төп төрки халкы, этник трансформация, сыйфат үзгәреше нәтиҗәсендә этник үсешенең яңа этабына аяк баса, бу хәл ахыр чиктә Казан татарлары этносы формалашуына китерә;

б) 1445 елдан соң дәүләт төзелешендә бу регионга гына хас үзенчәлекләр барлыкка килә, аларның тамырлары Көнчыгыш Азия дәүләт төзелеше һәм Алтын Урда чорына һәм аннан соңгы Евразия дәүләтләре традицияләренә барып тоташа;

в) Алтын Урда династиясе хакимияте урнаштырылганнан соң (җирле хакимият вәкилләре аңа турыдан-туры катнашмый), Казан дәүләтенең сәяси статусы үзгәрүе, гомумән алганда, аның үсешенә уңай тәэсир итә.

# КАЗАН ДӘҮЛӘТЕНЕҢ ПЕРИФЕРИЯДӘГЕ ТӨРКИ ХАЛКЫ

## 1. Дәүләттә чувашларның борынгы бабаларының этносоциаль үсеше

Казан дәүләтенең төрки халкы дәүләтнең нигезен тәшкил иткән Казан татарлары этносыннан тыш башкорт, нугай һәм чувашларның борынгы бабаларыннан торган.

Казан ханлыгы дәүләтендәге чувашларның борынгы бабаларының этносоциаль үсешен карап үтик.

Чуваш этносын белгечләр XVIII гасыр урталарыннан даими өйрәнә башлыйлар. Шундыйлардан И.Г.Гмелин (1751 ел басмасы), И.И.Лепехин, П.И.Рычков һәм кайбер башка галимнәрнең хезмәтләрен атарга мөмкин. Соңрак аларга К.Милькович, С.М.Михайлов, А.А.Фукс, В.А.Сбоев, В.И.Лебедев, Н.И.Золотницкий, А.И.Артемьев, В.К.Магницкий, А.В.Рекеев һ.б. хезмәтләре өстәлә. XX гасыр башы Н.И.Ашмарин, Зариф Бәшири, М.Мортазин, Н.В.Никольский, И.Н.Смирнов, Г.И.Комиссаров, Н.Р.Романов, Г.А.Никитин, В.Ф.Смолин һәм башка күп авторларның чуваш этносының тарихы һәм этнографиясе буенча төрле сорауларга кагылышлы хезмәтләре белән билгеләнә. XX гасырның икенче яртысыннан башлап чуваш этносын өйрәнүче галимнәр даирәсе шактый киңәя, махсус оешмалар барлыкка килә.

Чувашлар этногенезына карата галимнәрнең фикерләре төрле. Бу мәсьәлә бүгенгәчә кызу бәхәсләр тудыра. А.А.Фукс чувашларда хазарлар нәселен дәвам итүчеләрне күрә. В.А.Сбоев аларны бортаслардан чыккан дип уйлый. В.В.Бартольд аларны турыдан-туры һуннар токымына бәйле дип саный. В.Н.Татищев, Х.Фәезханов, Н.И.Ильминский һәм Н.И.Ашмарин тарафыннан чувашларның болгарлардан килеп чыгуы теориясенә нигез салына. Соңрак бу теория күп тарихи хезмәтләрдә яклау таба, аерым алганда В.Ф.Каховский хезмәтләрендә. Ләкин башка тикшеренүчеләр, аерым алганда А.Х.Халиков, Р.Г.Фәхретдинов, С.Х.Алишев, М.З.Зәкиев һәм Я.Ф.Кузьмин-Юманади тарафыннан үткәрелгән критик анализ бу теориянең бәхәсле булуын күрсәтте. Алар түбәндәге дәлилләргә нигезләнәләр:

1. Краниология мәгълүматлары буенча, болгарлар белән чувашларга караганда болгарлар һәм Казан татарлары арасындагы күчүчәнлек ачыграк күренә.
2. Болгар-чуваш теориясе этнографик мөнәсәбәттә дә расланмый. Болгарларның этнографик үзенчәлекләре, нигездә, Казан татарлары арасында сакланган.
3. Болгар-чуваш теориясе территориаль яктан да расланмый.
4. Чувашларның борынгы бабалары болгарларга якын булсалар, һичшиксез, алардан дәүләтчелекне дә мирас итеп алырлар иде. Чувашларның борынгы бабаларында дәүләтчелекнең булмавы ачык аңлашыла. Болгар дәүләте Казан дәүләтенә әверелә, ә Идел буе болгарлары дәүләтчелеген Казан татарлары кабул итә.
5. Лингвистик яктан да болгар-чуваш теориясе шактый каршылыклы.

Шулай итеп, хәзерге көндә чуваш этносының[32] килеп чыгышы турындагы мәсьәлә ачык булып кала бирә. Чувашларның көнкүрешен һәм антропологик материалны этнографик яктан анализлау чувашларны чиста төрки халкы дип санарга мөмкинлек бирми. Чуваш этносының башта Идел буе Болгары, соңрак Җүчи олысы һәм Казан ханлыгы бердәмлегенә кергән кайбер җирле угро-фин һәм төрки кабиләләрнең этник кушылулары нәтиҗәсендә формалашуы шиксез.

Чуваш этносы формалашкан территория тулысынча Казан ханлыгына караган. Ретроспектив анализ ысулы белән без чувашларның борынгы бабалары Казан ханлыгы чорында яшәгән табигый-географик шартларын торгыза алабыз. Бу бик мөһим, чөнки географик мохитнең этносоциаль система үсешенең даими һәм зарури шартларының берсе булып торуы бәхәссез, һәм ул, әлбәттә, бу үсешкә тәэсир итә.

Казан ханлыгы чорында формалашучы чуваш этносы таралган территория Идел буе калкулыгының төньяк өлешен биләп торган һәм, гомумән алганда, таулы-чокырлы тигезлек булган. Территориянең төньягында Идел үзәнлегендә һәм көнбатышта Сура үзәнлегендә түбән эрозия базисы булуы, шулай ук җирнең көпшәк һәм тиз уалучан токымнардан торуы бу тирәләрдә тирән үзәнле вак елгалар һәм ерым-сызалар челтәрен барлыкка китерә. Сыза һәм ерымтылар төньяктан көньякка таба бераз тигезләнүче таулы-чокырлы рельеф тудыра. Формалашучы чуваш этносының яшәү территориясендә иң тигез рельеф көньяк-көнбатыш өлешендә була.

Гомумән алганда, чувашларның борынгы бабалары торган урыннар хуҗалык алып бару өчен уңайлы булса да, территориянең төньягының таулы-чокырлы, тигезсез рельефлы булуы игенчелек белән шөгыльләнүне шактый кыенлаштыра һәм терлекчелекнең табигый азык базасын кечерәйтә.

Казан ханлыгының чувашлар яшәгән көнбатыш территорияләре климаты, гомумән алганда, халыкка тормыш алып бару өчен уңай булган, күрәсең. Тик чувашларның борынгы бабалары яшәгән җирләрнең көньяк-көнчыгыш районнары гына сирәк булган җәйге корылыктан интеккәннәр.

Казан ханлыгы чорында урманнар Чувашия территориясенең 70 процентына кадәр тәшкил иткәннәр, күрәсең. Вак күлләр күп булган. Мүкле сазлыклар зур территорияләрне биләгән. Болыннар бөтен территориянең якынча 5 процентын гына тәшкил иткәннәр һәм күбесенчә Сура һәм Зур Цивиль елгасы үзәннәрендә, өлешчә Идел буенда урнашканнар. Чувашиянең күптөрле җәнлекләр һәм кошлар белән чагылдырылган хайваннар дөньясы гаять бай булган.

Казан ханлыгы чорында чуваш этносы формалашкан табигать шартлары шундый булып күзаллана.

XV гасырга таба чувашларның борынгы бабалары торган территория тулысынча Казан ханлыгы биләмәсенә керә. Аларның төп тору урыннары Тау ягының төньяк өлеше була, аны төньяктан — Идел, көнчыгыштан — Зөя һәм көнбатыштан Сура елгалары чикли. Чыганаклар Сура елгасы Казан биләмәләрен рус җирләреннән аерып тора дип билгелиләр.

XV–XVI гасырлар дәвамында формалашучы чуваш этносының төп өлеше хәзерге Чуваш Республикасы территориясенең төньяк өлешендә яшәгән. Халыкның абсолют тыгызлыгы монда бик зур булмый. Ләкин барыбер чуваш халкы бу регионда көньяк районнары белән чагыштырганда күбрәк була. Казан ханлыгы чорында яшәгән чуваш халкының саны якынча 50–80 мең кеше тәшкил иткән[33].

Чувашлар[34] тоташ урманнар арасында, еш кына бер-берсеннән шактый еракта яшәгәннәр[35]. Аларның торак урыннары аулак урыннарда, ерымнарда, юллар һәм зур елга ярларыннан читтә урнашкан була. XVI гасырда А.М.Курбский чуваш авылларының аз санлылыгын билгеләп үтә: «От тое реки (Суры) шли... с войском 8 дней полями дикими и дубравами, негде же и лесами; а сел со живущими зело мало, понеже у них села при великих крепостях (т.е. в укромных местах) ставлены и незримы, аще и поблизку ходящим».

Хәзерге Чуваш иленең көньягына халык соңрак күчеп утырган, һәм монда торак урыннары елгаларга мөмкин булганча якынрак урнашканнар.

Кайбер галимнәр фикеренчә, формалашучы чуваш этносына XIII гасырдан алып XVI гасырга кадәр кыпчак этносы җитди тәэсир иткән, һәм, имештер, кыпчаклар болгар-татарлар белән чагыштырганда чувашлар арасында күпкә артыграк төпләнеп калганнар. Алар фикеренчә, кыпчак теленең өстенлек итүче тәэсире астында чувашларның борынгы бабаларының теленнән иске чуваш теле тулысынча формалаша.

Үзләренең формалашу чорында чувашлар шулай ук көнчыгыштан, Свияга (Зөя) бассейнында формалашып килүче Казан татарлары[36] этносының, ә көнбатыштан әле XIV гасырда ук Сура елгасының уң ярын басып алган һәм монда 1372 елда — Курмыш шәһәренә, ә соңрак, XVI гасырда, Алатырь шәһәренә нигез салган русларның этнокультур тәэсирен кичерә. Төньяк-көнбатыш чувашларга — марилар, ә түбән буй чувашларына мордвалар билгеле дәрәҗәдә этнокультур тәэсир ясыйлар. В.Ф.Каховский яза: «...Европеоид һәм монголоид халкының кушылуы нәтиҗәсендә формалашкан хәзерге чуваш халкының физик типлары чуваш халкының формалашуында төрле этник төркемнәр катнашуын раслый».

Хәзерге Чуваш Республикасының төньяк өлеше халкының борынгы чорлардан ук аның көньяк-көнчыгыш өлеше халкыннан шактый аерылып торганлыгы археологлар тарафыннан билгеләнә. Бу мөһим шарт, әлбәттә, формалашучы чуваш этносында этнографик төркемнәр барлыкка килүенә тәэсир итә.

Этнографик мөнәсәбәттә Казан ханлыгы чоры чувашлары ике төп диалекталь төркемгә бүленгәннәр: югары һәм түбән. Югары (төньяк) чувашлар — вирьяллар — хәзерге Чуваш иленең көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш районнарындагы җирле төрки, борынгы мари һәм борынгы мордва кабиләләренең этник катнашу һәм интеграция процессында формалашканнар. Түбән (көньяк) чувашлар — анатри — XIII гасырда бу төбәккә суварлар күченүе һәм аларның җирле, нигездә угро-фин кабиләләре белән катнашуы нәтиҗәсендә формалашканнар.

Казан ханлыгы чорында вирьяллар, күрше халыклар, аерым алганда тау мариларының[37] көчле тәэсире астында булсалар да, җитди этник үзгәрешләр кичермиләр. Түбән чувашлар исә Казан ханлыгы чорында ике төркемчәгә бүленәләр, алар бер-берсеннән тел һәм башка үзенчәлекләр белән аерылалар: уртача түбән яки түбән яклылар (анат енчи) һәм чын түбән чувашлар (анатри). Көнчыгыш күршеләр Казан татарлары белән иң зур этнокультур бәйләнештә соңгылары була. Ә анат енчига марилар да, казанлылар да сизелерлек йогынты ясамый. XVI гасыр уртасыннан рус этносы басымы астында чувашларның көньяк дала районнарына күченү процессында Урюм елгасыннан көньяк тарафта түбән чувашларның яңа төркемчәсе барлыкка килә — хирти (дала яклар).

XVI гасыр башына кадәр чувашларның борынгы бабалары чыганакларда регионның күп халыкларын (беренче чиратта мариларны, шулай ук чувашларны да, сирәк очракларда удмуртларны) билгеләүче гомуми җыелма атама белән — чирмешләр дип исемләнә[38]. Еш кына XVI гасырга кадәр чувашларның борынгы бабаларын бортаслар һәм мордвалар дип тә атаганнар. Үз этнонимнары белән чувашлар беренче

тапкыр 1505 елда искә алыналар[39]. Шушы вакыттан башлап чувашлар чыганакларда күбесенчә үз атамалары белән искә алыналар. Чувашлар яшәгән төбәкне Казан дәүләтендәге үзенә бер өлкә буларак беренче тапкыр искә алу шулай ук XVI гасырның беренче чирегенә карый. Казан ханына буйсынучы халыклар турында тулы мәгълүматларга ия булган Герберштейн язмасында без «Schvuuaij» атамасын очратабыз.

Чыганакларда «чуваш» этнонимының һәм аерым өлкә буларак «Чувашия» атамасының бер үк вакытта барлыкка килүен очраклы хәл дип санарга ярамый — бу хәл чувашларның Урта Идел буенда зур халыкларның берсе буларак әһәмиятләре артуына бәйле. Моның белән Казан ханнары да, Мәскәү князьләре дә санашырга тиеш була. Бу, һичшиксез, чувашларның XVI гасырның беренче яртысында үзләренең этногенезының соңгы фазасына керүләренә дә бәйле була, этносның этнонимы формалашып җитүе шуның төп билгеләренең берсе булып тора.

Бер төркем тикшеренүчеләр фикеренчә, «хәзерге Чувашиянең төньяк районнары территориясендә, фин-угор халкы белән ассимиляция нәтиҗәсендә чуваш халкының әле X гасырда ук Болгар дәүләте җирлегендә башланган формалашу процессы XV гасырда тәмамланган». Алар фикеренчә, «чувашлар телләре һәм көнкүреше буенча күрше угро-финнарга якын җирле кабиләләр һәм төрки телле кабилә яки халыкларның катлаулы якынаюы нәтиҗәсендә формалашканнар... Чувашларның фин телле һәм төрки телле борынгы бабаларының катнашып китү вакыты турында бәхәсләшергә мөмкин булса да, чувашларның каяндыр башка яктан инде формалашкан рәвештә килүләре турында сүз йөртеп булмый, аларны ниндидер борынгы халыкларга тәңгәлләштерергә ярамый (борынгы болгарлар турында сүз барса да). Соңгылары, һичшиксез, чуваш халкының формалашуында әһәмиятле роль уйнаганнар, ләкин, әлбәттә, аларның бердәнбер борынгы бабалары булмаганнар».

Башка галимнәр XIV–XVI гасырларда вирьял һәм анатриның бер-берсенә әкренләп якынлашу һәм берләшү процессы барышында чуваш халкының формалашу процессы гомумән алганда тәмамланган дип билгелиләр, моны рус елъязмаларында «чувашлар» этнонимының таралуы раслый.

Казан тарихчылары, аерым алганда т.ф.д. С.Х.Алишев фикеренчә исә, «Патриархаль-ыру һәм патриархаль-феодаль мөнәсәбәтләр әле XV гасыр — XVI гасырның беренче яртысында чуваш халкының тулаем формалашуы өчен шартлар тудыра алмаганнар. XV–XVI гасыр чувашларына зур булмаган һәм аерымланмаган территориядәге этник төркемнәр арасында аермалар, формалашып җитмәгән сыйныфлар, түбән дәрәҗәдә иҗтимагый үсеш хас булган». Минемчә, бу фикер дөреслеккә иң якын килгәне.

Чувашлар яшәгән төбәк икътисады Болгар дәүләте чорларыннан сизелерлек үзгәрешләр кичерми. А.М.Курбский Казан ханлыгында, шул исәптән чувашлар хуҗалыгында да игенчелекнең өстенлекле булуын билгеләп үтә. «Казанский летописец» чувашларны «землепашцы и трудницы» дип юкка гына атамый. Чувашлар туйдыручы җирне ана дип санаганнар. Чувашиядә игенчелек үсешенә мондагы табигать һәм һава торышы, шулай ук зур торак урыннар һәм шәһәрләр булмавы да ярдәм итә.

XV–XVI гасырларда чувашлар яшәгән урыннарының төньягында һәм аннан көнчыгышка таба, Зөянең түбән агымына кадәр шактый зур кырларны урманнан арындыралар һәм шунда игенчелек белән шөгыльләнәләр. Чувашлар таралган территориянең көньяк җирләре азрак кулланылган, монда торак урыннар булмаган диярлек. Чуваш крестьяннары бу җирләрне килеп-китеп эшкәрткәннәр, һәм хәтта XVI гасыр уртасында да әле көньяк-көнчыгыш Чувашиядә игенчелек өчен яраклы булган шактый кырлар буш торган. Бер чыганакта чувашларның күрше мордвалар һәм татарлар янында «буйлап» җир сукалаулары турында искә алыну кызыклы[40]. Ә Сура янындагы җирләр чувашлар тарафыннан иң аз файдаланыла; алар көнбатышка таба бик әкрен хәрәкәт итәләр.

Җирле халыкта Идел буе Болгар дәүләте карамагында булган чорда формалашкан игенчелек техникасы йөз еллар дәвамында, шул исәптән Казан ханлыгы чорында да сизелерлек үзгәрешләрсез кала. Ике яки өч басулы чәчү әйләнеше булган пар системасы өстенлек иткән, урманлы районнарда подсечная һәм переложная системалар да сакланган. Чувашлар төрле бөртекле һәм техник культуралар үстергәннәр. Бәлки инде, ул вакытта ук аларда колмак үстерү культуралашкан булгандыр. Игенчелек эшләрен чувашлар, борынгы бабаларының гореф-гадәтләрен төгәл саклап, дини ритуаллар һәм догалар, корбан китерүләр һәм башка йолалар белән кушып алып башкарганнар.

Яшелчә үстерү чувашлар хуҗалыгының әһәмиятле тармагы була. Яшелчәләр бары тик гаилә ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә генә хезмәт иткән, сатуга чыгарылмаган. Чувашларда бакчачылык таралмаган була.

Чувашларда терлекчелек ярым күчмә билгеләрдән арына, аның җитештерүчәнлеге түбән була, чөнки хайваннарны йорт хуҗалыгы эчендә генә үрчетәләр. Бәлки, күчмә терлек көтүләре дә булгандыр, ләкин мондый ысул бары тик иң көньяк районнарда гына кулланылган. Остеологик материал анализы

нәтиҗәсендә табылган мәгълүматлар кызыклы — Казан ханлыгы чоры чувашларында мөгезле эре терлек үрчетү беренче урында торган, икенче урында — дуңгыз һәм вак терлек, атлар бик аз санлы булган.

Чувашларда кошчылык та үсеш алган була. Күбесенчә таза тормышлы, бай крестьяннар су кошларын — үрдәк һәм казлар үрчеткәннәр.

Казан ханлыгы чорындагы Чувашия халкының шөгыльләре арасында ярдәмчел хуҗалык формалары — чолык умартачылыгы һәм балыкчылык та мөһим роль уйнаган. Бу як җәнлекләр, урман һәм су кошларына бай булганга, чувашлар ау белән дә шөгыльләнгәннәр. Кыйммәтле мехлы җәнлекләргә аучылык белән шөгыльләнүче мөһим районнарының берсе буларак, Чуваш иле мех байлыклары, бигрәк тә тиен тиреләре белән Пермь һәм Вятка кебек үк данлыклы була. Чуваш крестьяннары феодалларга төрле ясакларны мех һәм тиреләр белән түләгәннәр.

Казан ханлыгы чорында чувашларда һөнәрчелек алга китмәгән. Чувашлар арасында һөнәрче-осталар бик аз була. Нигездә, һөнәрчелек белән үз ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм башка әйберләргә алыштыру өчен бүтән эшләрдән буш вакытларда крестьяннар шөгыльләнгән. Эш кораллары, транспорт чаралары, кием, аяк киеме һәр гаиләдә диярлек үз куллары белән җитештерелгән. Кайбер һөнәрләр генә осталар кулында булган.

Һөнәрнең йорт характерында булуы һәм аның чуваш авылларында тупланы Чувашиядә Казан ханлыгы чорында шәһәрләр булмавы белән аңлатыла[41]. Күпмедер дәрәҗәдә һөнәрчелек үзәге булган урта гасыр чуваш шәһәре дип Чабаксарны[42] гына атарга мөмкин, аны да тартып-сузып кына, чөнки бу торак урынында табылган әйберләр комплексы характеристикасы шактый бәхәсле. Казынулар вакытында өйрәнелгән Чабаксар районы XIII гасыр ахыры — XV гасыр башларында өлешчә һөнәрчелек характеры йөрткән. Чабаксар җирендә табылган кәкре чалгы, бөртек көрәге, көрәк сыман кораллар һ.б. урта гасыр Чабаксар халкының авыл хуҗалыгы белән тыгыз бәйләнгәнлеген ачык күрсәтәләр. XIV гасыр катламында җиде корылма табыла, шуларның дүртесе — һөнәр алачыклары (ике чүлмәк ясау һөнәрханәсе, йозакчы һәм ювелир остаханәсе, йозакчы һәм күн эшкәртүченең торагы һәм һөнәрханәсе). Алга таба, XV гасыр — XVI гасырның беренче яртысында, бу торак урынның иҗтимагый-икътисади халәте үзгәрми.

XV гасыр — XVI гасырның беренче яртысында чувашларда тимерчелек һөнәре үсеш ала. Чуваш тимерчеләре кайбер эш һәм сугыш коралларын, шулай ук кара металлардан көнкүреш әйберләрен ясаганнар.

Чувашларның керамика җитештерүе яхшы өйрәнелгән. Тикшеренүчеләр чувашларда XIII гасыр — XVI гасырның беренче яртысында керамика комплексының үзенчәлекле булуын билгеләп үтәләр: югары сыйфатлы шомартылган савыт-саба аз, Идел буе Болгары, Алтын Урда, шулай ук Казан ханлыгының башка регионнарындагы көнкүреш керамикасы белән тиңләшмәслек көрән керамика күп очрый.

Большетаябин шәһәрлеге һәм чувашларның башка торак урыннарында үткәрелгән казу эшләре нәтиҗәләреннән күренгәнчә, сөяктән әйберләр эшләү билгеле дәрәҗәдә үсеш алган.

Урта гасырларда чуваш халкы тормышында агач белән эшләү мөһим урын алып торган. Агач әйберләрнең күп өлеше өйдә ясалган һәм оста-һөнәрчеләр эшчәнлеге җимеше булмаган. Ләкин агач эшкәртүнең кайбер төрләре махсус һөнәр буларак аерылып чыккан, күрәсең. Мәсәлән, балта осталыгының ул вакыт өчен шактый югары дәрәҗәдә булуын күпсанлы агач корылма калдыклары раслый, Чабаксардагы агач корылмалар осталар тарафыннан салынган дип санарга мөмкинлек бирә.

Чувашларда шулай ук йозак, ювелир әйберләре, күн эшкәртү һәм күн итекләр тегү һөнәрләре дә үсеш алган була, моны Чабаксарда табылган кораллар, чимал, ярым фабрикатлар һәм җитештерү бинасы калдыклары раслый.

Шуның белән бергә белгечләр чувашларда ул тарихи чорда һөнәр үсеше һәм специальләшү дәрәҗәсенә артык югары бәя бирүдән кисәтәләр. Балчыктан ясалган савыт-саба сыйфатына карaганда, чувашларда керамика җитештерү башка халыклардагы чүлмәк ясау осталыгыннан калышкан. Аяк белән хәрәкәткә китерелүче чүлмәкче түгәрәге киң таралмаган. Күн эшкәртү башлыча итек тегү өчен генә кулланылган. Һөнәрнең сизелер-сизелмәс кенә специальләшүе турында итекченең күннән башка әйберләр дә эшләве, тегү өчен җепләрне үзләре җитештерүе, төрле слесарьлык һәм ювелир эшләренең бергә башкарылуы дәлилли.

Алда әйтелгәннәргә өстәп Борынгы Чувашия территориясендә гомуми Урта Идел буе регионы өчен әһәмияткә ия булырлык шәһәр үзәкләре булмавы, XVI гасырда әле чувашлар арасындагы шактый көчсез эчке икътисади бәйләнешләр яшәвен һәм җирле халыкларның күршеләре белән мөнәсәбәтләренә тискәре тәэсир итүен билгеләп үтәсе килә.

Нәтиҗә ясап XV–XVI гасырларда Чувашиядә хуҗалык, һөнәр һәм сәүдә үсеше, гомумән алганда, Казан дәүләтенең периферия районнарындагы икътисад үсеше дәрәҗәсенә туры килгән дип билгеләргә була.

Туып килүче чуваш этносының мәдәнияте дә Казан ханлыгы чорында формалаша. Формалашучы чуваш матди һәм рухи мәдәниятендә җирле угро-фин һәм төрки халыкларның мәдәни традицияләре кушылуы ачык сизелә. Болар барысы да чувашларның гомуми мәдәниятенең хуҗалык алып бару, гореф-гадәтләр, кием, тел өлкәсендә үзенчәлеклелегенә йогынты ясаган һәм чувашларны регионның кайсы халыклары рәтенә кертергә — төркиләргәме, әллә угро-финнаргамы дигән бәхәс тууына нигез салган.

Югары чувашлар мәдәниятенә — марилар тәэсире һәм түбән чувашларга татарлар йогынтысы әйбәт төсмерләнә. М.З.Зәкиев фикеренчә, Казан ханлыгы чорында татарлар региондагы күрше халыкларга, аерым алганда «бер өлеше болгарлар арасында яшәп болгарлашкан» чувашларга «бик көчле мәдәни йогынты» ясаганнар. Казан ханлыгы чорында чувашларның татарлашу процессына шулай ук алар мохитенә ислам дине үтеп керү дә тәэсир иткән. Ислам диненең чувашларның борынгы бабаларының дини ышануларына йогынтысы эзләрен Идел буе Болгары чорыннан башлап күрергә була. Кайбер тикшеренүчеләр ислам күбесенчә мәҗүсиләр булган чувашларга өстән-өстән генә тәэсир иткән дип билгеләсәләр дә, минемчә, бу йогынты күпкә җитдирәк булган.

XV–XVI гасырларда чуваш җәмгыятенә ислам дине үтеп керүенә чувашларның дәүләтнең мөселман халкы белән тыгыз мөнәсәбәтләре, шулай ук мөселман диненең югары катлам чуваш феодаллары тарафыннан актив кабул ителүе, шул рәвешле илдә үз хәлләрен ныгытырга тырышулары да тәэсир иткән. Казан ханлыгында үткәрелгән ислам динен иректә тарату сәясәте, чуваш феодаллары ярдәме белән гади чуваш халкының бер өлешенең бу динне кабул итүенә китерә, кагыйдә буларак, алар вакыт узу белән татарлашалар[43].

Әмма шулай да чувашларның күпчелеге мәҗүси инанулар җирлегендә калган, мөселман мәдәнияте аларга аз кагылган. Чувашларның угро-фин һәм төрки борынгы бабаларында борынгы община чорында ук формалашкан һәм табигатьне, үлгәннәрнең җаннарын һ.б. олылауга нигезләнгән мәҗүси йолалары соңрак, феодаль мөнәсәбәтләр чорында бераз үзгәрә. Чуваш мәҗүси аллалары дөньясы Идел буе Болгарының, Җүчи олысының һәм Казан ханлыгының иҗтимагый-сәяси төзелешен ачык чагылдыручы катлаулы иерархия барлыкка китерә. Дәүләт башында югары хакимият вәкиле торган кебек, чуваш мәҗүси аллалары пантеонын Султи тура яки Ман тура (бөек алла) җитәкләгән, башкалар аның теләк-таләпләрен үтәгәннәр. Чувашларның дини инануларында галимнәр зороастризм һәм шаманизм элементларын табалар; шулай ук ислам дине дә чувашларның дини карашларында яңа культлар барлыкка килүгә этәргән.

Алдарак Казан ханлыгы чорында Чувашиядә шәһәрләрнең бөтенләй диярлек булмавы билгеләп үтелгән иде (Чабаксар турында югарыда әйтелде). Шуңа бәйле рәвештә тикшеренүчеләр XV–XVI гасырларда чувашларда шәһәр мәдәнияте элементлары үсмәвен билгеләп үтәләр[44]. Гомумән алганда исә, Казан ханлыгы чорында чуваш мәдәнияте чуваш җәмгыятенең этносоциаль үсеш дәрәҗәсенә туры килгән.

Чувашларның борынгы бабаларында феодаль җитештерү мөнәсәбәтләре Идел буе болгарлары йогынтысында безнең эраның икенче меңьеллыгыннан башлап үсә һәм саклана[45]. Казан ханлыгы оешкан чорга формалашып килүче чуваш этносында инде беренче феодальләшү күренешләре була. Казанның Мәхмүд хан тарафыннан яулап алынуы аның дәүләт төзелешенә Алтын Урдадан соң оешкан барлык ханлыкларга хас кайбер үзенчәлекләр өсти. Ләкин дәүләт һәм иҗтимагый төзелешнең, дәүләт белән идарә итү ысулларының нигезе булып монгол явына кадәр булган болгар традицияләре дә саклана.

Казан ханлыгы чорында чуваш җирләренең ничек идарә ителүләрен карап үтик. Казан дәүләтенең үзәк җирләрендәге кебек үк, аларда да аерым җир биләмәләре белән идарә итүче Казан феодаллары «утырган». Бу феодалларның үзләренә буйсынган чуваш феодалларына таянган булулары да мөмкин, мондый бәйләнеш ике як өчен дә файдалы була. Чувашлар яшәгән төбәктә шәһәрләр булмавы сәбәпле, Казан феодал-администраторлары хезмәтчеләре һәм кораллы көчләре белән үз поместьеларында яки гади авылларда торырга мәҗбүр булган. Ихтимал, хезмәтчеләр һәм дружинаның күпчелеген чувашлар тәшкил иткәндер, андый очракта алар аерым хокуклар һәм өстенлекләрдән файдаланганнар. Чувашлар арасында мондый феодалларның булуы турында беренче чиратта Чувашиянең төньягында табылган XV–XVI гасыр татар кабер ташлары сөйли. Ташлардан тыш чувашлар арасында Казан феодалларының булуын бер төркем авыл атамалары һәм чуваш фольклор әсәрләре раслый[46].

Чуваш салалары һәм авыллары атамаларын рус елъязмалары хәбәрләре һәм татар риваятьләре белән чагыштырып тикшерү Казан ханлыгы чорында Чувашиядә татарлар биләгән җирләрне билгеләргә ярдәм итә. Һәрхәлдә, Чувашиядәге бер төркем сала һәм авылларның атамалары XVI йөз Казан феодалларының нәсел һәм шәхси исемнәре белән гаҗәеп туры килә. Бу хәл татар иҗтимагый-икътисади йогынтысының Чуваш илендә киң таралган булуына дәлил булырга мөмкин.

Чувашиядә шулай ук мөселман рухани феодалларының җир биләмәләренең булуы да киң таралган күренеш. Шулай ук чувашларны буйсынуда тоткан феодал-аксөякләрнең бер катламы, мәҗүси чуваш дине

культына хезмәт итүчеләр — им-томчылар, тылсымчылар, сихерчеләр дә ясаклы халкы белән бергә җир биләмәләренә хуҗа булганнар.

Чуваш илендә ханның хәрби, күзәтү, хөкем-полиция хакимияте дә эшләгән. Ныгытылган пунктларда хан гаскәрләре урнаштырылган.

Чувашларның иҗтимагый тормышын ханлыкта хакимлек итүче феодаль строй билгеләсә дә, чуваш авылының үз эчендәге мөнәсәбәтләрне патриархаль-феодаль дип бәяләргә була. Чувашларның феодальләшүче элитасы һәм аның үз халкы арасындагы урыны турында XVI гасырның уртасына кадәр тарихи мәгълүматлар бик аз. Бу чуваш аксөякләре татар феодалларына буйсынган һәм турыдан-туры алар йогынтысында формалашкан булырга тиеш.

Элеккеге ыруг-кабилә тәртипләрен саклаган чуваш авылларының күпчелеге башында округ князьләре — емпу торган. Бу князьләр, мөселман динен кабул итсәләр, морза титулына да ия була алганнар, ягъни феодаль иерархик баскычта болгар-татар морзалары белән бер басмага басканнар. Тугандаш күрше чуваш авыллары төркемнәре белән йөзбашы князьләре — серпу идарә иткән. Аерым авылларны десятник князьләре җитәкләгән. «Князь»ләр белән беррәттән чыганаклар чуваш тарханнары турында да искә алалар. Җирле князьләр тархан дәрәҗәсен алганмы, әллә тарханнар хезмәттәге кешеләрнең сөйургал биләмәләренә һәм тархан иммунитетына ия булган аерым бер төркеме булганмы — билгеләү кыен. Казаклар — дәүләти хезмәтнең түбән баскычы кешеләре дә чувашлардан булган. Түләнгән ясакларның бер өлеше хәрби хезмәттә торган һәм феодаль-административ вазифалар башкарган җирле чуваш феодаллары карамагына күчкән, зур өлеше Казан феодалларына һәм хан җитәкчелегендәге хакимияткә юнәлтелгән.

Феодаль мөнәсәбәтләр белән беррәттән Казан ханлыгы чорында чувашлар арасында ыруглык мөнәсәбәтләре калдыклары да әле шактый көчле була. Общиналарда аксакаллар зур авторитетка ия булган; мәҗүси культ руханилары да җәмгыятькә көчле йогынты ясаган.

Ясаклы чувашларның күбесенең феодаль йөкләмәләре хан файдасына була, кайбер авыллардан ясак һәм башка түләүләр болгар-татар феодалларына — сөйургал хуҗаларына тапшырыла. Ясаклы чувашлар ханга яки татар феодалларына егермеләп төрдә ясак һәм салымнарны натуралата яки акчалата түләгәннәр[47]. Ләкин кулланышта булган чыганаклардан Казан ханлыгында крестьяннарны эксплуатацияләү дәрәҗәсен төгәл билгеләп булмый. Кайбер тарихчылар, 1523 елгы Сәхиб Гәрәй ярлыгындагы салым һәм түләүләр исемлеген санап чыгып, дәүләттә крестьяннар хәле бик авыр булган дип исбатларга телиләр. Әлбәттә, феодализм чорында буйсынучы халык массаларының хәле җиңел булмаган, ләкин эксплуатацияләү дәрәҗәсе салым саны белән генә түгел, ә реаль түләүләрнең гомумилеге һәм нәтиҗәлелеге белән билгеләнә. Нәкъ менә шул реаль түләүләр безгә билгеле түгел. Кайбер тикшеренүчеләр фикеренчә, Казан дәүләте халкы салымнар белән артык мәшәкатьләндерелмәгән.

Хезмәт массаларының хәле XVI гасырның икенче чирегендә, Казан тәхетенә Кырым вәкилләре утыргач кыенлаша. Казанга күпсанлы (300 дән артык) Кырым феодаллары килә, бу хәл ясаклы халыктан җыелган салымнар күләмен арттыруга китерә. Моны хәтта җирле феодаллар вәкилләре дә таный. Чуваш халык риваятьләре җирле чуваш феодал тарафыннан җәберләнүләрне дә тасвирлый. Мәсәлән, риваятьләрдә ерткыч Уразмәд — халык арасында кансыз явызлыклары белән танылган гаскәр башлыгы һәм ясак җыючы образы очрый. Чуваш авылларына кайбер нугай феодалларының һөҗүм итеп торуларын да билгеләп үтәргә кирәк. Алар крестьяннарны талаганнар, аларны әсирлеккә алганнар, терлекләрен урлаганнар[48].

Еш кына формалашып килүче чуваш этносы территориясендә, рус князьләренең басып алу сәясәте нәтиҗәсе буларак, Казан һәм Мәскәү гаскәрләре арасында бәрелешләр булып торган. Сугыш операцияләре турында мәгълүмат әле, бәлки, тулы да түгелдер. Рус елъязмалары мәгълүматларына караганда, чуваш җирләре аша Казан гаскәрләре русларга каршы яулар белән якынча 30 тапкыр, ә рус гаскәрләре Чуваш җире аркылы ханлыкның үзәк районнарына 40 тан артыграк тапкыр үткәннәр. Елъязмалар 1467–1469, 1487, 1506, 1508, 1523, 1524, 1530, 1545–1552 елларда Чувашия җирләрендә үткән орышлар турында хәбәр итәләр. Ул яулар һәм сугышлар чуваш авылларын бөлдергәннәр, халыкка санап бетергесез авырлыклар китергәннәр.

Мәскәү князьләренең көнчыгыштагы сәясәте турында югарыда әйтелгән иде. Инде XIV гасыр ахырыннан алып феодаль рус җир биләүчелеге мари, мордва һәм чуваш җирләрен басып алу исәбенә ныгыган. Русларның көнчыгышка таба мондый хәрәкәте җиңел бармаган һәм җирле халыкның көчле каршы торуына юлыккан. 1523 елның 1 сентябрендә Сураның Иделгә койган җирендә Васильгородка нигез салына, соңрак аның исемен Васильсурскка үзгәртәләр. Яңа шәһәр рус феодалларының Казан ханлыгы халкына каршы алып барган сугыш хәрәкәтләре базасы булып торган. Академик М.Н.Тихомиров фикеренчә, «Мордовия һәм Чувашиядә рус хакимиятен урнаштыру яңа шәһәрнең турыдан-туры максаты була». Васильгородка нигез салганнан соң, Сура елгасы буендагы чувашларның, мордваларның һәм тау мариларының бер өлеше Рус дәүләтенә тугры булырга ант бирәләр һәм, күрәсең, күпмедер вакыт аның

составында булалар. 1551 елның 24 маенда Зөя тамагында соңрак Свияжск дип исемләнгән Ивангородка нигез салына. Бу шәһәрне төзү Тау ягы тарихында гына түгел, бөтен Казан ханлыгы тарихы өчен дә кискен борылыш була. Казанга якын урында рус кальгасының барлыкка килүе рус гаскәрләре тарафыннан ханлыкның Тау ягын басып алынуын тизләтә һәм 1552 елда Казан дәүләтенең башкаласын яулап алу өчен плацдарм булып тора.

## 2. Дәүләтнең этносоциаль тормышында нугайлар

Нугай этносының этногенезын һәм этник тарихын өйрәнү кыпчаклар тарихы белән тыгыз бәйләнгән. Шуңа күрә, «нугай» историографиясенә күзәтү ясаганда, кыпчаклар һәм Алтын Урда тарихына кагылышлы күпсанлы басмаларны читтә калдырырга ярамый. Монда П.Голубовский, К.П.Кудряшов, Б.Д.Греков һәм А.Ю.Якубовский, М.Г.Сәфәргалиев, Г.А.Федоров-Давыдов, Б.Е.Кумеков, С.А.Плетнева, М.Г.Госманов, Р.Г.Фәхретдинов һәм башка тикшеренүчеләр хезмәтләрен аерып күрсәтергә кирәк. Нугайлар этногенезына, Нугай Урдасы генезисына, урта гасырлар нугайларының күрше этнослар белән мөнәсәбәтләренә Н.И.Веселовский, М.Г.Сәфәргалиев, Ә.Б.Булатов, М.И.Әхмәтҗанов, Ф.Г.Гарипова, Д.М.Исхаков, И.Х.Калмыков, Р.Х.Керейтов, Д.Кидырниязов, В.В.Трепавлов һ.б. тикшеренүләре багышланган. XIX гасыр ахырыннан башлап нугайларның этнографиясенә һәм этник тарихына багышланган күпсанлы басмалар дөнья күрде, шулар арасында А.Павлов, А.А.Скальковский, А.П.Архипов, Г.Ананьев, С.В.Фарфаровский, И.Т.Мутенин, Е.П.Алексеева һәм И.М.Аджиев, Л.Н.Кужелова, И.Х.Калмыков, Р.Х.Керейтов, А.И.Сикалиев һәм башка галимнәрнең хезмәтләре[49] бар.

Алтын Урда чоры Көнчыгыш Европа төркиләренең этник консолидациясе фонында аларның этник дифференциациясе процесслары да ачык күзәтелә, шул исәптән нугай һәм литва татарлары этник үзенчәлекләре күзгә чагыла башлый. Җәмгыятьтәге төрле этноэволюцион һәм этнотрансформацион процесслар белән бәйле булган бербөтен этник системадан чагыштырмача зур булмаган этник төркемнең аерылып чыгуы һәм вакыт дәвамында аның яңа этноска әверелүе этник сепарация дип атала. Нугай этносы барлыкка килгәндә нәкъ шундый процесс күзәтелә. Аның нигезен кыпчаклар һәм башка төрки, төгәлрәк әйткәндә Көнчыгыш һәм Урта Азия төркиләре һәм угор халыклары тәшкил иткән. Күпсанлы нугай ыруглары арасында иң киң таралганнарының тарихлары бик борынгы чорга барып тоташкан уйгырлар, уйсуннар, найманнар, кераитлар, кыпчаклар, дурменнар, катаганнар, кунгыратлар, мангытлар, кенегесләр, канглылар, аслар, болгарлар һ.б. белән бәйле[50]. Бу ыругларның «мангыт» (ыругларның берсенең атамасы) һәм «нугай» (атаклы Алтын Урда бәкләр бәге Нугай исеменнән түгел, ә уңай, мактаулы эчтәлектә кулланылган — моны «Сокровенное сказание»ның §195 һәм 209 текстлары раслый[51] — монголча nogai (эт) сүзеннән) җыелма этнонимы астында этник консолидациясе XIV гасыр ахыры — XV гасыр башында тарихи аренада Мангыт сәяси берләшмәсе барлыкка килүенә китерә, аның башында мангыт Идегәй тора[52].

Мангыт-Нугай Урдасының күпсанлы халыкка ия булуы һәм зур хәрби куәте нәтиҗәсендә XV–XVI гасырларда нугайлар далаларда гына түгел, Урта Идел буеның урманлы территориясендә дә мөһим роль уйнаганнар.

Кулланышта булган чыганакларга таянып, Казан ханлыгының этносоциаль тарихына нугай йогынтысы турында нинди нәтиҗәләр ясап була соң?

1. 1445 елдан алып Казан ханнарын тәхеткә утыртуда һәм Казан дәүләте белән идарә итүдә дәрәҗәле кыпчак-нугай (татар) ыруг-кланнарының катнашуы мәгълүм. Моны раслаучы алда санап үтелгән дәлилләргә тагын ике хәбәр өстәргә була. Мәсәлән, XVI гасыр башында Урта Идел буендагы этнополитик хәл белән яхшы таныш булган С.Герберштейн нугай «князе» Коссум «Кама, Җаек һәм Ра (ягъни Кама, Урал һәм Идел арасы, ә бу исә Казан ханлыгының көньяк-көнчыгыш өлеше) елгалары арасында урнашкан барлык әйбер»гә хуҗа дип яза. Ә Иван IV гә нугай бәге Йосыф биргән грамотада укыйбыз: «А ныне в Казани дочи моя и племя мне тамо есть» (ягъни сүз Сөембикә ханбикә турында бара).

2. Казан ханлыгы һәм Нугай Урдасы арасындагы чикләр беркайчан да төгәл булмаган һәм сакланмаган, бу хәл исә үзара этнокультур, иҗтимагый-икътисади һәм сәяси бәйләнешләр өчен уңай шартлар тудырган. Шуның нәтиҗәсе буларак, без нугайларның Казан ханлыгының бөтен территориясенә актив үтеп керүләрен күзәтәбез. (Нугайларның Казан ханлыгы территорисенә миграциясендә дала аридизациясе дә роль уйнаган.) Моны түбәндәге дәлилләр раслый:

а) нугайларның ханлык территориясе буйлап җәен күченеп йөрүләре турында чыганаклардагы хәбәрләр. Мәсәлән, «Мамай мурза и Юсуф мурза кочюют близко Казани на летовище...» — дип хәбәр итēлә, ә нугай «морзасы Урак» 1536 елның җәендә «Иван князьгә»: «...то извечное наше кочевище к Казани кочевати»[53], — дип хәбәр итә. 1548 елның 8 октябрендә теркәлгән хәбәрдә: «К царю и великому

князю от Исмаил мирзы татарин его служилой Бахтеяр Баймаков... прибыл... и сказывал царю и великому князю, что он был у Исмаил мирзы на Каме 60 верст от Казани. А Исмаил тут летовал...»[54] — дигән мәгълүмат китерелә;

б) Казан татарларына, нугайларга һәм башкортларга караган шәҗәрәләрнең күпчелегендә тамырлары белән XV–XVI гасырларга барып тоташкан туганлык билгеләре чагыла. Шәҗәрә материаллары буенча галимнәр М.И.Әхмәтҗанов һәм Д.М.Исхаков, гайнә татарлары тарихи риваятьләренә таянып, Казан ханлыгының көньяк-көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш регионнарының күбесе нугайларның күчеп йөрү районнары гына булып калмыйча, аларның сәяси, иҗтимагый-икътисади һәм этник тәэсире сферасы да булган дигән нәтиҗә чыгаралар. Д.М.Исхаков хәтта, бәлки әле, Урал буеның төньяк-көнчыгышы Казан һәм нугай феодалларының икесенә дә буйсынгандыр дигән фараз ясый;

в) Ә.Б.Булатов һәм Ф.Г.Гарипова хезмәтләрендә китерелгән топонимия мәгълүматлары Казан татарлары этногенезында барлыгын билгеле бер нугай элементына күрсәтәләр, нугайларның Казан ханлыгының көньяк-көнчыгыш районнарында да, төньяк-көнбатыш районнарында да булуларына ишарәлиләр.

3. Чыганаклар Казанда нугай бадраклары нәселе вәкилләре яшәве турында хәбәр итәләр, моны топонимия мәгълүматлары да раслый.

4. Чыганаклар Казандагы күпсанлы нугай сәүдәгәрләре турында хәбәр итәләр. Күчмә нугайлар мөгезле эре терлек, атлар һәм сарыклар белән сату иткәннәр.

5. Казан ханлыгында хакимлек итүче династияне алыштыруда катнашу, әлбәттә, нугайларның илнең сәяси тормышында актив рольләрдә булуы чагылышы. Нугай йогынтысы тагын күпсанлы нугайларның Казан ханына хәрби хезмәткә яллану юлы белән таралган, аларның саны еш кына 30 мең кешегә җиткән, бу турыда рус елъязмаларында хәбәрләр бар. Шулай ук Казан ханлыгы тарихында күпсанлы мисаллары булган болгар-татар һәм нугай феодаллары вәкилләре арасындагы никахлар да нугайлар тәэсирен арттырган. М.Г.Госманов фикеренчә, нугайларның ханлыкның сәяси тормышында роле XVI гасыр башында Казанга Кырым династиясе вәкилләре Гәрәйләр килгәч тагын да көчәя.

Шулай итеп, Казан ханлыгының сәяси тормышында, аның халкының этнополитик структурасында кыпчак-нугайларның роле зур икәнлеген һәм бу хәлнең, әлбәттә, бу регион халыкларының, аерым алганда Казан татарларының этник тарихына йогынты ясавын билгеләп үтәргә була.

## 3. Ханлыкка керүче башкортларның этносоциаль үсеше

Башкортлар этногенезы бүгенге көн тарих фәнендә иң катлаулы мәсьәләләрнең берсе булып тора. Тикшеренүчеләрнең нинди чыганакларга таянуына карап, башкортларның борынгы бабалары буларак сарматлар яки Идел буе болгарлары (В.Н.Татищев), нугайларга тугандаш кабиләләр (П.И.Рычков), угро-финнар (Г.Уйфальви), һуннар яки уйгырлар (С.Мирасов) һ.б. аталды.

Башкортларның угро-мадьярлардан килеп чыгуы турында гипотезага нигез салучылар һәм аны үстерүчеләр буларак И.Страленбергны, А.Л.Шлецерны, П.И.Шафарикны, В.В.Гумбольтны атарга була. Ләкин тәмамланган концепция формасында бу идеяне 1869 елда академик Д.А.Хвольсон бәян итә. XIX гасыр ахыры галимнәре арасында бу концепция тарафдарлары күп була (И.Н.Березин, Ж.Э.Реклю һ.б.). Соңрак башкортларның угор чыгышлы булулары турындагы караш берничә кат яңартылды. Күп кенә яңа тикшеренүләр авторлары аңа мөрәҗәгать итә (С.П.Толстов, С.А.Токарев, М.И.Артамонов һ.б.). Гомумиләштерүче басмалар рәтенә үтеп кереп, башкорт этногенезеның угро-мадьяр концепциясе хәзерге тарих фәненең киң таралган төп фикерләренең берсенә әверелде.

Бу концепция белән килешмәүчеләр дә һәрвакыт булды. XIX гасыр ахыры — XX гасыр башында фәнни әдәбиятта башкорт этносының төркиләрдән килеп чыгуы турында концепция формалаша. Барыннан да ачыграк ул Н.М.Малиев һәм В.М.Флоринский хезмәтләрендә тәгъбир ителгән. Алардан алдарак шундый рухтагы фикерләр В.В.Вельяминов-Зернов һәм фин галиме Д.Европеус тарафыннан әйтелә. Аларның хезмәтләре XIX гасыр ахыры — XX гасыр башы галимнәренә нык тәэсир итә.

Фәнни фикер үсеше акрынлап булса да, ахыр чиктә башкорт халкының төрки чыгышына өстенлек биреп, теге яки бу дәрәҗәдә аның этногенезында угро-фин компоненты катнашуын да инкяр итмәгән юнәлеш буенча барды. Башкорт этногенезының төрки нигезе һәм анда угор компонентының күпмедер дәрәҗәдә катнашуы турында фикер беренче тапкыр 1885 елда Х.Вамбери тарафыннан тәкъдим ителде.

XX гасыр башы башкорт халкының этник тарихына кагылышлы бер төркем яңа хезмәтләр барлыкка килүе белән билгеләнде. Бу хезмәтләргә кергән фактик материал аеруча кыйммәтле, алар арасыннан М.Һадиев һәм С.Руденко хезмәтләрен аерып күрсәтергә мөмкин.

Башкортларның этногенезын һәм этник тарихын өйрәнүнең яңа чоры сугыштан соңгы елларга туры килә. Бу этапка хас үзенчәлекләр: башкорт этник тарихының күп якларын төрле дисциплиналар казанышларына — археологиягә, этнографиягә, антропологиягә, лингвистикага, фольклористикага һ.б. таянып тикшеренүләрнең киң масштаблы булуы һәм тагын да үсә баруы; этногенетик тикшеренүләргә комплекслы якын килүгә күчү; башкортларның бары тик угро-фин яки төрки чыгышлы гына булулары турындагы традицион концепцияләрнең капма-каршы чикләреннән чыгып карау тенденциясе һәм этносларның барлыкка килүен һәм формалашуын киң территориядә һәм чагыштырмача озак вакыт диапазонында барган этнокультур, тел һәм иҗтимагый-икътисади күренешләрнең катлаулы, үзара бәйләнгән даими үсеш процессы буларак тикшерүгә омтылу.

XX гасырның икенче яртысы башкорт этногенезы һәм этник тарихы буенча күпсанлы әдәбият басылуы белән билгеләнде, аерым алганда бу өлкәдә абруйлы тикшеренүче Р.Г.Кузеев хезмәтләре дөнья күрде[55].

Көнчыгыш Европа һәм Азия арасында урнашкан Башкортстан географик яктан шушы ике табигатьнең төрле характердагы үзенчәлекләрен берләштерүче үзенә бер төрле гаҗәп комплекс булып тора. Башкортстанның Казан ханлыгына кергән көнбатыш өлешенә Идел буе географиясе үзенчәлекләре хас, көньягына — Азия далалары, көнчыгышына Себер тайгасы табигате йогынтысы сизелерлек. Табигать-климат шартларының шактый төрле булуы борынгы чорлардан ук җирле кабиләләрдә хуҗалык эшләренең төрле төрләре үсеш алуына китергән, чөнки өлкәнең Европа һәм Азия, дала һәм урман полосасы арасында урнашуы аны төрле хуҗалык һәм мәдәни тормыш өлкәләре арасында бәйләнеш зонасына әверелдерә.

Формалашучы башкорт этносы хуҗалыгы һәм көнкүреше, аның мәдәни-икътисади үсеше шулай ук өлкәнең гидрографик шартлары тәэсирен кичерә. Монда елгалар күп. Урал буеның төп су артериясе — Камага коючы Агыйдел елгасы (кайбер галимнәр раславынча, борынгы дәверләрдә Агыйдел Иделгә койган, ә Чулман-Кама Агыйдел кушымтасы саналган). Иң тыгыз елгалар челтәре Көньяк Уралның көнбатыш битләрендә.

Башкорт этносының хуҗалык тарихына бу өлкәгә хас җир-үсемлек ландшафтларының бай гаммасы йогынты ясаган. Башкортстан территориясендә игенчелек белән шөгыльләнү өчен кулай уңдырышлы мәйданнар күп. Ләкин шулай ук игенчелек өчен ярамаган җирләр дә шактый зур мәйдан били.

Элек Башкортстанның шактый зур территориясен урман тәшкил иткән. Урал тауларыннан агып төшүче күпсанлы елгаларның киң үзәннәрен болыннар каплаган. Башкортстанның үсемлек һәм хайваннар дөньясы башкорт этносы үсеп чыккан һәм формалашкан географик мохитнең мөһим факторы булып торган.

XV гасырның беренче яртысында Башкортстан территориясе (якынча 180 меңлек халкы белән[56]) өч сәяси берләшмә — Нугай Урдасы, Казан һәм Себер ханлыклары арасында бүленә. Башкортларның күпчелек өлеше нугай ханнарына буйсына, Урал арты башкортлары Себер ханлыгы составына керә, көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш Башкортстан җире Казан ханлыгы кулында була.

Казан ханлыгының Борынгы Башкортстанга сәяси һәм хуҗалык-мәдәни тәэсире, һичшиксез, көчле булган. Бу йогынты XV — XVI гасырның беренче яртысында Казан татарлары һәм башкортлар өчен гомуми этник базага нигезләнә, чөнки ике халыкның да формалашуында кыпчак компоненты зур роль уйнаган, Идел буе болгарларының утрак игенчелек культурасының күп традицияләрен саклаган Казан татарлары үсешенең этносоциаль юлы күчмә башкортлар үсешенең этносоциаль юлыннан сизелерлек аерылса да.

Казан ханнарының даими сюзеренитеты саналган башкорт территориясе зур булмаган. Ул Ык елгасының урта һәм түбән агымы, Минзәлә үзәне, Агыйделнең түбән агымы һәм Каманың сул ярындагы районнар белән чикләнгән. Казан ханнарының бу территориядән тыш җирләрдә хакимлек итүләрен раслаучы мәгълүматлар юк. Үз яшәешенә бәйле рәвештә Казан ханлыгы көнбатыш тарафта актив сәясәт белән шөгыльләнсә, көнчыгышка таба ул биләмәләрен киңәйтүгә омтылмаган. Казан ханнарының башкортларга карата алып барган сәясәтләренең нигезен күчмә халыкларны үз якларына аударырга тырышу тәшкил иткән. Мондый мөнәсәбәтләрнең характеры ирәкте кабиләсенең һәм башка башкорт нәсел төркемнәренең Казан ханнарына хәрби хезмәт күрсәтү тарихында ачык сурәтләнә, шуның бәрабәренә башкорт аксөякләре зур җир биләмәләре һәм башка өстенлекләр белән тархан грамоталары алганнар. XV гасырда Ык үзәнлегендә табынлы, бөрҗән, мин, кыпчак, тамьян, тангаур һәм башка башкорт кабиләләренең барлыкка килүе нәкъ менә шуның белән аңлатыла. Ул вакытта Нугай Урдасына кергән территориядә яшәгән көнчыгыш башкортларның Казан ханнарына хезмәткә ялланып ханлык чикләре янына күчеп утырулары мөһим күренеш булып тора. Кайбер башкорт кабиләләренең Казан ханына хезмәт итүләре аларның Идел буе Болгары хакимнәре һәм Алтын Урда чоры Болгар әмирләре белән борынгы бәйләнешләренең дәвам ителеше булып торган.

Гомумән алганда, Башкортстанның иң көнбатыш районнарының Казан дәүләте составына керүе, тагын да зуррак территорияләренә аның икътисади һәм сәяси тәэсире, башкортларның бер өлешенең Казан

гаскәрләре составында хезмәт итүе XVI гасырда башланып киткән башкорт һәм татарларның этник катнашуына этәргеч булып тора. Бу хәл татарларның башкортларга этнокультур тәэсире процессын көчәйтүгә китерә.

XV — XVI гасырларда Башкортстанга, асылда, моннан алдагы чор кыпчак кабиләләре миграциясенең дәвамы булган нугайлар күченүе ешаеп китә. Озак вакытлар дәвамында күршелек яки бер территориядә яшәү, тел якынлыгы, күчмә культура берлеге нигезендә активлашкан башкортлар һәм нугайлар арасындагы этник бәйләнешләр үзара тәэсир характерын йөрткәннәр, аерым нугай төркемнәренең башкорт этник мохитенә ыруг яки ыруг бүлекчәсе хокукларында үтеп керүләре белән бергә барган. Башкорт белән нугайларның берләшү-кушылу масштаблары шактый зур була, моны башкорт шәҗәрәләре дәлилли.

Казан ханлыгы чорында башкорт этник төркемнәренең төньякка таба, дәүләтнең угро-фин халыклары яшәгән төбәкләренә, шулай ук нугай феодалларына буйсынган Пермь җирләренә күченүләре күзәтелә. Бу процесслар этник бәйләнешләргә һәм миксациягә китерә, ягъни төньяк башкортлар борынгы мансилар, коми, удмурт һәм марилар белән кушылалар, моны этнографик мәгълүматлардан ачык күрергә була. Шулай итеп, Казан ханлыгы составына кергән төньяк-көнбатыш башкортларның этник тарихында регионның угро-фин халыклары җитди роль уйный башлый. Бу бәйләнеш башкортларның мәдәниятендә һәм көнкүрешендә чагылган. Аерым алганда, төньяк-көнбатыш башкортларның һәм угро-финнарның катнашуы төньяк башкорт мохитенә болгарлардан үтеп кергән ислам өстенлеге белән беррәттән башкортлар арасында регионның угро-фин халыклары өчен хас булган мәҗүси йолаларның да XIX гасырга кадәр саклануына китерә.

Гомумән алганда, XVгасыр һәм XVI гасырның беренче яртысындагы этник процесслар башкорт халкының этник характеристикасында сизелерлек эз калдырган һәм башкортларның ул вакытка инде төп контурлары формалашкан этнографик төркемнәре арасындагы региональ аермаларны шактый тирәнәйткәннәр.

Башкортларда этнотерриториаль төркемнәр булуын күрсәтеп, аларның өчесен аерым билгеләп үтәсе килә — бүләр, бөрҗән һәм табынлылар.

Башкорт-бүләрләр Идел буе Болгары халкының күрше угор кабиләләре белән якыннан аралашу мөнәсәбәтен кичергән һәм борынгы башкорт этник берләшмәләре белән тыгыз бәйләнештә булган өлешенең нәсел дәвамы булып торган.

Бөрҗәннәрнең тамырлары Урта Азия ыруг-кабиләләре белән тоташкан. Алар чыгышлары белән бәҗәнәкләргә тугандаш төркиләр булганнар. XVI гасырда алар Башкортстанның көнбатыш чикләрендә, Ык елгасыннан көнчыгышка таба яткан җирләрдә яшәгәннәр һәм, һичшиксез, Казан ханлыгы йогынтысында булганнар.

Табынлылар — кыпчаклар нәселе. XV гасырда Казан ханлыгының көнчыгыш чикләренә күчеп утырганнар һәм шунда ханга хезмәт итә башлаганнар. Монда барын ыруының бу этник төркемнең бер бүлекчәсе булып торуы игътибарга лаек. Бәлки, нәкъ менә алар — барын вәкилләре — Казан ханына үзләре теләп буйсынуны башлап җибәрүчеләр булгандыр. Казан ханы сараенда данлыклы төрки нәселе Барын зур ихтирам казанган (бу турыда алда әйтелде). Ничек кенә булмасын, шул вакыттан башлап ханга хезмәт итә башлыйлар һәм «ирәкте» яңа этник атамасын алалар, ул исә «ныгытмада хезмәт алып баручылар» дигәнне аңлата.

Алда билгеләп үтелгәнчә, башкорт кабиләләренең Казан ханына хезмәт итүе аларның Идел буе Болгары хакимнәре белән борынгы мөнәсәбәтләренең дәвамы булып тора. Казан ханы тархан хокукларын һәм өстенлекләрен угланнары һәм иптәшләре белән аңа хезмәткә кергән башкорт биләренә биргән. Кара табынлы Шәех Әхмәт би, аның иптәшләре һәм угланнары Казан ханы-сюзеренда нәкъ менә шундый хезмәттә торганнар һәм үзләренең яңа халәтләренә ярашлы яңа буын исеме — «ирәкте»не алганнар.

Икенче меңьеллыкның беренче яртысында ук хәзерге башкортларның борынгы бабалары «башкорт», «башкорттар» гомуми җыелма этнонимы астында билгеле булалар. Җирле халыкның гомуми үзатамасының тамыр җәюе милли берлекне тану үсешен чагылдыра. Бу күренеш XV гасыр һәм XVI гасырның беренче яртысында тагын да көчәя. Бу көчәю еракка миграцияләр һәм күчеп йөрүләрнең масштаблары кыскаруына, башкорт этносының хуҗалык практикасы тупланган территориянең чагыштырмача тотрыклануына турыдан-туры бәйле була.

XVI гасырның беренче яртысында башкортларның халык буларак формалашуы өчен кирәк этник, территориаль, иҗтимагый-икътисади һәм сәяси башлангычлар бергә җыела. Башкорт кабиләләре һәм этнографик төркемнәре актив бәйләнешләр һәм мөнәсәбәтләрдә торган Башкортстан территориясенең чикләре билгеләнә, диалекталь аермалар әле шактый вакыт саклланса да, бөтен этнос өчен аңлаешлы башкорт теле, башкорт этносының үзенчәлекле мәдәнияте формалаша, консолидация процесслары үсеше өчен әһәмиятле барлык иҗтимагый-икътисади һәм сәяси шартлар өлгерә.

Алда башкорт этносы формалашкан географик мохитнең башкортлар тормышының барлык якларына, аерым алганда аларның хуҗалык эшчәнлегенә төрле яклардан тәэсир итүе турында әйтелгән иде. Башкорт кабиләләренең икътисади үсешенә аларның Башкортстанның аучылык-игенчелек белән шөгыльләнүче утрак һәм терлекчелек белән шөгыльләнүче күчмә кабиләләр аралашкан төбәктә урнашуы да зур әһәмияткә ия булган.

Казан ханлыгы чорында башкортлар хуҗалыгының нигезен күчмә терлекчелек тәшкил иткән. XVI гасыр уртасында «Камадан Әстерханга кадәр Иделнең сул ягында урнашкан» илдә булып кайткан А.Дженкинсон андагы халыклар «терлекчеләр һәм күпсанлы хайваннар аларның төп байлыгын тәшкил итә» дип яза. Алар «итне, күбесенчә ат итен, күп ашыйлар һәм ат сөте эчәләр»[57]. Башкортларның үз чыганаклары (шәҗәрәләр, риваять һәм легендалар) терлекчелекнең әле хәтта XVII–XVIII гасырларга кадәр башкорт хуҗалыгының төп тармагы булып калуын тагын да ачыграк күрсәтәләр.

Башкортлар шөгыльләнгән тагын бер мөһим тармак аучылык була. Казан дәүләтенә кергән Башкортстанның төньяк-көнбатыш өлешендә җәнлекләр һәм кошларга бай урманнар өстенлек итүе башкортлар арасында аучылыкның киң таралуына китерә. Мехлар һәм тиреләр белән башкортлар феодалларга ясак түләгәннәр.

Чолык умартачылыгы, аучылык кебек үк, башкортлар өчен ярдәмчел шөгыль түгел, кәсеп әһәмиятенә ия була. Чолык умартачылыгы белән уңайлы урманнар булган бөтен Башкортстан территориясендә шөгыльләнгәннәр. Бал, мех кебек үк, феодаль салымнарның бер өлешен тәшкил иткән.

Җирле елга һәм күлләр төрле балыкларга бай булганга, башкортларда балыкчылык та киң үсеш ала.

Кошчылык башкортларда артык таралмаган. Әмма тикшеренүчеләр башкортларның аз санда тавык, каз һәм үрдәк үрчетүләрен билгеләп үтәләр.

Башкортлар яшәгән территориянең күпчелек өлеше, бигрәк тә урман һәм тау районнарының табигать-климат шартлары игенчелек белән шөгыльләнү өчен уңайсыз була. XV–XVI гасырларда башкортларда иген игүгә зур әһәмият бирелмәвенең төп сәбәбе шул булгандыр, мөгаен. Башкортлар язын зур булмаган участокларга тары яки арпа чәчкәннәр, уңыш бары тик ашауга киткән. XIV–XVI гасыр вакыйгаларын тасвирлаган башкорт-юрматлылар шәҗәрәсендә: «Бервакыт ач еллар килде. Кыш бик озак булды... икмәк бөтенләй уңмады», — диелгән. Ләкин шулай да Казан ханлыгы чорында башкортлар хуҗалыгының нигезе Кама һәм Каспий диңгезе арасындагы чиксез территориядә хакимлек иткән күчмә терлекчелек булуын тагын бер кат ассызыклыйк. А.Дженкинсон бу җирләрнең күчмә халыклары турында «алар берни дә чәчмиләр һәм ипи ашамыйлар... алар нигездә терлекчеләр» дип юкка гына язмаган.

XV–XVI гасырларда башкортларда күпмедер дәрәҗәдә табигать нигъмәтләрен җыеп көн күрү гадәте дәвам итә. Көньяк Уралда 100 гә якын ашарга яраклы кыргый үсемлекләр, шул исәптән 20 гә якын җиләк-җимеш үсемлекләре үскән.

XV–XVI гасырларда башкортларда һөнәрчелек зур күләмдә үсеш алмаган һәм тормыш-көнкүрештә ярдәмчел роль уйнаган. Бу чорда башкортларда металл һәм агач, мех һәм күн, хайваннар һәм үсемлекләр матдәләрен эшкәртү шактый гына камилләштерелә. Күчмә тормыш алып бару өчен уңайсыз булган керамиканың юклыгы һәм зур агач корылмаларның аз булуы күзәтелә. Шул ук вакытта көнкүрештә кулланылган әйберләр, савыт-саба агачтан ясалган була. Казан дәүләтенә кергән төньяк-көнбатыш Башкортстанның урман полосасында яшәгән игенче халкында күрше халыкларныкына охшаш агач тораклар булган, ләкин Башкортстанның башка регионнарында төрки һәм монгол кибиткалары тибындагы вакытлы корылмалар, тирмәләр кулланылган.

Азия белән Европа тоташкан җирдә, ике төрле мәдәният учаклары арасында урнашкан Башкортстанның үзенчәлекле географик урыны башкорт кабиләләренең рухи һәм матди мәдәниятенең оригиналь үсешенә китергән. Бүгенгәчә башкортларны характерлаган этнокультур билгеләр XIII–XIV гасырларда формалашкан һәм үскән. Бу синтезда хәзерге башкортларны Идел буе, Казакъстан, Урта Азия һәм Алтай төркиләре белән берләштерүче күп сыйфатларны билгеләүче һәм башкортларны шул ук халыклар рәтеннән аеручы үзенчәлекне формалаштыручы культураларның яңадан үзара тәэсир итешүе һәм катлаулы ярашуы була.

XV–XVI гасыр башкортларында телдән башкарылучы һәм музыкальләштерелгән ярым мифик иҗат киң таралган була. Күрше халыкларның иҗаты белән бәйләнешләре булса да, ул үзенчәлекле, төрле һәм бай була, араларында героик эпос, әкиятләр һәм җырлар булган төрле жанрларда иҗат ителә. Башкорт халкының күчмә тормыш алып баруы бу жанрларның киң таралуына нигез булып тора, чөнки шул рәвешле язу кулланмыйча халыкның рухи байлыгы һәм аның тарихи бабалары турында мәгълүмат буыннан буынга тапшырыла. Мондый ысул кәгазьдән ышанычлырак булып чыккан, һәм ул борынгы вакыйгаларның кайтавазын безгә дә китереп җиткергән.

Башкортлар арасында төрле кулланма сәнгать тә таралган була, аерым алганда — чүкеп бизәк төшерү һәм күн аппликациясе, алар күчмә халыклар тормышында эстетик кына түгел, гамәли әһәмияткә дә ия булган.

Башкортларның кайчан мөселман динен кабул итүләре, шуның белән беррәттән гарәп язуын куллана башлауларының төгәл вакыты билгеле түгел. Булган чыганакларга караганда, башкортлар арасында исламның таралуы берничә йөз елга сузылган һәм XIV–XV гасырларда, ә бәлки әле, XVI гасырда гына тәмамлангандыр, мөгаен. Ләкин ислам динен кабул итү башкортлар хәтереннән аларның борынгы ышануларын бөтенләй сызып ташлый алмаган. Башкортлар арасында ислам диненә кадәр булган күзаллауларның эзләре озак сакланган: алар табигать һәм аның күренешләрен җанландырганнар; аларда тотемнар сакланган; алар язмышка ышанганнар; алар кара китапчылар (кара китапсы) булуына ышанганнар; башкортларда тылсымчылар, күрәзәчеләр (багусы), сихерчеләргә (сихерсе) ышану, алардан курку яшәгән. Куркыныч янаганда шуларга мөрәҗәгать иткәннәр. Бу дөньяга карашларны анализлаганда, хайваннар һәм йолдызлар культы, табигатьне җанландыру һәм шуңа бәйле анимистик карашлардан башлап шаман культы калдыкларына кадәр төрле вакытларда өстәлгән катламнарны күрергә була[58].

Башкорт җәмгыяте XV гасыр һәм XVI гасырның беренче яртысында кичергән иҗтимагый-икътисади үсешкә бәя биргәндә исәпкә алынырга тиешле гомумтарихи факторлардан, югарыда тасвирланган хуҗалык алып бару үзенчәлекләре һәм табигый географик шартлар төрлелегеннән тыш тагын ике мөһим моментны билгеләп үтәргә кирәк: 1) башкортларның этник составының күп компонентлы булуы һәм башкорт этногенезында катнашкан кабиләләрнең иҗтимагый үсеш дәрәҗәләренең төрлелеге; 2) башкортларга тышкы шартлар тәэсире — IX–XIV гасырларда башкортларның этник бабаларының Идел буе Болгары һәм Алтын Урда феодаль дәүләтләре карамагындагы үсеше, Җучи олысы таркалганнан соң башкорт биләмәләренең Казан дәүләте, Себер ханлыгы һәм Нугай Урдасы бергәлекләренә керүе.

XV–XVI гасырларда башкорт җәмгыятенең феодальләшү процессы үсүе, кабилә башлыкларының сыйныфның аерым югары катламы буларак аерылып чыгуы күзәтелә. Башкорт җәмгыятенең феодаль югары катламын биләр — кабилә башлыклары, батырлар — хәрби җитәкчеләр һәм тарханнар тәшкил иткән. Башкортларда тарханлык институты әле болгар чорында ук барлыкка килә, ләкин аның югары үсеш алуы XIII–XVI гасырларга туры килә. Бу вакытларда Алтын Урда, соңрак Казан һәм нугай ханнары хезмәткә ялланган башкорт аксөякләренә җир биләү яки башка өстенлекләр биргән тархан грамоталары өләшкәннәр.

Башкорт җәмгыятенең нигезен исә терлек тотучы гади милекчеләр тәшкил иткән, аларның тормыш-яшәеше югары катлам феодаллар тарафыннан билгеле бер кысада тотылган. Ясак түләүне һәм өлешчә Казан ханнары казнасына күчүче башка йөкләмәләр авырлыгын нәкъ менә гади общинниклар күтәргән, алар яуларда катнашырга, җирле феодал хуҗалыгында эшләргә тиеш булган. Элек авыл җәмәгате-ыру тормышының иң мөһим мәсьәләләрен чишкән җыеннар (йыйын) Казан ханлыгы чорында кабилә аксөякләре йогынтысы көчәюе һәм болгар-татар морзаларына буйсыну нәтиҗәсендә үз әһәмиятен югалта төшә. Б.Х.Юлдашбаев фикеренчә, Казан ханлыгы чорында «башкорт халкында үзидарә тәртибе бик чикләнгән була».

Башкортлар яшәгән җирләрнең төньяк-көнбатыш биләмәләренә номиналь рәвештә Казан ханы ия булган, аның файдасына буйсынучы халыктан төрле салымнар җыелган. Бу территория хан тарафыннан наместникларга — ханлыкның дәүләт системасында билгеле урын биләгән туганнарына һәм вассал буларак аңа буйсынган иярченнәренә өләшенгән була. Башкорт биләре хан наместникларына вассал буларак буйсынганнар, ләкин үзләре үз чиратында вак милекчеләргә карата сюзерен ролен уйнаганнар. Шулай итеп, Идел буе Болгарының, Алтын Урданың һәм Казан дәүләтенең эчке төзелешенә хас феодаль характер башкорт этносының иҗтимагый тормышын да тулысынча характерлый.

1552 елда Казанның Иван IV гаскәрләре тарафыннан яулап алынуы башкорт халкының этносоциаль тарихында яңа этап башлап җибәрә.

Казан ханлыгының перифериядәге төрки халкының этносоциаль үсешен тикшереп, түбәндәге нәтиҗәләргә килергә була:

1. Казан ханлыгының Азия белән Европа тоташкан җирдә, ике төрле мәдәният учаклары арасында урнашуы җирле халыкның оригиналь этнокультур һәм этносоциаль үсешенә китерә.

2. Казан ханлыгы чорына этникара бәйләнешләр интенсивлыгы артуы хас.

3. Казан дәүләтенең бөтен тарихы дәвамында кыпчаклашкан этник компонентның күләме арта баруы күзәтелә, аның вәкилләре ханлыкның сәяси тормышында зур роль уйнаганнар.

4. Казан ханлыгы чорында дәүләтнең кайбер төрки кавемнәренә карата угро-финнарның шактый көчле йогынтысы сизелә, бу хәл барыннан да ачыграк чувашлар этногенезында чагылган.

5. Казан ханлыгының перифериядӓге төрки халкының икътисады Болгар һәм Алтын Урда дәүләтләре вакытларыннан бирле сизелерлек үзгәрмәгән.

6. Казан ханлыгы чорында Идел-Урал төбәге территориясенә көнчыгыш славяннар экспансиясе активлаша һәм даими факторга әйләнә.

# КАЗАН ДӘҮЛӘТЕНЕҢ УГРО-ФИН ХАЛКЫ

## 1. Дәүләт карамагындагы мариларның борынгы бабаларының этносоциаль үсеше

Казан дәүләтенең угро-фин халыклары төркеменә марилар, удмуртлар һәм мордвалар кергән.

Борынгы мариларның Казан ханлыгы чорындагы этносоциаль үсешен карап үтик.

Мари халкына кагылышлы беренче тарихи-этнографик тасвирламалар һәм аларның килеп чыгышына бәйле аңлатмалар XVIII гасырга карыйлар. Бу хезмәтләрдә марилар Урта Идел буеның иң борынгы халкы дип танылa һәм борынгы фин кабиләсенә кертелә. Аннан соңгы елларда мари этносының тарихы һәм барлыкка килүе белән кызыксыну шактый арта. XIX гасыр ахырында И.Н.Смирнов, Т.Семенов, М.П.Веске, А.А.Спицын, С.К.Кузнецов һ.б. хезмәтләре дөнья күрә, аларда этнографик, лингвистик һәм археологик материаллар нигезендә борынгы мариларның башта Идел буеның киң территориясендә яшәүләре, регионның угро-фин халыкларының генетик якынлыгы, мари этносы мохитендә якын тугандаш этник төркемнәр булуы турында фикер алга чыгарыла. Мари этносының борынгы һәм урта гасырлар тарихын өйрәнү XX йөздә, бигрәк тә аның икенче яртысында нык үсә, моңа 1965 елда Йошкар-Оладa мари халкының этногенезы һәм этник тарихы мәсьәләләре буенча үткәрелгән фәнни сессия дә сәбәпче булып тора.

XV гасыр — XVI гасырның беренче яртысында формалашучы мари этносы биләгән территориянең зур өлеше Казан дәүләте эченә кергән. Казан ханлыгы чорында мариларның табигать-географик яшәү шартлары нинди булган соң?

Идел елгасы марилар биләгән территорияне ике тигезсез өлешкә бүлгән, җирләренең күпчелеге болынлы сул як ярда, калганнары таулы уң ярда урнашкан. Сул ярның көнчыгыш өлешен елга үзәнлекләре һәм ерымнар белән капланган калкулык биләгән. Монда субүләр үтә, Идел белән Вяткага коючы елгалар шушында башлана. Көньяк өлешендә зур урманнар һәм шулай ук карст күлләре урнашкан. Казан ханлыгы чорында болын ягы марилар биләгән җирләрнең игенчелектә иң уңдырышлы өлкәсе булган. Сул ярның көнбатыш өлешен — Мари үзәнлеген — урманнар, күлләр һәм сазлыклар биләгән. Ул җирле халыкка азык-төлектә кулланырдай урман тәгамнәре һәм чималларының зур өлешен биргән. Таулы уң ярның нигезен Идел буе калкулыгының сыртлары (плато) тәшкил иткән. Монда вак елгалар һәм ерымнар күп. Платоның уң битләүләре сөзәк һәм авыл хуҗалыгы эшчәнлеге өчен уңайлы.

Формалашучы мари этносының яши торган урыны ылыслы һәм катнаш урманнарның бер-берсенә якынаю зонасында урнашкан. Казан ханлыгы чорында урманнар зур мәйдан биләгән, бу турыда «Казанская история» хезмәтендә берничә кат искә алына. Флора җиләк, дару, печән үләннәре һәм гөмбәләргә бай булган. Урманнарда күпсанлы җәнлекләр һәм кошлар яшәгән. Сулыкларда төрле-төрле балыклар йөзгән.

Мари ягының климаты арктик һәм атлантик һава массалары тәэсире белән билгеләнгән һәм уртача континенталь булган.

Гомумән алганда, табигать шартлары һәм географик урнашу мари этносының этногенезына һәм алга таба үсешенә электән үк уңай тәэсир иткән.

XV гасырда марилар яшәгән территориянең күпчелек өлеше Казан ханлыгына керә. Ханлыкның көнбатыш чиге Сура елгасы буенча үткән һәм тау мариларын үз эченә алган, төньякта чикләр болын марилары һәм удмуртлар яшәгән җирләр буенча барган. Марилар дәүләтнең Галич, Алат һәм Арча даругалары административ биләмәләренә кергәннәр. Бу чорда марилар яшәгән төп территорияләрнең тышкы чикләре тәмам формалашкан була, ул якынча хәзерге Мари Эл территориясенә туры килә[59].

Мариларның торак урыннары табигый су чыганаклары — елга, күл, чишмә һәм сазлыкларга якын урнаштырылган. Тоташ урманлы урыннарда яшәүче марилар өчен елга буйларында тору борынгыдан хас табигый хәл була. Ә мариларның территориаль төркемнәре үзләре яшәгән елга исемнәре белән аталганнар[60]. Өлкәдә халык саны арта барганга, марилар субүләрләргә дә үтеп кергәннәр, аерым алганда, удмуртларны регионның төньяк-көнчыгышына кысрыклап чыгарып, урман аланнарын, тормыш һәм хуҗалык алып бару өчен уңайлы башка урыннарны биләп алганнар. Кайбер урыннарда бик уңайлы булмаган комлы, сазлыклы җирләрдә дә яшәргә туры килгән, тораклар төзү һәм басулар өчен җирне урман кисеп чистартканнар[61].

Торган җирләренең нинди булуына бәйле рәвештә марилар бу өлкә территориясендә тигез таралмаган. Халыкның күп өлеше көньяк, үзәк һәм төньяк-көнчыгыш районнарда яшәгән. Ветлуга һәм Олы Кокшага елгалары арасы, Кече Кокшаганың түбән агымы тирәләрендә халык аз булган.

Тикшеренүчеләр фикеренчә, Казан ханлыгы чорында марилар күрше халыкларның — фин кабиләләренең пермь төркеме — удмуртларның, Казан татарларының, чувашларның, мордваларның һәм русларның көчле йогынтысын кичергәннәр. Марилар регионның төрки телле халыкларыннан күпсанлы тел (бигрәк тә лексик) һәм иң алдынгы мәдәни-көнкүреш элементларын кабул итеп алганнар. Болын ягы мариларының көнчыгыш төркемнәренә Казан татарларының, ә тау мариларына һәм болын мариларының көньяк төркемнәренә чувашлар тәэсире ачык чагыла. Мари-удмурт бәйләнешләре бигрәк тә тыгыз һәм дәвамлы булган, мондый якынлык аларның озак вакыт күрше булуларына яки бер территориядә яшәүләренә бәйле. Мариларның мордва-мукшылар белән мөнәсәбәтләре шулай ук аларның бердәм чыгышларына һәм күптәнге күршелекләренә нигезләнгән. Мариларның, удмуртларның һәм мордваларның угро-фин телләре төркеменә караган телләре, антропологик характеристикалары, хуҗалык эшчәнлеге традицияләре, хуҗалык йолалары элементлары, гаилә-көнкүреш йолалары һәм дини карашлары, матди культуралары, аерым алганда торак урыннары характеры, халык киемнәре, аучылык-балыкчылык һәм җыючылыкка нигезләнгән кулинарияләре охшаш. XV–XVI гасырларга мөнәсәбәтле мари-рус этник бәйләнешләре бик аз күзәтелгән. Ләкин шулай да археологлар тарафыннан Тау ягы һәм Ветлуга буе мари торак урыннарында табылган славян керамикасы һәм христиан көнкүреше элементлары бу мөнәсәбәтләрнең булуын раслый. Марилар үзләре шулай ук күрше халыкларның этнокультур тормышына һәм хуҗалык-көнкүрешенә уңай йогынты ясаганнар[62].

Мариларның шактый зур территориядә һәм озак вакыт дәвамында барган башка халыклар белән үзара этнокультур һәм хуҗалык-көнкүреш бәйләнешләренең төрле булуы бу этнослар эчендә, аерым алганда марилар арасында үзенчәлекле этнографик төркемнәр барлыкка килүенә китерә. Билгеле бер тарихи шартлар аркасында мариларда акрынлап ике этнографик төркем билгеләнә: болын марилары (олык мари) һәм тау марилары (курлык мари). С.Герберштейн, А.Курбский һәм «Казанский летописец» авторы Казан ханлыгындагы мариларның ике төркеме турында ачыктан-ачык язалар.

Этнографик аерымланган тау марилары Чабаксардан алып Сура елгасының түбән агымына кадәр сузылган тау ягында гына түгел, болын ягында да яшәгәннәр. Палеоантропологик материал тау һәм болын марилары арасында сизелерлек аермалар булуын күрсәтә. Шул материал нигезендә тау марилары күп билгеләре буенча чувашлар, удмуртлар һәм мордва-эрзяләр белән охшаш дип расларга мөмкинлек бирә. Болын мариларының монголоид төре исә Идел һәм Кама буйларында урнашкан башка бер халыкка да охшамаган. Алар яшәгән территориянең табигать шартларындагы һәм этник мохиттәге кайбер аермаларга бәйле рәвештә тау мариларының иҗтимагый-икътисади һәм этник үсешенә кайбер үзенчәлекләр хас була[63].

Тау марилары һәм чувашлар арасындагы борынгы бәйләнешләр тау мариларының шактый өлешенең чувашларга охшашлануына китерә. Үзенчәлекле чуваш төркеме — вирьяллар барлыкка килү шуның нәтиҗәләренең берсе. Бу бәйләнешләр шактый катлаулы булган, һәм монда ике культура бер-берсенә үзара тәэсир итешкән. Вирьяллар мәдәниятендә тау марилары сыйфатлары өстенлеге — аларның этник нигезләрен тау марилары тәшкил итүен дәлилли.

Болын һәм тау марилары этнографик төркемнәрен аерып күрсәткәндә, Казан ханлыгы чорында мари халкының башка территориаль төркемнәре дә булуын билгеләмичә мөмкин түгел. Мәсәлән, чыганакларда Казанның яулап алынуына кадәр Казаннан 700 чакрымда башкорт олысларында яшәгән «дальняя черемиса» турында мәгълүматлар бар. Күрәсең, бик еракта яшәгән бу «дальняя черемиса» соңрак көнчыгыш марилар этнографик төркеменең нигезен тәшкил иткән, аларның этник тарихына Г.А.Сепеев һ.б. хезмәтләре багышланган.

Археологик, топонимик материалларны һәм язма чыганакларны бергә өйрәнү мари этносының көнбатышта Ветлуга буеннан алып көнчыгышта Идел-Вятка арасына кадәр Урта Идел буенда, шулай ук Иделнең уң як ярларында формалашуын күрсәтә. Кайбер галимнәр фикеренчә, безнең эраның беренче меңьеллыгы ахырында ук борынгы марилар «чирмеш» исеме белән инде, нигездә, формалашкан халык буларак танылалар. Ләкин мари халкының этногенезын һәм этник тарихын өйрәнүче абруйлы галимә К.И.Козлова мари этносын борынгылаштыру омтылышларына, борынгы мари этносы безнең эраның беренче меңьеллыгы ахырына формалашкан дигән фикергә каршы чыкты.

Елъязмаларда X гасырдан башлап искә алынган «черемиса» аерым кабилә түгел, ә тугандаш диалектларда сөйләшкән, күрше территорияләрдә яшәгән һәм, ихтимал, мәдәни-көнкүреш тормыш тәртипләре охшаш булган территориаль кабилә берләшмәләре җыелмасы булып тора. Елъязмалар чорындагы «черемиса»ны халык дип атап булмый, чөнки ул бары тик Рус дәүләте карамагында, алга киткән феодализм чорында формалашкан мари халкының этник нигезе генә булып тора.

XVI гасырда «Казанский летописец» авторы мариларны бербөтен буларак түгел, ә тугандаш халыкларның зур территориаль төркемнәренең — тау, болын, кокшай һәм ветлуга чирмешләре берлеге буларак карый, аларны этнолингвистик, ягъни телләре һәм барлыкка килүләре буенча гына бер дип таный,

барлык кушылма элементлары булган бер халык дип санамый. Ул вакыттагы тарихи шартларда мондый берлек кисәк барлыкка килә алмаган да. Борынгы кабилә төркемнәре нигезендә барлыкка килгән чирмеш территориаль берләшмәләре территориаль яктан да, диалектлары буенча да, нык «якташлык» карашлары белән дә аерылганнар. Табигый хуҗалык шартларында бу төркемнәр арасында сизелерлек аралашу булмый; алар арасындагы хуҗалык һәм башка бәйләнешләр әле гадәттә иртә феодаль «якташ» төркемнәрне бер халыкка берләштерүче даими органик мөнәсәбәтләр буларак формалашып бетмәгән була.

Болар барысы да К.И.Козловага, ә соңрак С.Х.Алишевка марилар Казан ханлыгы чорында әле бердәм булмаганнар, мари халкының формалашу процессы әле башланып кына килгән дип исбатларга мөмкинлек бирә[64].

Табигать-география шартлары электән үк формалашучы мари этносында борынгы җыючылык, аучылык, балыкчылык һәм умартачылык белән аралаштырылган игенчелек-терлекчелек хуҗалыгы, кәсепләр һәм һөнәрләр үсешенә уңай тәэсир иткән.

Ләкин XV–XVI гасырларда мариларда булган җитештерү төрләре әһәмиятен арттырып күрсәтергә ярамый. С.Герберштейн XVI гасыр башында Идел артындагы урманнар «бал, җәнлекләр, балык һәм тиеннәргә бай» дип яза, шуңа күрә «туземецлар (болын марилары күздә тотыла) аучылык һәм балыкчылык хисабына яшиләр, икмәк турында уйламыйлар» ди. Шул ук вакытта ул Иделнең уң ярында яшәгән тау мариларында аучылык белән беррәттән игенчелек тә булуын билгеләп үтә. «Казанский летописец»та XVI гасыр уртасында: «В той стороне луговой есть черемиса кокшайская и ветлужская, живет в пустынях лесных, не сеют, не орют, но ловом звериным и рыбным и войною питаются и живут аки дикие», — дип яза. 1664–1667 елларда Идел буйларында булып кайткан Н.Витзен, мариларның игенчелек белән шөгыльләнүләрен билгеләп: «Алар җирендә икмәк начар үсә»[65], — дип язган. Шулай итеп, хәзерге тикшеренүчеләрнең күбесе «Казанский летописец» авторының үз-үзенә капма-каршы рәвештә тау һәм болын мариларын «землепашцы» дип атавына таянып, Мари өлкәсенең Рус дәүләте тарафыннан яулап алыну вакытына инде күпчелек мариларда тотрыклы игенчелек формалашкан дип билгеләсәләр дә, мариларның тәмам игенчелек көнкүрешенә күчүләре турында бары тик XVII–XVIII гасырлардан башлап кына сүз йөртергә мөмкин[66].

XV–XVI гасырларда мариларда игенчелек гадәттә чәчү урыннарын еш үзгәртү һәм ышна ачып яңа басу булдыру тәртипләренә нигезләнгән. Игенчелекнең ышна ачу системасы иҗтимагый җитештерү тарихының билгеле бер этабы булып торган һәм ул урманнар каплаган, игенчелек өчен уңайлы җирләрнең азлыгы шартларында бик әһәмиятле саналган. Урман кисеп ачылган ышна җирләре бик тиз уңдырышсызланган. Игенчелектә аз җитештерүчәнле «переложная система» кулланыла. Яңа чистартылган җирдә 3–4 икмәк уңышы җыеп алганнан соң, аны берничә елга «ялга» калдырганнар, ә аннары кабат эшкәрткәннәр.

Мариларда иртә игенчелек системалары трансформациясе Көнчыгыш Европаның урманлы җирләрдәге игенчеләренең хуҗалык-культур төре чикләрендә барган. Аңа, нигездә, охшаш тенденцияләр хас булган; Идел-Урал тарихи-этнографик өлкәсендәге башка халыклар белән бер үк вакытта үскән, игенчелек традицияләре борынгыдан, Идел буе Болгары чорыннан ук сакланган Казан татарларын исәпкә алмаганда, әлбәттә. Этник үзенчәлекләр хезмәт күнекмәләрендә һәм буыннан буынга күчеп барган хуҗалык тәҗрибәсендә чагылган.

Мари өлкәсенең табигый шартлары Казан ханлыгы чорында терлекчелек тармагы үсеше өчен уңайлы булган. Марилар яшәгән территориядә Вятка, Пижма, Немда, Ярань, Олы һәм Кече Кокшага, Ветлуга һ.б. киң тугайлы һәм су баса торган болыннарга бай елгалар аккан. Иделнең болын ягындагы тугаеның киңлеге 5 км га җиткән, бу тугай искиткеч яхшы болын һәм көтүлек булып торган. Марилар ат, мөгезле эре терлек, сарыклар үрчеткәннәр; дуңгызлар белән кәҗәләр мариларның дини карашлары буенча яраксыз саналган, шуңа күрә аларны тотмаганнар диярлек[67].

Казан ханлыгы чорында мариларда аучылык, балыкчылык, табигать нигъмәтләрен җыючылык, чолык умартачылыгы кебек регионның бай флора һәм фаунасына бәйле шөгыльләр дә киң таралган була.

Мариларда һөнәрчелек тармагында агач эшкәртү һәм күннән әйберләр ясау буенча авыл промыселлары эшли. Тимерчелек, зәркәнчелек һәм башка һөнәрләр камилләшә.

Марилар шулай ук күрше халыклар һәм регионнар белән кызу сәүдә алып барганнар. «Казанский летописец» дәүләтнең башкаласы Казан шәһәрендәге ярминкәсенә үз эшләнмәләре белән мариларның килүен («много народу сбирающеся, черемисы на праздники тыя с рухлом своим из дальних улусов и торговаху з градцкими людми») билгеләп үтә. Казан ханлыгына кергән мари халкы татарлар, чувашлар, удмуртлар белән дә, руслар белән дә сәүдә иткәннәр.

Этносның матди мәдәнияте дә, рухи мәдәнияте дә ул яшәгән географик шартлар белән тыгыз бәйле. Марилар мәдәниятенең төп сыйфатлары бу халыкның урманда яшәгән, урманга бәйле булуын чагылдыра. Марилар көнкүреше һәм дини ышану үзенчәлекләре урманда яшәү шартларында формалашкан, монда

халык ау һәм балык тотуга зур әһәмият биргән һәм бу шөгыльләрне ышна ачып иген игү һәм аранда терлек асрау белән аралаштырган. Мондый үзенчәлекләр урманда яшәүчеләрнең билгеле бер хуҗалык культурасы төренә хас һәм мари халкының гадәти көнкүреше һәм мәдәниятенең тирән җирле тамырларга барып тоташуын раслый. Рухи һәм матди мәдәният шулай ук халыкның иҗтимагый-икътисади тормыш шартлары белән дә бәйләнештә тора, шуңа күрә еш кына чыгышлары төрле булган, ләкин иҗтимагый үсешнең бер басмасында торган башка халыклар белән параллельләргә ия була.

Югарыда марилар һәм регионның башка халыклары арасында матди мәдәният өлкәсендәге параллельләр һәм үзара йогынтылар билгеләнде. Дини ышанулар һәм йолалар буенча мариларга иң якын торган халык мордвалар булган. Тарих барышы Казан ханлыгы чорында мордваларда да, мариларда да кайбер очракларда бер-берсенә охшаш үзенчәлекле йолалар барлыкка килүенә китерә. Мариларда мәҗүсилек бу чорда, гомумән алганда, игенчелек һәм терлекчелеккә бәйле табыну характерын ала. Казан татарлары һәм татар-мишәрләр аркылы аларга хәтта мөселманлык идеяләре дә үтеп керә. XVI гасырда кайбер марилар ислам динен тотканнар.

Казанның яулап алынуыннан соң, 1565–1567 елларда Зөя өязе буенча һәм 1603 елда Казан өязе буенча төзелгән беренче рус сан алу китаплары Казан ханлыгының Тау ягындагы җирләрнең өлешчә югары хаким — хан яки аның гаилә әгъзалары һәм күпсанлы болгар-татар аксөякләре милкенә турыдан-туры керүен, ә өлешчә татар, чуваш һәм мордва вәкилләренеке («изстари татарския и чувашския и мордовския») икәнлеген һәм мондый җирләрнең ясак түләүче крестьяннар кулында булуын чагылдыралар[68]. Тау ягында татар феодалларының шәхси җир биләмәләре күбесенчә Зөя елгасы буйларында, ягъни башкалага мөмкин булганча якынрак тупланган, кинәт туган крестьян фетнәләре яки Мәскәү Русе тарафыннан сугыш афәте булганда тизрәк Казанга качып котылу мөмкинлеген күздә тотып билгеләнгән. Мәсәлән, 1551 елда рус гаскәре Зөя суы буена килгәч, мондагы татар бәк һәм морзалары башкалада («князи и мурзы» «в Казани во осаждении»)[69] яшеренгәннәр.

Зөядән көнбатышка таба, Тау ягының марилар яшәгән төбәкләрендә, болгар-татар феодалларының җир биләүчеләр буларак чыганакларда искә алынмавы кызыклы. Бәлки, монда андый шәхси милекле феодаллар бөтенләй булмагандыр һәм бөтен ясаклы халык хан вәкиле җитәкчелегенә буйсынган, ягъни «туры ясаклар» түләгәндер. Хан администрациясе вәкаләте буенча монда ясак җыю кем күзәтүендә булырга мөмкин дигән сорауга Г.Перетяткович ачык җавап бирә: җирле халык вәкилләре кулында («Казанская аристократия со своими поборами могла относиться не непосредственно к инородцам, а через посредство влиятельных среди них людей, через своего рода аристократию — десятных и сотных князей, которым, в свою очередь, могли быть представлены некоторые права и доходы среди подчиненных инородческих племен»). Чыннан да, Тау ягында татар феодаллары урынына җирле халыкның үз старшиналары һәм сотниклары («старейшины и сотники горния черемисы») мөһим роль уйнаганнар. Икенче бер елъязма аларны «сотные князья и десятные» дип атый. Аларның чыгышлары буенча чуваш һәм мари аксөякләреннән булуы Иван IV нең 1574 елгы Казан җире устав грамотасыннан ачык күренә.

Ләкин елъязмадагы «сотный князь» термины ялгыш фикерләргә нигез тудырырга тиеш түгел, чөнки XV–XVI гасырлар рус документлары еш кына төрле «инородец»ларның җирле үзидарә башлыкларын да князь титулы белән бүләкләгәннәр. Чынбарлыкта исә алар зур булмаган җир берләшмәләре башлыклары яки бераз зуррак кабилә берлекләренең хәрби җитәкчеләре булганнар[70]. Шуңа күрә аларны, кайбер авторлар кебек, «милли феодаллар» дип атап булмый. Кабиләдәшләре арасында аларның хакимияте көчләүгә яки халыктан аерылган дружина оешмасына нигезләнмәгән, ә шәхси абруйларына һәм «олылык» патриархаль традициясенә таянган була.

«Сотня» оештыру формасы, ягъни ясаклы халыкны административ-фискаль һәм хәрби нигездә зур булмаган округларга — олыс һәм даругаларның бер өлеше булган йөзлек-сотняларга бүлү марилар һәм чувашлар арасында үзеннән-үзе барлыкка килмәгән, ә хан хакимияте тарафыннан урнаштырылган[71]. Моның шулай булуы ясаклы халыкны якынча күрше авылларның (общиналарның — руэмнарның) аерым төркемнәренә туры килгән сотняларга бүлү Казан хакимлеге нык булган җирләрдә генә, ягъни Зөядән алып Сурага кадәр Тау ягында һәм өлешчә даругалар чикләрендә болын ягында гамәлдә булуыннан күренә.

Дәүләтнең ерак олысларында даими рәвештә түрәләр һәм хәрби гарнизоннар тоту мөмкинлеге булмаганлыктан, шунда яшәүчеләрдән ясак җыярга теләгән Казан хакимнәре бу эшне җирле башлыкларга тапшырганнар һәм аларга аерым өстенлекләр биргәннәр. Хан өчен җирле халыктан билгеләнгән сотниклар болгар-татар феодалларына караганда күпкә түбәнрәк торган вак вассаллар саналганнар. Ләкин алар белән санашырга туры килгән, чөнки дәүләтнең шактый халкы белән шулар идарә иткән, өстәвенә әле бу халыклар хәрби көчләрнең бер өлешен дә тәшкил иткән.

Болын ягы марилары белән Казан хакимнәренең мөнәсәбәтләре бераз башкачарак була. Кара урманнар арасында таралып яшәгән болын мариларының аерым төркемнәре Казан феодалларына номиналь рәвештә

генә буйсынганнар. Һәрхәлдә, болын ягының шактый өлешендә — Ветлуга һәм ике Кокшага елгалары буйларында — татар феодалларының җир биләмәләре бөтенләй булмый диярлек. Болын ягында Тау ягы өчен хас булган сотняларга бүленеш тәртибе дә үсеш алмый.

Авыллары, җир биләмәләре Казанга якынрак урнашкан мари халкы — «черемиса ближняя» — хан хакимияте даирәсенә шактый нык җәлеп ителгән була. Буйсындыруның бу формасы даругалар — әмирләр идарә иткән фискаль-административ округлар системасы аша тормышка ашырылган, алар ханлыкта бишәү булган. (Д.М.Исхаков Казан ханлыгы карамагындагы даругаларны әһәмиятләре буенча дәүләтнең абруйлы нәсел вәкилләре җитәкләгән ярым мөстәкыйль «бәклек»ләргә тигезли[72].) Кече Кокшагадан көнчыгыштарак яшәгән мари халкы җирләре шуларның өчесенең биләмәсенә керә[73].

Көнчыгыш мари җирләренең даругаларга бүленеше бик тотрыклы булган. Даругалар һәрберсе бер төркем авылларны берләштергән сотняларга бүленгән. Аларның һәрберсенең башында җирле община аксөякләре арасыннан куелган сотник торган. Бу сотниклар Казан ханлыгының хезмәттә торучы катламы белән тыгыз бәйләнгән. Алар, күрәсең, үзләренә буйсынган мари крестьяннарыннан хан казнасына җыелган ясакның бер өлеше хисабына яшәгәннәр. Шулай итеп, сотниклар Казан ханлыгының хакимлек итүче югары феодаль катламы һәм «Казанский летописец» авторы «чернь» дип атаган гади «черемиса»лар арасындагы хакимияткә ия арадаш катламны тәшкил иткәннәр.

Яран, Олы Кокшага һәм Ветлуга елгалары үзәннәрендә яшәгән марилар хан хакимияте йогынтысын азрак сизгәннәр, монда даругаларга да, сотняларга да төгәл бүленеш булмаган. Кокшага һәм Ветлуга үзәннәрендә яшәүче мари халкы Казан ханлыгының дәүләт аппараты басымы астына турыдан-туры эләкмәгән һәм, күрәсең, ирекле рәвештә үзләрен бу сәяси берләшмәнең вассаллары дип таныганнар.

Гомумән алганда, ханлыктагы иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең XV гасыр — XVI гасырның беренче яртысында марилар җәмгыятендә феодаль мөнәсәбәтләр үсешенә йогынты ясавын билгеләгәндә, мари этносының феодальләшүе үсешенең башлангыч чорында гына булуын билгеләп үтәргә кирәк. Мариларда җирдән күмәкләп, җәмәгать тәртибендә — патриархаль гореф-гадәтләргә нигезләнеп куллану системасы XX гасырга кадәр сакланган, мариларның милли сәяси үзәкләре булмаган.

XII–XIII гасырлардан ук марилар яшәгән җирләргә көнчыгыш славяннарның күченү хәрәкәте башлана. Бу чорда Сура, Ветлуга һәм Вятка буйларындагы рус кнәзьлекләренең чикләре мари җирләренә бик якын киләләр. XIII–XIV гасырларда новгородлылар һәм башка төньяк-көнчыгыш рус дәүләтләреннән күчеп килүчеләр Вятка елгасы буендагы җирләрне биләп ала башлыйлар һәм җирле халык белән бәйләнешкә керәләр. Монда «бер яктан, русларның Вятка буйлап түбәнгә таба төшүләре, икенче яктан, мариларның инде үзләштерелгән районны бирергә теләмәүләре аркасында бәрелешләр була» диелә Мари АССР тарихына багышланган хезмәттә (кара: Очерки истории Марийской АССР). Күченеп килүче русларның басымы астында җирле мари халкы Вятка буенча түбәнгәрәк төшеп утырырга мәҗбүр була. XIV гасырда марилар яшәгән җирләрнең төньяк-көнбатыш территориясе рус кнәзьлекләре биләмәсенә керә. XV гасыр башында Иделнең сул ярында, марилар яшәгән территориядә, соңрак тирә-юньдә данлыклы христиан табынучыларының бер үзәгенә әйләнгән Макарьевский Желтоводский монастыре төзелә. Бу хәл көнбатыш мариларына карата рус феодаллары һәм православие руханилары йогынтысы көчәюенә һәм аларның Мәскәү Русе даирәсенә кертелүләренә китерә. 1489 елда Вятка җирләрен руслар яулап алгач, төньяк марилары бу дәүләт чикләрендә кала.

1523 елда Казан ханлыгы территориясендә, Сура елгасы тамагындагы Цепель дип аталган мари авылы урынында, Васильгород каласына нигез салына. Бу вакыйга Казан хакимнәренә һәм җирле халыкка ачыктан-ачык каршы чыгу, янау була. 1551 елда Тау ягы Рус дәүләте тарафыннан тулаем яулап алына һәм тау марилары Мәскәү патшалыгы составына кертелә. 1552 елда Казан ханлыгы җиңелгәннән соң, формалашучы мари этносы яшәгән территория тулысынча рус феодалларына буйсына башлый[74].

## 2. Ханлык җирлегендә формалашучы удмурт этносы

Удмурт этносын өйрәнү XIX гасырның икенче яртысыннан башлана. Россия этнографиясе тарихында удмуртларга багышланган беренче монография Казан университеты профессоры И.Н.Смирнов тарафыннан 1890 елда бастырыла[75]. Шул ук елларда диярлек А.А.Спицын, П.Н.Лупповларның удмуртларга (рус елъязмаларында — вотяклар) караган тикшеренүләре дөнья күрә[76]. XX гасырның икенче яртысында Ижевск шәһәрендә Удмуртиянең урта гасырлар тарихы буенча документлар, шулай ук удмуртларның этногенезына, этник һәм иҗтимагый тарихларына, гомумән алганда, Удмуртия этнографиясенә багышланган байтак материаллар басылып чыга[77]. Соңгы вакытта басылган һәм удмурт этносының этнокультур һәм иҗтимагый-сәяси тарихына кагылган хезмәтләрдән В.Н.Белицер,

В.Е.Владыкин, Р.Д.Голдина, М.В.Гришкина, А.Г.Иванов, В.К.Кельмаков, В.В.Пименов, М.М.Салтышев, М.В.Сысоева, Т.И.Тепляшина, Г.Н.Трефилов, А.А.Тронин, Г.П.Шкляев һәм К.И.Козлова хезмәтләрен атап үтәсе килә. Историографиягә ясаган күзәтү[78] хәзерге вакытта удмуртларның этносоциаль тарихы тиешле дәрәҗәдә тулы өйрәнелмәгән булуын күрсәтә, күп мәсьәләләр әле бүген дә чишелмәгән. Удмуртларның бер өлешенең XV–XVI гасырларда Казан дәүләтенә керүләре проблемасы бик аз тикшерелгән булып кала.

Удмуртия Көнчыгыш Европа тигезлегенең Урал буе өлешендә урнашкан, монда калкулыклар һәм түбән төшкән җирләр аралашкан. Суык һәм карлы озак кышлы һәм чагыштырмача кыска җылы җәйле табигать зонасына керә. Ел фасылларының күчү чорлары — яз һәм көз ачык чагылган уртача континенталь климат хас. Удмуртия территориясе күпсанлы елгалар белән бүлгәләнгән, алар ике зур елга — Вятка һәм Камага коялар. Удмуртиянең Казан ханлыгына кергән көньяк өлеше яфраклы-ылыслы урманнар зонасында урнашкан. Элек бу урманнар — төрле киекләргә һәм кыйммәтле мехлы җәнлекләргә, ә елга һәм сулыклар күпсанлы балыкларга бай булган.

XV гасырда удмуртларның Кама буе төркеме Казан ханлыгы йогынтысына эләгә[79]. Мәхмүд хан монда җирле феодальләшүче ыруг башлыклары арасында яклау тапкан, алар хан йөзендә үзәк хакимиятне көчәйтү, үзара ызгышларны[80] киметү һәм үз территорияләренә рус экспансиясенә актив каршы тору мөмкинлекләрен күргәннәр.

С.Герберштейн монда «Вятка һәм Вологдадан алып Камага хәтле киң мәйданнарда халыкның» торак урыннары булмавын билгеләп үтә. Ә археологик тикшеренүләр шул чор удмурт торак урыннарының булуын күрсәтә. Казан ханлыгына кергән удмурт авыллары, гадәттә, елга, күл һәм чишмә буйларында урнашкан була. Казан ханлыгына кергән удмурт халкы (элекке төрки-татар язылышында — арлар) күпсанлы булмаган һәм якынча 50 мең кеше тәшкил иткән. Каманың уң яры удмуртларының Казан ханлыгына керүләре аларның тормышының төрле якларында эз калдырган. Тикшеренүчеләр көньяк удмуртларның этнокультур кыяфәтенә көчле болгар-татар, мари һәм кыпчак-нугай тәэсирен билгеләп үтәләр; аларга шулай ук башкортлар һәм комилар да билгеле этнокультур йогынты ясаганнар[81]. Көньяк удмуртлар ар төркеменең этник-тел табигатендә төркиләр йогынтысы бигрәк тә ачык сизелә. Күпчелек әйбер атамалары һәм төшенчәләр, аерым алганда иҗтимагый терминнар алар мохитенә Казан ханлыгы чорында төркиләрдән кергән.

Бик аз вакыт дәвамында, 10 ел тирәсе, якынча 1468 елдан 1477 елга кадәр, Вятка җирләренең үзәге булган Хлынов шәһәрендә Ибраһим хан вәкиле идарә иткәндә, төньяк удмуртлар белән комиларның бер өлеше шулай ук Казан ханлыгына буйсынган. Төньяк удмуртларның шулай вакытлыча гына Казан ханына вассаллар буларак буйсынулары, әлбәттә, аларның этносоциаль тарихында берничек тә чагылмаган.

Кама буеның тоташ урманлык шартларында аучылык, балыкчылык, чолык умартачылыгы һәм җыючылык удмуртларның борынгыдан килгән хуҗалык шөгыльләре булган. Болгар-татарлар йогынтысында җитештерү көчләре үсүе белән удмуртлар акрынлап җитештерүче хуҗалык формаларына — игенчелек һәм терлекчелеккә күчәләр. Әмма XV–XVI гасырларда удмуртларның бу хуҗалык төрләре әле аз нәтиҗәле булып кала. Болар барысы да удмуртларның географик яшәү шартларына бәйле була. Шулай, әле XVI гасырда ук С.Герберштейн һәм XVII гасырда П.де Ерлезунд Вятка краеның игенчелек өчен уңдырышсызлыгын билгеләп үткәннәр. Үзләштерүче хуҗалык типлары (аучылык, балыкчылык, табигать нигъмәтләрен җыючылык, чолык умартачылыгы) удмуртларның географик-табигый яшәү шартлары белән органик һәм турыдан-туры бәйле булганнар һәм тулысынча диярлек шуның белән билгеләнгәннәр. Без монда формалашучы этносның үзе тирәсендәге экосистема белән тыгыз бәйләнешен күзәтәбез, бу гадәттә статистик үсешле этносларга хас.

Казан ханлыгы чорында көньяк удмуртларда иң алга киткән һөнәрләр кустарь җитештерү рәвешендәге көн әйберләр ясау, сөяк кисү, агач эшкәртү һәм туку була, тимерчелек барлыкка килә. Һөнәрчелек продукциясе, нигездә, җирле халыкның үз ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлтелә, сәүдә җирле даирәдә әйбер алмашу югарылыгында була. Арлар яшәгән җирләрдән читкә мех, бал һәм аккургаш чыгарылган.

Казан ханлыгы чорында удмуртлар мәдәнияте башлангыч хәлендә генә була. Ләкин инде ул чорда ук анда җирле угро-фин һәм төрки халыкларының мәдәни традицияләре аралашуы күзәтелә. Тикшеренүчеләр удмуртлар мәдәниятенең комилар һәм болын марилары мәдәниятләренә якынлыгын, шулай ук удмуртларның матди һәм мәдәни культурасына төркиләрнең көчле йогынтысын билгеләп үтәләр. В.Е.Владыкин фикеренчә, Кама буенда көньяк удмурт халкының сизелерлек төркиләшү һәм исламлашу кичергән бер өлеше булган бисермән этнографик төркеме барлыкка килүе нәкъ менә Казан ханлыгы төркиләренең көньяк удмуртларга көчле этнокультур тәэсире нәтиҗәсе булып тора. Ләкин бисермәннәрнең этногенезы хәзергәчә тулысынча ачыкланмаган[82], чөнки алар үзләре «без татарлардан идек, хәзер удмуртларбыз» диләр, ягъни үзләренең төрки чыгышларын ассызыклыйлар һәм фин телләре мохитендә

охшашлануларын билгелиләр. Йола бәйрәмнәрен уздырганда кайбер очракларда мөселман руханиларына мөрәҗәгать итүләре, аларга сәдака бирүләре дә мәгълүм. Удмуртларга гына хас иҗтимагый күренеш — воршуд оешмасының (бу турыда алга таба кара) бисермәннәрдә булмавы, күренекле этнограф К.И.Козлова фикеренчә, бисермәннәрнең көньяк удмуртлардан чыгуы турындагы гипотезаны шик астына куя[83].

Казан ханлыгына кергән көньяк удмуртларның да, рус феодалларының вассаллары булган төньяк удмуртларның да күпчелеге мәҗүси булганнар. Удмуртларның регионның башка угро-фин халыкларының ышанулары белән охшаш мәҗүси дине системасы шактый катлаулылыгы һәм югары үсеш дәрәҗәсе белән үзенчәлекле була. Бу турыда күпсанлы аллалар пантеоны, культ руханилары абруе, махсус гыйбадәтханәләр булуы, бөтен ваклыкларга кадәр уйланылган һәм корбан чалулар кертелгән йолалар һ.б. — болар барысы да «кеше-җәмгыять-табигать» схемасының эшләп торуын идеологик яктан тәэмин итү өчен кирәк булган.

XV–XVI гасырларда удмуртларда феодаль мөнәсәбәтләр киң таралмаган була. Аларда әле патриархаль ыруг нигезләренең таркалу чоры барган. Ләкин Идел буе Болгары, Алтын Урда, Казан ханлыгы белән тыгыз сәяси, икътисади һәм мәдәни мөнәсәбәтләр корган көньяк удмуртлар җитештерү көчләренең үсеш дәрәҗәсе югарырак булган, аларда иҗтимагый бүленеш төньяк удмуртлар белән чагыштырганда ачыграк чагылган[84]. XV гасыр ахырында көньяк удмурт кабиләләрендә ыруглык строе таркалып бетеп, тормыш феодаль иҗтимагый-икътисади мөнәсәбәтләргә нигез булып торган күршеләр общинасы формасында дәвам иткән.

Күршеләр җәмәгате (общинасы) белән кинештә (төркичә — киңәш, община әгъзалары җыелышы) сайланучы тюро (төркичә — түрә, җитәкче) һәм аның ярдәмчеләре җитәкчелек иткән, алар даими рәвештә ясаклы удмурт халкының Казан хакимнәре белән мөнәсәбәтләрен җайлаганнар. Татар морзалары ярдәме белән тюролар акрынлап алышынмый башлыйлар, алар хакимиятне үз кулларында туплыйлар һәм гади җәмәгать әгъзалары хисабына байый башлыйлар. Вакыт узу белән алар вак җир биләүчеләргә әвереләләр. Тюролар хакимиятен ныгыту Казан феодаллары өчен файдалы булган, чөнки ясакның хакимият казнасына өзлексез түләнүен тәэмин иткән һәм шул ук вакытта регионда сыйнфый һәм милли киеренкелекләр туу хәтәрен күпкә киметкән.

Казан ханлыгы чорында көньяк удмурт җәмгыятенең иҗтимагый төзелешендә мәҗүси культ руханилары да әһәмиятле урын алып торганнар. Удмуртлар арасында каһин вазифасы шәхси рәвештә атадан улга күчмәгән, ә билгеле бер туганнар (гаилә) төркеменә — «каһин ыруына» беркетелгән. Каһиннәр төркеме бердәм булмаган, иерархик принципка нигезләнеп төзелгән: түбән дәрәҗә аллаларга — түбән каһиннәр, югары дәрәҗәле аллаларга баш каһиннәр хезмәт иткән.

Удмуртларның иҗтимагый җәмгыятендә воршуд институты иң үзенчәлекле күренеш булып тора. Үзен билгеле бер гаилә, ә аннары күршеләр берлеге (җәмәгате) әгъзасы дип санаудан тыш һәрбер удмурт үзенең кайсы воршудка каравын төгәл белгән — бу борынгы тотемик ышануларның чагылышы булган.

Билгеләп үтелгәнчә, көньяк удмурт общиналары тюролар аша татар феодалларына буйсынганнар, аларны рус елъязмалары «Арьские князья» («Ар ягы бәкләре») дип атый. М.И.Әхмәтҗанов һәм Д.М.Исхаков фикеренчә, кыпчак феодаллары нәселеннән чыккан Ар ягы бәкләренең Арча даругасының үзәгендә — Арча шәһәрендә — үз резиденцияләре булган, бу даруга, күрәсең, Алтын Урда кланнарының берсе — Кыпчак ыругы биләмәсе саналган. Вятка елгасы үзәнендә кыпчак-нугай феодалларының, аерым алганда нугай «князе» Ханморзаның күчеп йөрүе турында мәгълүматлар бар. Ар ягы бәкләренең бер өлеше Чыпца елгасы буенда урнашкан зур торак пункты — Нократта торган, 1489 елга кадәр Арча даругасының төньяк чиге шушыннан үткән. 1489 елда Вятка ягының Рус дәүләтенә кушылуы Чыпца татарларын рус сәясәте тәэсире астында калдыра. (Кайбер галимнәр фикере буенча, Нократ, Чыпца буе «Ар ягы бәклеге»н XIV гасырда Көньяк Уралдан күчкән кыпчак берләшмәсе нигезли. XV гасырда ярым мөстәкыйль ул бәклекне Мәскәү князьлеге буйсындыра.)

Удмуртлар яшәгән җирләргә рус хәрби отрядлары һәм күчеп килүче рус халкы вәкилләре XI–XII гасырларда үтеп керә башлыйлар. XIII гасырда бу процесс сизелерлек активлаша. XIV гасыр ахырына таба руслар бу территориядә Вятка шәһәрен һәм Вятка елгасының урта агымында, Молома елгасы тамагыннан Кобра елгасы тамагына кадәр биләмәдә дистәләп авыл һәм салалар төзеп өлгерәләр. 1401 елда төньяк удмурт җирләренең байтак өлеше Мәскәү князе биләмәләренә керә. 1489 елда Вятка ягы Иван III гаскәрләре тарафыннан яулап алына. Казан ханлыгының җиңелүе нәтиҗәсендә XVI гасырның 50 нче еллары ахырында Удмуртия тулысынча Рус дәүләте составына керә, ә удмурт халкы формалашу процессы яңа фазага күчә.

## 3. Казан ханлыгына кергән мордва халкы

Мордваларның этногенезы һәм этник тарихына, аның рухи һәм матди мәдәниятенең, иҗтимагый тормышының аерым мәсьәләләренә кагылышлы тикшеренүләр бары тик XIX гасырның икенче яртысы — XX гасыр башында гына барлыкка килә башлый: П.И.Мельников (1867 ел басмасы), В.Н.Майнов (1879, 1883), И.Н.Смирнов (1895), С.К.Кузнецов (1912) һәм кайбер башка авторлар хезмәтләре[85]. XX гасырның 20 нче елларыннан башлап мордва этносын өйрәнү шактый көчәя. Мордваларның этнокультур һәм иҗтимагый-сәяси тарихын өйрәнүдә яңа этап XX гасырның икенче яртысына туры килә, нәкъ шушы чорда бу тематикага багышланган күпсанлы әдәбият басыла.

Мордовия территориясе аерым калкулык һәм елгалар белән бүлгәләнеп беткән тигезлек булып тора. Аның үзәк һәм көнчыгыш өлешләре — Идел буе калкулыгының төньяк-көнбатыш итәгендә, көнбатыш өлеше Ука-Дон уйсулыгында урнашкан. Гомумән алганда, бу регионга сөзәк калкулыклар, тигез түбәнлекләр һәм киң елга үзәннәре хас. Монда күлләр һәм сазлыклар, куе ерым-сызалар челтәре күзәтелә.

Территория яфраклы урманнар һәм урманлы дала зонасы чикләрендә урнашкан. С.Герберштейн XVI гасыр башында мордвалар яшәгән территориядә «зур урманнар» булуын белдерә. Хәтта әле XIX гасырда да урманнар мордвалар яшәгән территориянең яртысын тәшкил итүен исәпкә алганда, Казан ханлыгы чорында формалашучы мордва этносы таралу территориясенең урманнар биләгән өлеше 80 процентган да ким булмаган дигән нәтиҗә чыгарырга була. Урманлы территория — гумус белән бик аз туендырылган һәм шуңа күрә игенчелек өчен шактый уңайсыз көлсу, күбесенчә комсу һәм балчыксыл туфраклар өлкәсе. Әмма XV–XVI гасырларда мордвалар яшәгән территорияләрнең кайбер районнары дала-кыр үзенчәлегенә хас булган, бу кара туфраклы җирләр игенчелек өчен уңай саналган. Шулай итеп, XV–XVI гасырларда мордвалар яшәгән җирләр игенчелеккә ярашлыгы буенча төрле булган.

Мордовиягә уртача континенталь климат хас. Җәен монда яшенле көчле яңгырлар еш була, әмма корылык һәм кызу җилләр дә сирәк түгел, болар барысы да, әлбәттә, халыкның хуҗалык эшчәнлегенә тәэсир иткән.

Урманлы мәйданның зурлыгы, урманлы дала зонасы һәм елгаларның күплеге Мордовия территориясенә хас булганлыктан, анда үсемлек һәм җәнлекләрнең күптөрлелеге күзәтелә.

Казан ханлыгы чорында мордва халкы менә шундый табигый шартларда яшәгән.

XV гасырның беренче яртысында мордва халкының бер өлеше Казан дәүләтенә буйсына. XV гасыр ахырына таба мордвалар биләгән территорияне инде бары тик мордва җирләре генә дип атап булмый, чөнки аның төньяк һәм көнбатыш өлешләрендә — рус авыллары, ә үзәк, көнчыгыш һәм көньяк районнарында чувашлар, Казан татарлары һәм татар-мишәр авыллары да барлыкка килә. XVI гасырдан башлап мордваларның урнашу географиясе көнчыгышка таба рус феодалларының көчәя баручы хәрәкәтенә бәйле рәвештә үзгәрә башлый[86]. XVI гасырда мордваларның урнашу чикләрен С.К.Кузнецов билгели. Ул болай яза: «Мордва авыллары урнашуының көнбатыш чикләре Ука елгасында, Муром урманында тәмамланган... Көнчыгыш чикләр Сура елгасына кадәр сузылган; Сурадан көнчыгышка таба һәм Идел ярлары буенча Самара борылышына кадәр, өлешчә сул яр буенча да көньякка таба мордвалар бары тик чолык ухожайларына гына ия булган. Мордва җиренең көньяк чикләре Хопра һәм Тансырея елгаларына чаклы сузылганнар...»[87]. XVI гасыр уртасында яшәгән мордваларның этник территориясе ареалын галим төгәл билгеләгән. Бары тик аның кайбер көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш координаталарын гына ачыкларга кирәк. Археологик казынулар Казаннан көньяккарак — Иделнең уң ярында да, Самара борылышында да аерым мордва авыллары булуын күрсәтәләр[88]. Русларның көнчыгыш тарафка күченү хәрәкәте нәтиҗәсендә үз территориясеннән кысрыкланган мордваларның еш кына бөтен авыллары белән Казан ханлыгының үзәк районнарына килеп төпләнүен һәм шунда хан биргән җирләрне эшкәртә башлауларын да исәпкә алырга кирәк. Зөя өязе буенча сан алу китабында 20 дән артык ташландык мордва авылы санап үтелә[89]. Шунда ук: «Да в тех селах и деревнях с татары и чувашею преж сего жили мордва...» — дип язылган. Шул ук вакытта мордваларны татар феодаллары көчләп күчергәннәр дигән мәгълүматлар чыганакларда юк. Шуңа күрә кайбер тикшеренүчеләрнең андый фикерләре[90] нигезсез тоела. Мондый информация 1979 һәм 1981 елларда бастырып чыгарылган, XVI гасырда мордваларның урнашу картасын төзегәндә тулысынча чагылдырылган[91]. Карта Казан ханлыгы территориясендә мордва-мукшыларның Идел һәм Зөя арасында, Наровчат-Самара-Саратов өчпочмагында яшәвен, шулай ук ханлыкның көнбатыш чиге булган Сура елгасының бөтен агымы буенча мордва-эрзяләр торганлыгын чагылдыра.

Алда билгеләнгән территориядә мордва халкы тигез урнашмаган, күбесенчә хуҗалык алып бару өчен кулай урыннарда тупланган. Беренче чиратта мондый урыннар елга үзәннәрендә һәм урман түрендәге ачык мәйданнарда булган. XVI гасырның 60 нчы елларында Идел буенда булып кайткан инглиз сәяхәтчесе А.Дженкинсон: «Мордвалар урманнарда һәм буш урыннарда шәһәрләрсез һәм зур торакларсыз яшиләр»,

— дип билгеләп үтә. XVI гасыр уртасында Идел буенда узган бөлдергеч сугыштан соң, бәлки, бу чыннан да шулай булгандыр. Ләкин XV гасыр – XVI гасырның беренче яртысында мордва авыллары булган, бу турыда С.Герберштейн хәбәр итә. Аларның күпчелеге елгалардан ерак булмаган калкулыкларда урнашкан.

Казан ханлыгы чорында мордвалар күрше халыкларның этнокультур тәэсирен кичерә. Күпчелек өлеше Казан дәүләте биләмәсендә яшәгән мордва-мукшыларның ханлыкның башка халыклары белән этник бәйләнешләре бигрәк тә көчле булган. Мукшылар мишәрләрнең, шулай ук чувашлар һәм нугайларның көчле йогынтысын кичергәннәр, болар барысы да мордваларның бу этник төркеменең үзенчәлеклеген тагын да көчәйткән. Ханлык халыклары билгеле бер дәрәҗәдә мордва-эрзяләргә дә тәэсир иткән, бигрәк тә Сура елгасы үзәнендә яшәгән өлешенә.

Мордва этник мохитендә ике эре этнографик төркемгә бүленүен билгеләгәндә, бу мохиттә аерым локаль төркемнәр булуын да читләтеп үтәргә ярамый. Шулай көчле болгар-татар һәм мишәр йогынтысына эләккән каратай[92] локаль мордва төркеме Казан ханлыгы чорында тәмам формалаша. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, каратайлар чыннан да мордва этник төркемен тәшкил итәләр, мөгаен, мукшы төркемендер, алар болгар-татарлар һәм мишәрләр белән озак вакыт күрше булып яшәү нәтиҗәсендә төрки тел һәм мәдәният, һәм көнкүрешнең кайбер элементларын үзләштергәннәр, ләкин мордва үзаңын югалтмаганнар[93]. Каратайлар мордваларның шактый зур төркеменең татарларга ярашуына бердәнбер мисал булып торалар, чөнки XIV гасыр ахырыннан башлап күп очракта мордваларны рус этник төркемнәре охшашлаткан.

XVI гасырның беренче яртысыннан мордваларның тагын бер кечерәк төркеме — шокшалар да яшәп килгән. Мордва-эрзяләрнең төркемчәсе булсалар да, мордва-мукшылар тәэсире нәтиҗәсендә эрзяләрдән шактый аерылганнар. Ләкин шокшаларны мордваларның мөстәкыйль этник төркемчәсе дип санарга ярамый, күрәсең[94]. Алар Казан ханлыгы йогынтысына кермәгән булса кирәк.

Мордва халкының әле безнең эраның II гасырында ук билгеләнгән кабиләләр берләшмәсеннән аермалы принципиаль яңа этник модель буларак формалашу процессы XV–XVI гасырның беренче яртысында дәвам итә. XV гасыр — XVI гасырның беренче яртысында сәяси таркаулыкларына карамастан, мордваларның этнос эчендә туплану процессы көчәюе шуны дәлилли, бу мордва этносының этник үзаңы үсеше белән бәйле була.

Революциягә кадәрге историографиядә мордвалар XVII гасырга кадәр борынгылык шартларында яшәгәннәр, ярым күчмә тормыш алып барганнар, хуҗалыклары җәнлек тотуга, табигать нигъмәтләрен җыючылыкка, балыкчылыкка һәм башка «борынгы» шөгыльләргә кайтып калган дигән фикер бар иде[95]. Ләкин язма, этнографик, археологик һәм башка чыганаклар бу фикерне, гомумән алганда, кире кагалар. Мәсәлән, мордваларның җир эшкәртүләре турында С.Герберштейн яза. Казан дәүләтенә кергән мордваларның хуҗалык үсеше дәрәҗәсе илнең перифериядәге районнары хуҗалыгы үсешенә туры килгән. XV гасыр — XVI гасырның беренче яртысында мордвалар хуҗалыгында игенчелек, терлекчелек, кошчылык, умартачылык, һөнәрчелек һәм сәүдә зур роль уйнаган.

Мордваларда элекке чорлардан — X–XI гасырлардан, ягъни Идел буе Болгары вакытыннан ук билгеле булган игенчелектә үз ысуллары XVI гасырның беренче яртысында алга таба үскән. Казан ханлыгы чорында өч басулы система киң таралган, кайбер урыннарда ышна җире ачып җир эшкәртү тәртибе дә сакланган. Өч басулы система чәчүләр мәйданын арттыруы белән генә түгел, басуларның уңдырышлыгын югары күтәрүе белән дә әһәмиятле һәм прогрессив була. Болар үз чиратында авыл хуҗалыгы коралларын — сука, тәрән, урак, чалгы һәм башкаларны, шулай ук ашлык тарттыру җайланмаларын камилләштерүгә китерә. Мәсәлән, мордваларда XV–XVI гасырларда кул белән әйләндерә торган тегермәннәре (кедьсэ яжамо кевть) һәм ул чор өчен катлаулы механизмлы су тегермәннәре шактый таралган була. Бу тегермәннәрдә икмәк һәм тегермән коралларын саклау өчен махсус янкормалар да булган. Мордва крестьяннары чәчкән иң борынгы культуралар тары, арпа, борчак, борай һәм бодай санала.

Мордвалар хуҗалыгында терлек асрауга мөһим урын бирелгән. Борынгы чорларда ук мордвалар дуңгыз үрчетә башлыйлар, Казан ханлыгы чорында бу тармак тагын да ныграк үсә һәм мордва этник мохитенә исламның бик аз үтеп керүенә дәлил булып тора. Алар шулай ук ат, сыер һәм сарыклар үрчеткәннәр. Табигый шартлар моның өчен уңайлы булган. Киң тугайлы елгалар, азыкка бай урман аланнары муллыгы күп терлек тоту мөмкинлеген биргән, җәен мал ул болыннарда утлап йөргән, араннарда кыш чыккан.

Кошчылык мордваларда шулай ук борынгы чорлардан ук алга киткән була. Күбесенчә үз ихтыяҗлары өчен, сирәгрәк башка товарлар һәм азык-төлеккә алыштыру өчен үрчетелә.

Умартачылык шулай ук мордваларның борынгы шөгыльләренең берсе була. XV–XVI гасырларда мордваларда чолык умартачылыгын бүкән умартачылыгы алыштыра. Умарта бүкәннәрен урманнарда да, торак янында да урнаштырганнар. Мордваларның умартачылыкка бәйле махсус аллалары булган — Нишке-паз — бал кортлары яклаучысы.

Аучылар күбесенчә ит һәм кыйммәтле мех өчен җәнлекләр, шулай ук кошлар да аулаганнар. Ләкин ит азыгы чыганагы буларак ау терлекчелек кебек үк әһәмиятле булмаган. Моны мордва торак урыннарында алып барылган казыну материаллары раслый, кыргый җәнлекләр сөякләре анда 15–20 процент кына тәшкил итә. Ау мордваларга башка файда китергән — аучылар тапкан кыйммәтле мех сатуга чыгарылган яки феодалларга натуралата ясак түләү өчен кулланылган. Мордваларда төп ау кораллары җәя һәм ук булса да, аларның башка җайланмалар (үзаткычлар, тозак чокырлары, капкыннар, элмәкләр) һәм ысуллар (лачын белән, өйрәтелгән этләр белән ау) да кулланулары шактый кыен шөгыльдә югары осталыкка ирешүләрен раслый.

Мордвалар хуҗалыгында балыкчылык шактый әһәмиятле урын алып торган, борынгы мордва торак урыннарындагы казу эшләре материаллары шуны раслый. Эшчәнлекнең бу ысулына мордвалар урнашкан территориядә кыйммәтле балык төрләренә бай күпсанлы елгалар һәм сулыклар булуы булышлык иткән. Әмма тикшеренүчеләр мордва халкында балыкчылыкның XV–XVI гасырларда ярдәмчел шөгыль булуын һәм промысел характерын йөртмәвен билгеләп үтәләр.

Мордва халкында һөнәрчелек даими үсә һәм камилләшә барган. XV–XVI гасыр мордва тимерчеләренә төрле тимердән авыл хуҗалыгы кораллары җитештерү технологиясе билгеле була. Бу эштә югары дәрәҗә осталык һәм күнекмәләр таләп ителгән. Зәркәнчелектә төсле металлардан бизәнү әйберләре кою төп урын алып торган. Археология материаллары мордва ювелирларына күптөрле катлаулы технологияләр таныш булуын раслый.

Металл эшкәртү һөнәрләре белән беррәттән XV–XVI гасырларда мордвалар хуҗалыгында йорт-кура төзү кәсебенең сизелерлек роль уйнавы мәгълүм. Мордвалар йон, киндер һәм җитеннән тукыма ясаганнар. Җеп орчык ярдәмендә тәрәшле сүстән эрләнгән, орчык тизрәк әйләнсен өчен аңа балчык яки таш пряслице киерткәннәр. Кул станнарында җептән тукымалар тукылган.

Мордва торак урыннары һәм каберлекләрендә төрле көнкүреш һәм йорт кирәк-яраклары табыла: кул тегермәне ташлары, чакма һәм чакматашлар, кайраклар һәм безләр, пряслице, балчык һәм бакыр савыт-саба. Балчык савыт-саба бик күп төрле булган: төрле зурлыктагы чүлмәкләр, коштабак-кәндиләр, кружкалар, ашлык, сөт саклау һәм азык әзерләү өчен зур чүлмәкләр. Кулдан эшләнгән керамика еш очрый, әмма махсус чүлмәк ясау тәгәрмәчендә ясалганнары да бар. Торак урыннарында табылган чүлмәкчеләр ясаган керамика Казан ханлыгы чорында мордваларда чүлмәкче һөнәренең чагыштырмача югары үсеш дәрәҗәсендә булуын раслый. Бу чорда мордваларда агач һәм сөяк эшкәртү дә, аерым һөнәрләр буларак формалашмасалар да, шактый камилләшә. Шулай итеп, мәгълүматлар Казан ханлыгы чорында мордвалар хуҗалыгында металл, агач һәм сөяк эшкәртү белән бәйле һөнәрләрнең зур әһәмияткә ия булуларын раслыйлар. Чүлмәкчелек, эрләү, чигү һәм туку кебек йорт җитештерү тармаклары алга таба үсә бара.

Чыганаклар инде XIV гасырдан ук башлап мордваларда йөк көймәләре кулланылуын һәм алар урнашкан территориядә арба юллары булуын хәбәр итәләр. Болар, әлбәттә, эчке һәм тышкы сәүдә үсешенә уңай йогынты ясаган. Моны И.Барбаро XV гасырда ук билгеләп үткән. Әдәбиятта ерак Төркиядә сәүдә иткән мордва сәүдәгәре турында мәгълүмат бар. XV–XVI гасыр документларында күрше базарларга мордвалар китереп саткан товар исемлекләре бар, алар арасында сусар һәм кондыз тиреләре, бал, балавыз мөһим урын алып торган. Болар барысы да мордва халкының Казан ханлыгы чорында киң сәүдә алып баруларын раслый.

Казан ханлыгы чорында мордва халкының мәдәнияте формалашуын дәвам итә. Мордва халкы үзе иҗат итеп кенә калмаган, ул күрше халыкларның мәдәни казанышларын да иҗади эшкәрткән, тудырган әйберләрендә матурлыкка үз карашларын чагылдырганнар. Тикшеренүчеләр мордваларның матди һәм рухи мәдәнияте күрше угро-фин, төрки һәм славян халыкларының мәдәни традицияләре йогынтысын кичергән дип белдерәләр. Бу тенденция декоратив-гамәли сәнгатьнең төрле элементларында бигрәк тә ачык күренә. Мордваларга руслар, Касыйм татарлары һәм мишәрләр иң көчле мәдәни йогынты ясаганнар, бераз марилар, чувашлар һәм нугайлар тәэсир иткәннәр. Зөя елгасыннан көнчыгышка таба яшәгән мордвалар көчле татар йогынтысын кичергәннәр.

Казан ханлыгы чорында мордваларга тарихи-этнографик әдәбиятта гомумиләштереп «мәҗүсилек» дип аталган дини карашларның иртә формаларының тотрыклы рәвештә саклануы хас булган. Тотемик ышанулар, төрле сихер йолалары, анимистик күзаллаулар шулар исәбенә керә. Бөтен әйләнә-тирә чынбарлык аларда җанландырылган һәм аллалаштырылган. Су, урман, җил, ут, күк күкрәү, яшен, кояш, ай һәм башка табигать күренешләре белән күк җисемнәренең үз ияләре булган, аларга уңай сыйфатлар белән беррәттән тискәре үзенчәлекләр дә бирелгән. Аларга ярдәм сорап мөрәҗәгать иткәннәр, бу аллалар хөрмәтенә сулыклар янында яки урман авызында гыйбадәт кылулар оештырылган. Гадәттә, бу йолалар ау һәм балыкчылык чорында, шулай ук игенчелек-терлекчелек эшләре сезонында башкарылган.

Мәҗүси аллаларның күпчелеген мордвалар гадәттән тыш сыйфатларга ия булган кешеләргә охшатып күз алдына китергәннәр (антропоморфизм дип аталучы күренеш). Иҗтимагый тигезсезлек барлыкка килүе һәм сыйнфый мөнәсәбәтләр формалашуы нәтиҗәсендә аллалар пантеонында бөтен «вак» аллалар башында югары алла — мукшыларда — Шкай һәм эрзяләрдә Нишке барлыкка килә. Югары тәңре турында карашлар формалашуына шулай ук көнчыгыш (күбесенчә мукшы) мордваларның мөселманлашуы, ә көнбатыш (күпчелектә эрзя) мордваларның христианлашуы да шактый зур роль уйнаган.

Регионның угро-фин халыкларында, шул исәптән мордва халкы арасында да феодаль мөнәсәбәтләр урнашуы мәсьәләсен чишү беренче тапкыр А.П.Смирнов хезмәтендә фәнни нигезгә куела. Ул әле XX гасырның 20 нче елларында ук Урта Идел буенда феодаль мөнәсәбәтләрнең чагыштырмача иртә, безнең эраның беренче-икенче меңьеллыклары чигендә барлыкка килүен, бу мөнәсәбәтләрнең, нигездә, җирле кабиләләрнең эчке үсеше нәтиҗәсендә, шулай ук Идел буе болгарлары тәэсирендә формалашуын исбатлады. Бу фикерләр галимнең аннан соңгы хезмәтләрендә дә үстерелде[96].

Башка галимнәр тарафыннан да якланган А.П.Смирнов фикеренчә, XI–XII гасырларда мордваларның борынгы бабалары арасында феодаль мөнәсәбәтләр урнашу, беренче сәяси берләшмәләр[97] туплану процессы көчәя барган. Һәм инде XII–XIII гасыр башында ук рус феодаль кнәзьлекләренә буйсынган көнбатыш мордва җирләренең һәм Идел буе Болгары карамагына кергән көнчыгыш мордва җирләренең күпчелеге, һичшиксез, феодаль мөнәсәбәтләр эченә җәлеп ителгән. Шул ук вакытта мордваларның феодаль югары катламы да барлыкка килә башлаган.

Мордваларның борынгы бабаларында монгол-татар явыннан күпкә иртәрәк формалаша башлаган феодаль мөнәсәбәтләр, әлбәттә, киләчәктә алга таба үскән. «Иң яхшы кешеләр» яки мордва телендә *инязор, инекозялар* гомумҗәмәгать (община) җирләрен, балык тоту, кондыз аулау, чолык умартачылыгы урыннарын үз кулларына акрынлап туплаганнар. Болгар-татар феодаллары атамаларын үзләштереп, алар бәк һәм морза исемнәрен алганнар. Мондый үзгәреш бер төркем мордва авылларының рәсмиләштерелмәгән атамаларында чагылыш тапкан. Үзләренә мордва халкын буйсындырган һәм аерым хәрби отрядларга ия булган бу мордва феодаллары рус елъязмаларында еш искә алына.

XIV гасырның икенче яртысыннан, Җүчи олысында төрле феодаль төркемнәр арасында көрәш башлангач, мордва җирләренең Урда феодаллары тарафыннан үзләштерелүе көчәя. Мордвалар яшәгән җирләрдә үз биләмәләрен нигезләгән татар морзалары катламы барлыкка килә. Татар хакимияте астындагы мордва «кнәзьлекләре»ннән торган бу үзенчәлекле вак административ (ясак җыюга бәйле) берәмлекләрне *«беләк»*ләр дип атаганнар («бүләк» сүзеннән). Татар морзалары алардан ясак җыйганнар. Мордваларның Казан татар аксөякләре вәкилләренә «исемле» ясак түләүләре һәм беләкләр турында истәлекләр XVII гасыр рус халык исәбен алу китапларында сакланган[98]. Мәсәлән, Иске Парадеево, Дубенки, Тарханово авылларында яшәгән мордвалар — «князь Куломзинга», Түбәнге Ведянцы халкы «княж Кижедевскийга» ясак түләгәннәр. Д.Пушечников һәм А.Костяевның 1624–1626 еллардагы «Книги письма и меры» китапларында элек Лунгинский, Тургаковский, Сулеменский, Сутолейский, Наватский, Идебирский, Порасельский, Печерский, Козевельский, Кельдюшевский, Кердяшовский, Миркедюшевский, Мокшазаровский, Кирзятский һ.б. беләкләргә караган мордва авыллары атап үтелә. Владимир-Суздаль, соңрак Түбән Новгород һәм Мәскәү кнәзьлекләре феодализмы йогынтысы астында булуы аркасында күбесенчә рус тәэсирен кичергән мордва-эрзяләрнең язмышы бераз башкачарак формалашкан.

Рус һәм татар феодалларына буйсынган мордва феодаллары югары сәяси зирәклеккә ия булганнар һәм шартларга бәйле рәвештә әле татарлар, әле руслар ягына авышканнар, бу хәл аларның геополитик халәтләренә бәйле булган. Шулай да аларның сәяси багланышларының төп юнәлеше чикләнгән була. Казан ханлыгы чорында Казан феодалларына вассал буларак буйсынган һәм дәүләттә үз абруйларын күтәрергә омтылган көнчыгыш мордва феодаллары күпчелек очракта үзәк хакимият сәясәтен хуплаганнар, ислам динен кабул иткәннәр һәм шул рәвешле идарә итүче элита арасына кергәннәр. Көнбатыш мордва феодаллары исә еш кына рус феодализмына ярдәм иткәннәр. XVI гасырның 30 нчы елларыннан башлап Урта Идел буендагы рус хәрби-чик үзәкләренә якын урнашкан беләкләргә ия булган кайбер татар феодаллары да руслар яклы сәясәтне үткәргәннәр. Андыйларның саны даими арта барган.

Мордовиянең төп ясаклы халкын үз эченә алган мордва авыл җәмәгате (общинасы) Казан ханлыгы чорында әле шактый ыруг-кабилә чоры калдыкларын саклап калган, алардан әле хәтта XVII–XVIII гасырларда да арынып бетмәгән була. Ләкин ул җәмгыятьнең феодальләшүе, С.Х.Алишев фикеренчә, бөтен мордва җәмгыятенең феодальләшүе кебек үк, «чувашлар, мари һәм удмуртлар белән чагыштырганда күпкә алга киткән».

Инде билгеләп үтелгәнчә, рус феодализмының мордва җирләренә хәрәкәте монгол явына кадәр үк сизелерлек булган. Казан ханлыгы җиңелүенә кадәр күпкә иртәрәк мордвалар урнашкан җирләрнең, аеруча

мордва-эрзяләр яшәгән төньяк-көнбатыш районнарның Мәскәү кнзяьлеге карамагына күчүе мәгълүм. Ул җирләргә руслар да күпләп күченгән, рус хәрби гарнизоннары һәм авыллары барлыкка килгән.

1372 елда Сура елгасының түбән агымында рус шәһәре Курмыш төзелгәннән соң, рус феодаллары мордва җирләренә тагын да бердәмрәк рәвештә үтеп керә башлыйлар. XV гасырның беренче яртысыннан башлап Урта Идел буена рус феодалларының басып керү хәрәкәте көчәюе күзәтелә, нәтиҗә буларак монда эре дөньяви һәм монастырь җир биләмәләре барлыкка килә. Мордвалар урнашкан территориядә рус җир биләүчеләренең вотчиналары инде үзләштерелгән җирләрнең зур өлешләрен басып алу нәтиҗәсендә формалаша. Мордвалар әкренләп көнчыгышка таба кысрыклап чыгарыла.

XVI гасыр башында Мокша елгасы буендагы Наровчат шәһәрендә рус гарнизоны барлыкка килә. Мордва җирләрендә яңа рус кальгалары төзелә: 1523 елда Сура тамагында — Васильсурск, 1525 елда Алатырь тамагында — Алатырь, 1535 елда Мокшаның югары агымында — XIV гасырдан билгеле булган мордва авылы Мохша урынында — Мокшанск, 1536 елда Мокшаның уң ярында, Иске Темниковтан бераз югарырак — Яңа Темников, 1538 елда Ханкирмәннән (Касыймнан) ерак түгел — Елатьма. Казан янәшәсендә Зөя шәһәре төзелгәннән соң, мордва феодалларының күбесе Явыз Иванга турылыклы булырга ант итәләр, ә инде Казан ханлыгы җиңелгәннән соң, мордвалар тулысынча һәм тәмам Рус дәүләте составына керәләр.

Казан ханлыгының угро-фин халкының этносоциаль үсешен тикшергәннән соң, түбәндәге нәтиҗәләргә килдем:

1. XV гасыр — XVI гасырның беренче яртысында региондагы төрки, угро-фин һәм көнчыгыш славян халыкларының үзара бәйләнешләре этнокультур һәм иҗтимагый-икътисади процессларның даими шартына әверелә.

2. Бу чорда угро-фин халкына төркиләрнең этнокультур йогынтысы бигрәк тә ачык билгеләнә, бу хәл еш кына дәүләтнең перифериядәге халкы арасында үзенчәлекле этнографик төркемнәр барлыкка килүенә китерә.

3. Дәүләтнең нигезен тәшкил итүче халыкның иҗтимагый-икътисади йогынтысы Казан ханлыгы чорында перифериядәге угро-фин халкы арасында киң тарала.

4. Рус дәүләтенең «Казан сугышы»на әзерлеге һәм турыдан-туры Казанны яулап алу процессы татарларга гына түгел, мари, мордва һәм башка халыкларга да каршы юнәлтелгән хәрби акцияләр аша алып барылган; рус феодалларының бу акцияләре еш кына җирле халыкның юк ителүенә, кешеләрнең урнашкан җирләреннән куылуына китергән, ягъни регионда демографик үзгәрешләр һәм этник миграцияләр туууына сәбәп булган.

# ЙОМГАК

Хезмәтемнең темасы этник һәм социаль тарих, Казан ханлыгының барлыкка килүе һәм яулап алынуы, дәүләтнең сәяси тарихы, илнең полиэтник халкының этногенезы, җирле халыкның этнографик төркемнәре, аларның саны һәм урнашу территорияләре кебек теоретик сорауларга бәйле мәсьәләләрнең зур төркемен үз эченә ала. Бу мәсьәләләрнең күпчелегенә карата тарих фәнендә бердәм фикер юк һәм булмас та, мөгаен, чөнки мәдәниятнең катлам-катлам булуы һәм Идел буе халыклары формалашу процессында төрле компонентлар катнашуы аларның этносоциаль тарихын өйрәнүгә шактый тәэсир итәләр, шулай ук кайбер аерым тарихчыларның субъектив этнополитик карашларының да йогынтылары зур.

Хезмәтнең хронологик һәм географик чикләре киң булу сәбәпле, Казан ханлыгының этносоциаль тарихының бөтен мәсьәләләре бердәй тикшерелмәде. Мәсәлән, Казан ханлыгының башкаласы турында сораулар, «ясаклы чувашлар»га кагылган җитди мәсьәлә, дәүләтнең нигезен тәшкил иткән этносның этнокультур тарихына кагылышлы мәсьәләләрнең күбесе минем тарафтан тикшерелмәде, чөнки бу сорауларга күпсанлы махсус хезмәтләр багышланган. Ул чорда чувашлар һәм башкортларның этносоциаль үсеше буенча бәхәсле мәсьәләләр тикшеренү чикләреннән читтә калды, алар М.И.Әхмәтҗанов, М.З.Зәкиев, Д.М.Исхаков, В.Ф.Каховский, Р.Г.Кузиев, В.В.Трепавлов, А.Х.Халиков һ.б. хезмәтләрендә чагылдырылган. Җирле халыкның этнографик һәм этноконфессиональ төркемнәренең үсешенә кагылышлы мәсьәләләр тулысынча ачылып бетмәде һ.б. Санап үтелгән мәсьәләләрнең күбесе, минемчә, махсус монографик тикшеренүгә лаеклы.

Казан дәүләтендәге этносоциаль процессларны өйрәнү мине «алар шактый катлаулы һәм төрле булганнар, тарихи планда гына түгел, хәзерге заман милләтара мәсьәләләрне чишү өчен дә әһәмиятле булып торалар» дигән нәтиҗәгә китерде.

Казан ханлыгының этносоциаль тарихын тикшерү нәтиҗәсендә түбәндәге төп нәтиҗәләргә килдем:

1. Идел-Урал тарихи-этнографик регионы халыкларына этнокультур һәм иҗтимагый-сәяси формалашу уртаклыгы хас, аның башлангычлары Идел буе Болгары, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы цивилизацияләренә барып тоташа.

2. Гомумән алганда, Алтын Урда чоры региондагы этник һәм иҗтимагый процесслар юнәлешләре сыйфатын үзгәртә, аларга аннан соң килгән чорда дәвам иткән куәтле үсеш инерциясен бирә.

3. Казан дәүләте Идел-Кама буе Болгарының да, Алтын Урданың да этнополитик варисы булып торган.

4. 1445 елда Казан ханлыгында турыдан-туры Алтын Урда династиясе урнашуы регионның этнополитик һәм иҗтимагый тарихында җитди үзгәрешләр тудыра.

5. Казан ханлыгы чоры түбәндәге этносоциаль процесслар белән билгеләнә:

а) ханлыкның сәяси тормышында зур роль уйнаган кыпчаклашкан этник компонентының тоткан урыны көчәюе күзәтелә;

б) регионда формалашучы угро-фин халыкларына төркиләрнең этносоциаль йогынтысы ачык билгеләнә;

в) татарларның дәүләтнең периферияләге халкына этносоциаль һәм йомшак конфессиональ тәэсире ачык билгеләнә;

г) Казан ханлыгы чорында этнослар арасында бәйләнешләр артуы — җирле төрки һәм угро-фин халыкларының мәдәни (тел, дини, иҗтимагый-икътисади һ.б.) традицияләренең өлешчә катнашуына һәм җирле халыкның үзенчәлекле этнографик төркемнәре барлыкка килүенә китерә (каратайлар, бисерманнәр һ.б.);

